ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Л.Р. Надыршина**

# ӘДӘБИ ИҖАТ СИСТЕМАСЫ БУЛАРАК XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ПОЭМАСЫ

Казан
2018

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2Рос.Тат)**
**Н 17**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары белән басыла*

**Фәнни мөхәррир**

филология фәннәре докторы, профессор **Т.Н. Галиуллин**

**Рецензентлар:**

филология фәннәре докторы, доцент **Ф.С. Сәйфуллина,**
филология фәннәре кандидаты **Р.Ф. Рахмани**

**Надыршина Л.Р.**
**Н 17** Әдәби иҗат системасы буларак XX йөз башы татар поэмасы / Л.Р. Надыршина. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 160 б.
ISBN 978-5-93091-260-9

Китапта узган гасырның унынчы елларында дөнья күргән лиро-эпик әсәрләр әдәби агымнарга мөнәсәбәтле төркемләнә һәм әдәби иҗат системасы буларак фәлсәфи-эстетик ноктадан анализлана.

Хезмәт әдәбият белгечләренә, укытучыларга, студентларга, шулай ук татар әдәбияты тарихы белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2Рос.Тат)**

**ISBN 978-5-93091-260-9**

© Надыршина Л.Р., 2018;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

## КЕРЕШ

Милли мираска мөнәсәбәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә, халыкның үз үткәне, мәдәни байлыгы белән кызыксынуы арту, моңа кадәр күләгәдә калып килгән әдәби катламнарның ачылуы әдәбият тарихына, тикшерелмәгән яки берьяклырак өйрәнелгән күренешләргә яңача карарга мөмкинлек бирде. Татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңарыш идеяләре поэзиядә башкачарак тикшерү критерийларын алга чыгаруга юл ачты. XX йөз башы әдәби мәйданындагы поэмаларны төрле иҗат юнәлеше һәм агымнарга мөнәсәбәтле өйрәнү дә – шундый өлкәләрнең берсе.

XX йөз башына кадәр иҗат ителгән поэмаларда традицион сюжет-мотивлар төп урынны алып тора, дидактик хикәяләү стилен һәм гуманлылык идеяләрен раслау беренче планга чыга. Бу поэмаларның үзәгендә үзен мәхәббәт хисләре өчен корбан итәрлек лирик герой тора, һәм ул әкият каһарманнарына якыная, лиро-эпика тулысы белән романтизм кысаларында карала ала. XX йөз башы татар сүз сәнгатендә исә поэма жанры тамырдан үзгәрә, өр-яңа үсеш сукмакларын барлый. Т. Галиуллин фикеренчә, «күп кенә сюжетлы шигырьләрнең нигезендә поэма материалы ята, ә шагыйрьләр әлеге күләмле жанрга вакыйгалы шигырь аша киләләр. Поэма әһәмиятле вакыйгаларны үзәккә ала, поэзия үсешенең яңа юлларын барлый һәм шагыйрьнең башка (аеруча лирика өлкәсендә) эзләнүләренә, фәлсәфи-этик уйлануларына йомгак ясый. Милли әдәбиятта поэма кебек зур жанр формалашу әлеге әдәбиятның югары үсешкә ирешүе хакында сөйли»[1]. XX йөз башы татар әдәбияты да

---

[1] *Галиуллин Т.Н.* Дыхание времени. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1979. – С. 249.

нәкъ менә поэма жанрының яңа көч алып мәйданга чыгуы белән характерлана, бу исә милли сүз сәнгатенең әлеге чорда яңа үсешкә ирешүен, камилләшүен раслаучы күренеш булып тора. Шуның белән беррәттән, XX йөз башында шигъриятнең, бигрәк тә поэма жанрының үсеп китүен иҗтимагый фикер, сәяси шартлар үзгәрү нәтиҗәсендә яңа җәмгыятьнең мәдәни нигезен, идеологиясен эзләү процессы белән бәйле рәвештә дә карарга мөмкин. Әгәр Урта гасыр иҗтимагый һәм әдәби фикеренең бер үзенчәлеге булып «илаһи сүзнең зур абруйга ия булуы»[1] торса, дини идеология арткы планга күчеп, илаһи сүзнең әһәмияте кими барган чорда аның урынын «басма», иҗади сүз ала[2]. Бу исә, үз чиратында, шагыйрьлекне пәйгамбәрлек миссиясе белән тәңгәлләштерүгә китерә. Әлеге фикер Лотман өйрәтүләрендә дә әйтелә[3]. Шул рәвешле, агымдагы чорда шагыйрь авызыннан чыккан сүзне илаһи сүз дәрәҗәсендә кабул итү шигъриятнең үсешен нигезли. Күпләп иҗат ителгән поэмалар да халыкка иҗтимагый-милли, әдәби, фәлсәфи фикерләрне җиткерү максатына хезмәт итә. Көнчыгыш әдәбияты традицияләренә нигезләнеп үскән һәм XX гасыр башында рус, аның аша Көнбатыш әдәбиятлары йогынтысын тойган милли сүз сәнгате традицион алымнарга яңача караш булдыра, шул ук вакытта татар әдәбияты өчен яңа булган күренешләр күпләп күзәтелә башлый. Моңа кадәр ислам дине белән бәйле мифологик элементлар, суфичылык дәвереннән үк килгән традицион сюжет-образларга нигезләнгән әдәбият дини-дидактик, үгет-нәсыйхәтчелек максатларын алга сөрсә,

[1] *Гафиятуллина Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә Тукай. – Казан: Матбугат йорты, 2002. – Б. 25.

[2] *Мухаметшин Р.* Ислам в татарской общественной мысли начала XX века // Очерки истории татарской общественной мысли. – Казань, 2000. – С. 160.

[3] *Лотман Ю.* Литература в контексте русской литературы XVIII века // О русской литературе. – СПб., 1997. – С. 122.

XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләр дөньяви фикерләр үткәрү мәйданына әйләнә. Бу чорда татар сүз сәнгате иҗат агымнарының төрлелеге нисбәтеннән һәм әсәрләрнең поэтик эшләнеше ягыннан яңа баскычка күтәрелә. Әлеге күренеш XX йөз башы лиро-эпикасында аеруча киң чагылыш таба, яңа рухтагы әсәрләр ике инкыйлаб арасында күпләп языла. Мәдәни-тарихи процесслар нәтиҗәсендә сәнгатьчә фикерләүнең яңа тибы барлыкка килә, шуның бер күренеше буларак, кануный булмаган жанр формалары оеша. Шуңа мөнәсәбәтле, татар лиро-эпикасында да, традицион реализм һәм романтизм белән бергә, модернистик элементлар синтезы күзәтелә. Г. Тукай, Ш. Бабич, Ф. Бурнаш, Г. Харис, Н. Думави, Г. Рәхим, З. Бәшири, Г. Сөнгати һ.б. шагыйрьләрнең иҗади эзләнүләре татар әдәбиятында яңа үсеш сукмакларын нигезли.

Иҗтимагый фикернең үзенчәлекле бер төре булган әдәбиятны, шул исәптән поэтик әсәрләрне яңа күзлектән максатчан тикшерү XX йөз башы поэзиясе хакындагы күзаллауларны шактый киңәйтә. Әдәби процессны өйрәнү, гадәттә, аерым әдәби әсәрләр, иҗатлар аша алып барыла, шунлыктан поэмаларны тикшерү, XX йөз башы татар шигърիятенең милли сыйфатларын төгәлләштереп, әдипләрнең сәнгати-эстетик һәм фәлсәфи эзләнүләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Болар барысы хезмәтнең актуальлеген билгели.

XX гасыр башы татар лиро-эпик мирасы аерым галимнәр тарафыннан билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнелгән. Әле совет чорында ук Х. Госман, Г. Халит, И. Нуруллин кебек галимнәр XX йөз башы татар шигъриятенә багышланган эзләнүләр алып бара. Әмма бу тикшеренүләр, чор идеологиясеннән азат булмыйча, нигездә, милли мирасны социологик мотивлар чагылышы ноктасыннан өйрәнеп, аны реализм яки прогрессив романтизм кысаларына кертергә тырышу төсен ала, шуңа нисбәтән, XX йөз башында язылган поэмаларда милли азатлык өчен көрәш, революциягә кадәр халыкның

авыр язмышын сурәтләү, Аллага, дингә каршы чыгу кебек мотивлар барлана, чорга тәнкыйди карашлар, яңача эзләнүләр күләгәдә кала яки берьяклы мөнәсәбәт белдерелә.

Әйтик, Х. Госманның «Шигърият гомере» (1978) хезмәтендә әлеге чор әдәбияты ике, ягъни реалистик һәм романтик катламнарга аерып карала. Һәм автор романтик әдәбиятның сюжет материалын борынгыдан – тарихи, дини легендалардан, халык әкиятләреннән алуын билгели. Х. Госман легендаларга таянып иҗат ителгән поэмаларның нигезендә Урта гасыр тәртипләренә нәфрәт ята, дигән фикерне алга сөрә, әсәрләргә берьяклырак якын килә. Мәсәлән, мондый үрнәкләр рәтендә Гариф Шәрифинең «Нәнкәҗан» поэмасы карала. Автор поэманың үзәгендә ханлык, хакимлек белән азатлыкка омтылучы кеше арасындагы конфликт ятуын билгели һәм легенда материалын иске гадәтләргә каршы баш күтәрүгә генә кайтарып калдыра.

Х. Госман гасыр башында диннең, дини легендаларның татар поэзиясенә тәэсир итүен күрсәтә, пәйгамбәр образына мөрәҗәгатьнең аеруча киң таралуын билгели, әмма бу күренеш чынбарлыкны сурәтләүгә зыян гына китерә, дигән фикерне алга сөрә. Г. Сөнгатинең «Хозыр» поэмасын үрнәк итеп күрсәтә, аның пәйгамбәрен пассивлыкта гаепли[1]. Х. Госман шулай ук М. Гафуриның «Рисаләт» поэмасына да бәя бирә. Биредә дә автор Мөхәммәд пәйгамбәр образының әсәрдә гади кешеләрнең бәхетсезлеген күрсәтү, бу бәхетсезлектә байларның һәм көчлеләрнең гаепле булуын фаш итү максатыннан кертелүен билгели2. Ш. Бабичның «Газазил» әсәренең Аллага каршы көрәш темасына язылуын ассызыклый[3].

---

[1] *Халит Г.М.* Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 38.

[2] *Госман Х.* Шигърият гомере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 39.

[3] Шунда ук. – Б. 53.

Г. Халитнең «Яңа гасыр поэзиясе» (1979) хезмәтендә[1] дә тәнкыйди реализм һәм прогрессив романтизм иҗат ысуллары белән язылган әсәрләрне генә игътибар үзәгенә алу максаты куела. Шуңа бәйле рәвештә, Г. Сөнгати, Г. Харис, И. Шаммаси кебек шагыйрьләрнең «реакцион романтизм» үрнәкләре буларак каралган иҗаты тикшерүдән, гомумән, читтә кала.

И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1982) хезмәтендә ул вакыт идеологиясенә яраклаштырып тикшерергә мөмкин булган Г. Тукай, Ш. Бабич, Н. Думави, М. Гафури кебек шагыйрьләрнең иҗаты гына карала, бу чор лиро-эпикасы дигән баш астында Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы, аның халык иҗатына нигезләнгән әкиятләре, Ш. Бабичның «Газазил» әсәре анализлана. Соңгы поэма Аллага каршы рух белән сугарылган, Алланың гади кешегә ясаган зыянын, диннең тискәре якларын ачып бирүгә корылган әсәр сыйфатында укучыга тәкъдим ителгән[2]. Китап авторы Беренче бөтендөнья сугышы елларында иҗат ителгән поэмаларны реакцион романтизм кысаларына кертеп карый. Г. Сөнгатинең «Хозыр», К. Юлдашевның «Чура батыр», Г. Шәрифинең «Нәнкәҗан», Н. Думавиның «Шәрык даһие» поэмалары – әнә шундыйлардан.

М. Гайнуллин да Беренче бөтендөнья сугышы чорында татар шигъриятенең яңа сыйфат үзгәрешләре кичерүенә басым ясый, сугышка каршы мотив белән халык авыз иҗаты бергә үрелгән, тормышка ашмаслык хыял дөньясы чагылдырылган әкияти характердагы поэмаларның күпләп язылуын билгели. Шундыйлар рәтендә Х. Исхакыйның «Таз һәм падишаһ әкияте», М. Гафуриның «Гаип хәзинә», Г. Харисның «Хозыр», Н. Думавиның «Гыйшык трагедиясе»,

---

[1] *Халит Г.* Яңа гасыр поэзиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 168 б.

[2] *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 224.

Ш. Бабичның «Газазил», Н. Исәнбәтнең «Сукбай» поэмалары атала[1]. Галим тарафыннан Беренче бөтендөнья сугышы елларында романтик поэмаларның һәм балладаларның күпләп иҗат ителүе дә әһәмиятле яңа күренеш булды һәм жанр хокукын алды, дип раслана. Ул төр әсәрләрдә татар милли романтизмының характерлы һәм каршылыклы билгеләре аерата калку булып күренүе ассызыклана[2].

Г. Тукайның сатирик иҗатын тикшерүгә багышланган хезмәтендә[3] Р. К. Ганиева әдипнең сатирик рухта иҗат ителгән шигырьләре белән беррәттән, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына да җентекле анализ бирә.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, үзгәртеп кору елларына кадәр басылган хезмәтләрдә тәнкыйди реализм агымына караган поэмалар игътибар үзәгенә алына. Романтизмның революцион дип исемләнгән канаты гына таныла һәм идеология таләпләреннән чыгып бәяләнә. Г. Тукай, Ш. Бабич, Н. Думави, М. Гафури, С. Сүнчәләй, Ф. Бурнаш кебек әдипләрнең поэмалары идеология кысаларына утыртыла, ә Г. Сөнгати, Г. Харис, Б. Мирзанов шикелле шагыйрьләрнең чор тәнкыйте декадентлык тамгасы салган лиро-эпик әсәрләре тикшерүчеләр игътибарыннан читтә кала яки тискәре бәяләнә. Беркадәр уңай бәя алганнары да, чор идеологиясе таләпләреннән чыгып, берьяклы гына анализлана.

Соңгы елларда XX йөз башы татар әдәбиятын, шул исәптән лиро-эпиканы тикшерүгә яңача якын килү, катламнар синтезы төсендә бәя бирү күзәтелә. Г. Гыйльмановның

[1] *Гайнуллин М.* Татарская литература и публицистика начала XX века. Изд. 2-е, доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – С. 159.

[2] Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 3 т. – Б. 78.

[3] *Ганиева Р.К.* Сатирическое творчество Г. Тукая. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964.

«Татарская баллада» монографиясе[1] әлеге чор поэмаларын иңләп алырга омтылган хезмәт буларак, игътибарга лаек. Бу китапта без тикшерүгә алган әсәрләрнең күбесе баллада жанрына кертеп карала.

XX йөз башы эпик шигъриятенең аерым үрнәкләре, Ф. Яхин тарафыннан тупланып, җыентык булып дөнья күрде. Галим XX йөз башы татар поэмаларының, нигездә, романтизм кысаларында иҗат ителүен билгели[2]. Икенче бер хезмәтендә Ф. Яхин XX йөз башында мифологик материал һәм тарихи легендалар нигезендә шигъри әсәрләр язылуның шактый активлашуын искәртә[3] һәм М. Гафури, Н. Думави, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич, Ф. Бурнаш, Б. Мирзанов, Г. Сөнгати һ. б. поэмаларына мәгърифәтчелек идеяләре яссылыгыннан бәя бирә.

XX йөз башы татар поэмаларын монографик планда өйрәнгән хезмәтләр юк, әмма кайбер галимнәрнең эзләнүләрендә XX йөз башы лиро-эпикасының аерым үрнәкләре гомуми эчтәлеккә бәйле төстә анализлана. Мәсәлән, Р. Ганиева үзенең «Татарская литература: традиции, взаимосвязи» хезмәтендә XX гасыр башы татар лиро-эпикасының кайбер үрнәкләренә тукталып үтә. Ул Ш. Бабич иҗатындагы романтик мотивларга бәя бирә һәм аның «Газазил» поэмасын тикшерә[4]. Әлеге әсәр Д. Заһидуллина тарафыннанда шактый үзенчәлекле бәяләнә, мифологик сюжет, образлар бирелеше

---

[1] *Гильманов Г.Х.* Татарская баллада. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 192 с.

[2] *Яхин Ф. З.* XX йөз башы эпик шигърияте // Эпик шигърият: XX йөз башы. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 7.

[3] *Яхин Ф. З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: ТДГИ нәшрияты, 2000. – Б. 260.

[4] *Ганиева Р. К.* Романтические мотивы творчества Шаехзаде Бабича // Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 132–135.

ноктасыннан җентекле анализлана[1]. Т. Галиуллинның «Шәехзадә Бабич – сатира остасы» дип аталган мәкаләсендә дә әдипнең «Газазил» поэмасына тукталып үтелә һәм, шуның белән бергә, «Кандала» поэмасы турында да фикерләр әйтелә[2].

Д. Заһидуллинаның XX йөз башы татар сүз сәнгатен тикшерүгә багышланган хезмәтләре чор әдәбиятын яңа күзлектән бәяләү критерийларын билгеләде. Милли сүз сәнгатен дөнья сурәте үзгәрү нисбәтеннән анализлаган «Дөнья сурәте үзгәрү» монографиясендә[3] галимә XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнү объекты итеп ала һәм аерым поэмаларны да оппозицияләр сурәтләнеше ноктасыннан тикшерә. Яшәү һәм үлем фәлсәфәсенә бәйле рәвештә, Н. Исәнбәтнең «Качкын», Ф. Бурнашның «Коркыт» поэмалары тикшерелә; мифларны тергезү һәм яңа миф тудыру аспектыннан М. Гафуриның «Адәм вә Иблис», Ш. Бабичның «Газазил» поэмалары җентекле анализлана, Н. Исәнбәтнең «Сукбай», Н. Думавиның «Шәрык даһие» әсәрләренә гомуми бәя бирелә.

Л. Дәүләтшина үзенең хезмәтләрендә, татар әдәбияты һәм халык авыз иҗатында Акыллы карт архетибы бирелешен тикшерүгә бәйле рәвештә, Г. Сөнгатинең «Хозыр» поэмасындагы Хозыр образын да шушы архетипка мисал буларак билгеләп үтә[4].

Н. Йосыпованың XX йөз башы татар поэмаларындагы яңа тенденцияләрне үзәккә алган фәнни мәкаләләрендә

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Шәехзадә Бабичның иҗат юлы: мәгърифәтчелектән шартлы сурәткә таба // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 159–163.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Шәехзадә Бабич – сатира остасы // Галиуллин Т.Н. Дәгъва. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 246–255.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 191.

[4] *Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI вв.: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань: РИЦ «Школа», 2005. – С. 19.

аерым үрнәкләр модернизм йогынтысын тойган әсәрләр буларак анализлана[1].

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, XX йөз башында дөнья күргән поэмаларның күбесе тикшерүчеләр игътибарыннан читтә калып килә. Безнең фикеребезчә, бу әсәрләр яңа яссылыкта бәя бирүне таләп итә. Бу хезмәттә узган гасырның унынчы елларында дөнья күргән лиро-эпик әсәрләрне иҗат юнәлеше һәм агымнарга мөнәсәбәтле төркемләү, әдәби иҗат системасы буларак фәлсәфи-эстетик ноктадан өйрәнү максаты куела. XX йөз башы татар лиро-эпикасын бу рәвешле өйрәнү чор поэзиясендә һәм, гомумән, әдәбиятында барган үсеш тенденцияләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

[1] *Юсупова Н.М.* Символизация в татарской поэзии начала XX века // Вестник Удмуртского университета. – 2014. Серия «История и филология». – 2014. – № 4. – С. 111–114; *Юсупова Н.М.* Мифологические образы и сюжеты в лиро-эпических произведениях начала XX века: роль, функции и художественное значение // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2014. – № 4. – Ч. 2. – С. 211–214.

## Беренче бүлек

# XX ЙӨЗ БАШЫ ТРАДИЦИОН ТАТАР ПОЭМАСЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮСЕШЕ

### 1.1. XX йөз башы татар поэмаларында реалистик юнәлеш яңарышы

XX йөз башында татар әдәбияты, шул исәптән лиро-эпика да яңа үсеш юлына чыга. Әлеге чор татар поэмалары бердәм калыпта, бер генә юнәлештә үсеп китми. Төрле шагыйрьләр иҗатының асылын билгеләгән яңа агымнар тиз арада киң таралса да, гасырлар буе килгән традицияләр, гомумбилгеле шәкелләр зур урын алып торуын дәвам итә, татар шигъриятендә алга чыккан романтизм һәм модернистик күренешләр янәшәсендә реализм әйдәп баручы юнәлеш буларак яши. Бу чорда да мәгърифәтчелек реализмы рухында иҗат ителгән поэмалар күп күзәтелә, шуның белән беррәттән, XX йөз башы татар әдәбиятының бер үзенчәлеге булган тәнкыйди реализм да лиро-эпикага ныклап кереп урнаша. Р. Ганиева революцион көрәш җәелүне татар әдәбиятында тәнкыйди реализм барлыкка килүнең төп сәбәбе итеп күрсәтә. Шул ук вакытта, кеше шәхесенә игътибар арту белән бәйләп, әлеге агымга параллель рәвештә романтизмның да үсүен ассызыклый[1]. Р. Ганиева бу үзгәрешне чорның күчеш, феодаль тәртипләр җимерелү, инкыйлаблар, милли-азатлык хәрәкәте үсеше дәвере булуына мөнәсәбәттә карый[2].

---

[1] *Ганиева Р.К.* Художественные методы в тюркских литературах начала XX века // *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 54.

[2] Шунда ук. – Б. 54.

Ф. Бәширов та, 1905 елдан соң татар әдәбиятында җитди сыйфат үзгәрешләре кичәргән тармакның поэзия булуын билгеләп, инкыйлабның шигъриятькә мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш темасын алып килүен раслый[1]. Әлеге фикерләр З. Рәмиев тарафыннан да дәлилләнә: «Илдә иҗтимагый тигезсезлек һәм каршылыклар моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә кискенләшә, милли азатлык хәрәкәтләре көчәя. Гасырлар буена үсеп-үзгәреп, яңа сәнгатьчә сыйфатларны үзендә туплый килгән татар лирик шигърияте сулышына болар көчле тәэсир итеп торганнар, аның эчке рухын, лирик-психологик табигатен катлауландырганнар»[2]. Й. Нигъмәтуллина эзләнүләрендә XX йөз башы татар сүз сәнгатендә эстетик идеал мәсьәләләре тикшерелә һәм әлеге чор әдәбиятында, шул исәптән шигъриятендә дә тәнкыйди реализм агымы формалашуы раслана[3]. Т. Галиуллин билгеләвенчә, татарларда милли күтәрелеш көчәю белән, җәмгыятьнең теге яки бу чордагы кимәлен, халыкның җиһандагы урынын, тирәлек белән катлаулы мөнәсәбәтләрен үзенә туплаган милли узаң формалаша[4]. Әлеге шартлар, үз чиратында, тәнкыйди реализм агымы формалашуга йогынты ясыйлар.

Галимнәр фикеренчә, тәнкыйди реализм агымы татар әдәбиятында XIX йөзнең соңгы чирегендә формалаша, кешене әхлакый камиллеккә өндәү, башкаларга файда китерергә чакыру көче белән башка әдәбиятлардан аерылып тора. Татар әдәбиятында язучыларның тәнкыйть ярдәмендә татар җәмгыятен «йокыдан уяту», үз хәленә объектив бәя бирергә мәҗбүр итү кебек максатлары ачык күренә, яшәп

---

[1] *Бәширов Ф.К.* XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 4.

[2] Татар шигърияте: XX гасыр башы. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 4.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – 212 с.

[4] *Галиуллин Т.Н.* Милли үзаң һәм шигърият // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2000. – Б. 64.

килүче тәртипләрне инкяр итү, барыннан да элек татар җәмгыятендәге иске тәртипләрнең юкка чыгарга тиешлеген раслау кебек яңгырый. Шуңа күрә татар әдәбиятында тәнкыйди реализм кире кагуның һәм раслауның янәшәлегенә, синтезына ирешә. Тәнкыйтьләү исә аерым шәхесне түгел, тирәлекне, җәмгыятьтәге билгеле бер катламнарны игътибар үзәгенә куя[1]. Гомумән, реалистик сәнгатьтә кеше үзенең кабатланмаслыгы белән аерылып торган индивидуаль шәхес буларак каралмый, ә бәлки шәхескә иҗтимагый тирәлекнең йогынтысы мәсьәләсе беренче планга чыга[2]. Нәкъ шушы үзенчәлекләре белән ул мәгърифәтчелек реализмы һәм романтизмыннан аерылып тора да. Әгәр дә әлеге ике агымга антропологик башлангыч хас булып, шәхес үзгәрүчән иҗтимагый хәлләрдән өстен сурәтләнсә, тәнкыйди реализм шул үзгәрешләргә зур әһәмият бирә, мондый әсәрләрдә тасвирланган характер социаль детерминацияләнү принцибына буйсындырыла[3]. Шул рәвешле, алдагы гасыр белән бәйле мәгърифәтчелек идеяләре тәнкыйди реализмга нигез сала, бу исә татар поэмаларында да идея-фикер үзгәрешенә китерә. Алда билгеләп үтелгәнчә, агымдагы чор татар реалистик лиро-эпикасы мәгърифәтчелек идеяләреннән азат түгел. Й. Нигъмәтуллина тәнкыйди реализмның синкретик характерда булуын әдәбиятның тизләтелгән үсеше белән бәйләп аңлата[4]. «Гыйлемлелек, мәрхәмәтлелек макталган, әхлакый нәтиҗәләр сүз катламында кабатланган, геройларның уңай

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 78.

[2] Основы литературоведения: Учеб. пособие для филол. фак-тов пед. ун-тов / Мещеряков В.П., Козлов А.С., Кубарева Н.П., Сербул М.Н.; под общ. ред. В.П. Мещерякова. – М.: Московский Лицей, 2000. – С. 240.

[3] Литературно-эстетические концепции в России конца XIX – начала XX в. – М.: Наука, 1975. – С. 69.

[4] *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. – Казань: Изд-во Казан.о ун-та, 1970. – С. 69.

һәм тискәрегә бүленеше ачык күренеп торган»[1] мәгърифәтчелек реализмы үзенчәлекләре бу чорда иҗат ителгән поэмаларда да ачык чагыла. А. Фёдоров билгеләвенчә, мәгърифәтчелек ноктасыннан караганда, тарихи һәм иҗтимагый үсештә кешеләрнең аңы зур роль уйный, шуңа күрә мәгърифәтчелек наданлыкка, әхлаксызлыкка, дини фанатизмга каршы көрәш ача[2]. Бу көрәш XX гасыр башы татар мәдәниятендә этәргеч көч урынын били. Мәгърифәтчелек күтәргән күп кенә идеяләр татар җәмгыяте өчен бик тә актуаль булып кала[3]. Шул ук вакытта әлеге идеяләр чынбарлыкка тәнкыйди караш белән дә баетыла. Нәтиҗәдә, XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә күчеш рухында иҗат ителгән поэмалар турында сөйләү мөмкинлеге туа. Андыйларга мисал итеп Г. Рәшиди әсәрләрен китерергә була. Әлбәттә, алар сәнгати эшләнеше ягыннан да, күтәргән проблемалары җәһәтеннән дә югары таләпләргә җавап бирмиләр, әмма аның **«Ахмак хаҗи»** (1910), **«Асрау кыз нәсыйхәте»** (1911), **«Бәхетсез карчык»** (1912) кебек поэмалары аерым кеше язмышын җәмгыять үсеше белән бәйләп караулары, шәхеснең рухи яктан ярлылануын, юкка чыга баруын социаль проблема дәрәҗәсенә күтәрүләре белән тәнкыйди реализм йогынтысын тойган үрнәкләр буларак карала ала. Шул ук вакытта бу поэмалар геройларның уңай һәм тискәрегә ачык бүленеше, белемлелек, әдәп-әхлак проблемаларын калкыту кебек мәгърифәтчелек реализмы үзенчәлекләре белән дә характерлана.

Мәгърифәтчелек реализмы йогынтысын тойган поэмалар авторның дөньяга карашына мөнәсәбәттә берничә төркемгә бүленәләр. Аларның бер ишләрендә белемсезлек /

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 77.

[2] *Федоров А.А.* Введение в теорию и историю культуры: Словарь. – Уфа, 2003. – С. 206.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 191.

мәгърифәт оппозициясе алгы планга чыгарыла. Бу рәвешле язылган әсәрләрдә оппозициянең бер ягында еш кына белем алмау, мәгърифәткә ирешү мөмкинлеге булмау сәбәпле бәхетсезлеккә дучар ителгән герой тора. Каршылыкның икенче канатын исә шул геройның үкенүле уйлануларында тудырылган һәм белемлелеккә нигезләнгән идеаль яшәеш тәшкил итә. Ягъкуб Мамишевның шундый поэмага мисал буларак карала алган **«Көннекче карт»** (1914) әсәрендә уку-укыту кешенең алгарышка ирешү мөмкинлеге буларак күрсәтелә, ул – яхшы яшәешкә китерүче бердәнбер юл. Әлеге поэма XX йөз башы татар әдәбиятында зур урын алып торган кечкенә кеше проблемасын калкыта, дип әйтергә дә җирлек бар. Поэманың зур өлешендә көннекче карт гаиләсенең яшәеш-көнкүрешен ачыклаган интерьер тасвирланган бирелгән. Автор, аларның ярлылыкның соң чигендә яшәвен раслау нияте белән, көндәлек тормышка бәйле детальләрне санап бару юлын сайлый. Үзен дә, гаиләсен дә мохтаҗлыкка дучар иткән көннекче картның бу хәлгә төшүенә төп сәбәп – вакытында укымау, белем алмау. Автор бу фикерне әсәрнең башында ук ассызыклый: *Бу җәзалар бар да аңа, / Укымаудан яшь чагын. / Һөнәр кеби зур байлыкны / Өйрәнмәде ул тагын*[1]. Шул рәвешле, белемсезлек начар яшәүнең сәбәбе итеп күрсәтелә дә, әсәргә килеп кергән автор образы аркылы укучыга дидактик характердагы киңәш бирелә: *Сезгә әйтәм, и туганнар, / Укып гыйлем алыгыз. / Гыйлем-һөнәр сездә булса, / Шиксез, булыр малыгыз*[2]. Поэманың башлам өлешендә төп идея турында әйтелгәч, автор әсәрне көннекченең бер көнен сурәтләү белән дәвам итә, һәм әлеге вакыйгалар да реалистик характерда җиткерелгән идеягә буйсындырыла. Карт белән булган вакыйгалар аның даими

---

[1] *Мамишев Я.* Көннекче карт // Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 212.

[2] Шунда ук. – Б. 212.

хәл-әхвәлен тәшкил итә, һәм бу ноктада әсәр сызлану фәлсәфәсе белән баетыла. Мәгърифәтсез тормыштан чыгу юлын тапмау, белемсез, картның һөнәрсез кешенең бәхеткә ирешмәячәге турында уйланулары һәм авторның нәтиҗәләре әлеге фәлсәфәнең эчтәлеген тәшкил итә. Картның, тәмам чарасызлыкка бирелеп, Аллага мөрәҗәгать итүе сызлануны тагын да көчәйтә, яшәештә өметсезлек хакимлек итүен ассызыклый. Картның: *«И Ходаем, тәкъдиреңме / Әллә безгә шундый хәл?»*[1] – дигән риторик соравы аша автор язмыш фәлсәфәсен күтәрә һәм кешенең язмышы үз кулында, дигән фикергә килә. Карт шәрехләвендә бу идея тырмышыңны уку, белем алу аркылы гына бәхетле, мул итеп төзеп була дигән фикер белән төгәлләнә: *Гыйлем – үткен бер коралдыр, / Һәрбер эштә ул кирәк. / Гыйлем илән булмый калган / Дөньяда эш бик сирәк*[2]. Шул ук вакытта, мәгърифәтчелек реализмына хас булганча, бала тәрбияләүдә гаиләнең урыны турындагы фикер дә үткерелә. Картны кайчандыр әнисе, укыта алмыйча, байга биргән булса, хәзер аның балаларын да шушы язмыш көтә. Әсәрдә, шул рәвешле, аерым шәхес язмышын сурәтләү мәгърифәтчелек белән бәйле хакыйкатьне үткәрү ысулына әверелә.

Поэма ахырында янәдән автор образы күренү әсәрнең бетемен дидактик характерда итә: *Менә инде уйлагыз сез / Ярлыларның тормышын. / Чигә михнәт, бичаралар, / Җәй көнендә һәм кышын. / «Уйлагыз», – дип сезгә яздым / Ярлы-мескеннәр хәлен. / Булса эшегез, сез бирегез, / Кысмагыз һичбер ялын*[3]. Әлеге юллар әсәрнең тәнкыйди башлангычка ия булуы турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә (тәнкыйди реализм кешене әхлакый камиллеккә өнди,

---

[1] *Мамишев Я.* Көннекче карт // Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 217.

[2] Шунда ук. – Б. 217–218.

[3] Шунда ук. – Б. 218.

башкаларга ярдәмчел булырга чакыра[1]): авторның укучы игътибарын ярлылар тормышына юнәлдерүе, аларны кызганырга чакыруы җәмгыятьтәге тигезсезлек турында уйлану булып шәрехләнә ала. Димәк, бу әсәрдә, реалистик фикерләү тибына бәйле рәвештә, уку-укыту белән бәйле бер катламлы тормыш моделе тергезелә. Автор кешене тарихи-җәмгыяви шартларга буйсынган итеп сурәтли һәм әлеге хәлдән чыгу юлын да чынбарлыктан табарга омтыла.

Кәшшаф Хаммадовның **«Күмелгән зәкявәт»** (1914) поэмасында мәгърифәтчелек идеяләре искелек / яңалык оппозициясе аша ачыла, һәм әлеге оппозиция шәхес / тирәлек каршылыгы рәвешендә гәүдәләнә. Автор, яшь кеше язмышын сурәтләү аша, җәмгыятьтәге иске тәртипләрнең шәхесне юкка чыгаруга китерүе турындагы фикерне үткәрә. Бәхетне мәгърифәт, белемле булуда табу теләге белән янган Рәфикъның язмышын табигать белән янәшәлектә ачу үзенчәлекле алым булып тора. Иске карашлы, кадими мәдрәсә тормышының көз һәм кыш белән ассоциацияләшүе аның җимергеч ролен тагын да көчәйтә. Шул рәвешле, поэмада төп алым буларак кулланылган антитеза хыял белән чынбарлык каршылыгын нигезли. Укып, мәгърифәтле булу хыялы белән яшәгән баланың омтылышлары чынбарлыктагы тәртипләргә бәрелеп чәлпәрәмә килә.

Күп әдипләргә хас булганча, бу әсәрдә дә мәгърифәт төшенчәсен нур символы аша җиткерү күзгә ташлана. Рәфикъ төшендә бөтен дөньяны ак нур басуын, егетләр һәм кызларның, тәхеткә утырып, ай, кояш, йолдыз, гарешкә очуларын күрә. Үзе дә алтын тәхеткә бара башлауга, аны кемдер йолкып ала. Әлеге төш реаль вакыйгалар катламында интерпретацияләнә, һәм искелек тарафдарлары, кадими дин әһелләре Рәфикъны (гомумиләштерсәк – милләтне) артка

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 76.

сөйрәүче, яңалыкка каршы чыгучы көч буларак күрсәтелә. Шагыйрь тарафыннан алар кискен тәнкыйтьләнә, мондый система кире кагыла. Шулай булса да, автор хикәяләвеннән Рәфикъның рухи һәм физик үлемгә дучар булуының төп сәбәбе – гаиләдә бала язмышына битарафлык күрсәтүдән дип аңлашыла. Димәк, әсәр, мәгърифәтчелек реализмы кысаларыннан чыгып, тәнкыйди реализмга таба үсеш алган үрнәк буларак карала ала.

XX йөз башында иҗат ителеп, тәнкыйди башлангычка йөз тоткан поэмаларда төп оппозицияне искелек һәм яңарыш көрәше тәшкил итә. Яңарыш идеяләре кеше бәхете, тигезлек, рухи азатлык проблемаларын күтәрә. Татар әдәбияты шуның бер вариациясе буларак, «уку-укыту ысуллары хакындагы бәхәстән үсеп чыккан»[1] мәгърифәтчелек реализмы ярдәмендә, хатын-кыз мәсьәләсен дә әдәби мәйданга чыгара. Феминистик проблема, XX йөз башында «милләт аналары» төшенчәсе рәвешендә төгәлләшеп, бик күп әдипләр иҗатына үтеп керә. Мәсәлән, Ягъкуб Мамишевның **«Моңлы хатын Бибигайшә»** (1908) поэмасы, мәгърифәтчелек реализмына таянган хәлдә, тәнкыйди реализм башлангычын да үз эченә алып, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен гомуммилли яссылыкта карый. Әлеге әсәрдә, XX йөз башы татар сүз сәнгатендә зур урын алып торган күпхатынлылык проблемасы яктылыгында, шәхес язмышы үзәккә куела, һәм ул татар милләте турында уйланулар белән каймалап алына. Укучыга мөрәҗәгатендә автор яшьләргә үгет-нәсыйхәт бирү юлын сайлый һәм, мәгърифәтчелек идеяләрен дәвам итеп, уку, белем алу, алдынгы карашларны яклау кебек күренешләрнең татар яшьләре өчен мөһим булуын ассызыклый: *Укып җибәр китап алып, / Азрак вакыт барында. / Бушка үтмәсен бәйрәмең дә, / Аз булса да мәшгуль бул. / Якын күреп*

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 77.

*күрсәтәмен / Сиңа, туган, тугры юл. / Эшсезлектән азып китә / Безнең татар яшьләре. / Яманлыктан әрәм була / Алтын кеби башлары. / Китапханә бар түгелме / Азрак барып укырга? / Сезгә кирәк юл күрсәтү / Ничек кирәк сукырга*[1]. Шул рәвешле, шагыйрь гасыр башы татар җәмгыятенә «сукыр» дип бәя бирә, һәм мәгърифәтле яшәеше милләтне алга җибәрүче көч буларак күрсәтә. Әлеге фикер Гайшәнең иренә, балаларына, карендәшләренә әйткән сүзләрендә дә кабатлана. «Гайшә ханымның ирләргә әйткән сүзләре» бүлекчәсе исә феминистик мотивларны турыдан-туры алгы планга чыгара: *Бу дөньяның яртысын / Түгелме соң тоткан без? / Ирләрдән бар шундыйлар, / Гакылда ким, чын җүләр. / Хатын-кызлар булмаса, / Җыртык-тишек кем җөйләр. / Ир булсагыз, урныгызда / Игътибарлы булыгыз. / Хатын-кызны хур күрмәгез, / Алар түгел колыгыз. / Алар берлән уйнамагыз, / Алар түгел бит курчак*[2]. Димәк, әсәр XX йөз башы татар җәмгыятендәге тулы бер социаль катлауга – татар яшьләренә тәнкыйди бәя бирә һәм иске тәртипләрнең юкка чыгарга тиешлеген раслый. Әлеге поэманың тәнкыйди реализм рухындагы идеясе дә шуның белән бәйле: милләтне алга җибәрү – җәмәгатьчелек алдында торган төп бурыч, ә моңа аң-белемле, мәгърифәтле тормыш аркылы гына ирешеп була. Поэманың сәнгатьчә эшләнеше аны бәеткә тартым итә һәм әсәрнең лиризмын көчәйтә.

Хатын-кыз проблемасы шуңа охшаш рухта Хәтимә Усадованың **«Саф күңел»** (1912) поэмасында да сурәтләнә. Әсәрдә төп фикер, мулла улына кияүгә бирелеп, гомерен кимсетү-хурлыкта үткәргән яшь хатын монологы аша җиткерелә. Әлеге эчке сөйләм поэмада сурәтләнгән дөньяны аерым шәхес язмышына бәйле үткән / бүгенге кысаларында карау мөмкинлеге тудыра. Үткәндә калган рәхәт тормыш,

---

[1] *Мамишев Я.* Моңлы хатын Бибигайшә. – Казан, 1911. – Б. 5.

[2] Шунда ук. – Б. 17.

гамьсез яшәешкә билгесез, өметсез бүгенге каршы куела. Хатынның үзе үк әлеге бәлаләрнең сәбәбе итеп белемсезлекне, наданлыкны күрсәтә. Поэманың түбәндәге юллары исә геройның яшьләргә, бигрәк тә кызларга үгет-нәсыйхәте булып аңлашыла: *Уку кирәк һәркемгә: / Хатын-кызларга, ирләргә, / Тырышыгыз укырга / Барып ерак җирләргә. / Вакыт җиткән укырга, / Туташларым, безгә дә, / Күптән вакыт бит җиткән, / Яшь егетләр, сезгә дә*[1]. Шул рәвешле, автор, реалистик фикерләү тибына хас булганча, тормыш дөреслеген эзли һәм аны аң-белем алу белән мотивлашкан шәхес ирегендә таба.

Күренгәнчә, югарыда каралган поэмаларның сәнгати эшләнеше шактый йомшак. Алар коры тезмә дидактика рәвешен алалар, һәм авторлар идеяне әсәр тукымасында әйтеп бирү юлын сайлыйлар. Образлар системасы да укымаган бала, надынлыгы аркасында ярлы калган карт, шул ук сәбәп белән гаилә бәхете кичермәгән хатын кебек шаблон геройлардан оеша. Шулар янәшәсендә аерым бер лиро-эпик үрнәкләрдә, коры тәнкыйди сурәтләүдән читләшеп, шартлылыкка мөрәҗәгать итү омтылышы да күзгә ташлана. Шундыйлардан Зариф Бәширинең **«Поезд»** (1907) поэмасы тәнкыйди юнәлештә иҗат ителгән. Көчле позиция алып, әсәрнең исеменә чыгарылган һәм поэманы бер үзәккә туплап торган поезд образы автор шәрехләвендә җәдиди җәмгыять символы булып төгәлләшә: *Күптән илгә кайтыр идек, булса поезд, / Чана белән барсак – ерак, саргаер йөз, / Поездны охшаттым «җәдидләргә» – / Күңел салып бәйләдем билгә пояс! / Чана белән Сибириягә кылсак сәфәр, / Ул сәфәрең үз башыңа булыр сәкарь, / Шулай ук бел «кадим» белән укуны да, / Җәдидләргә инкяр кылыр булсаң әгәр!*[2] Димәк, әлеге поэма мисалында авторның яңалыкка карашын шартлы-символик катлам аркылы җиткерү

[1] *Усадова Х.* Залим тырнагында саф күңел. – Казан, 1912. – Б. 18.
[2] *Бәшири З.* Зариф Бәшири шигырьләре. – Казан, 1927. – Б. 18.

омтылышын күрә алабыз. З. Бәшири үз чорының иҗтимагый вазгыятенә бәя бирүдә дә киная юлын сайлый һәм яшәешне буран, ачы җил кебек аллегорик образлар аша ачыклый: *Көн – буран, түзеп булмый ачы җилгә, / Җитмәсә тагы юлга кар өелгән, / Ат бата, басса, кирәк, кайсы җиргә*[1]. Лирик геройның караңгылыкта адашып калуы исә, метафорик сурәт рәвешендә кабул ителеп, XX йөз башы татар җәмгыятенең юллар чатында калуына ишарә кебек яңгырый: *Бәхетсезгә каршы, юк маягы да, / Адаштык; югалттык юлны, тагы да, / Ат батты, калдык кырның уртасында*[2].

Шул рәвешле, «Поезд» поэмасында җәмгыятьне алга җибәрү белән бәйле гуманистик һәм җәмгыяви идеаллар күтәрелә. Әлеге идеал ирекле, мәгърифәтле киләчәк белән бәйле рәвештә торгызыла.

Гомумән, XX йөз башында тәнкыйди рухта иҗат ителгән татар поэмаларының үзәгендә җәмгыять яшәеше белән бәйле проблемаларны хәл итү омтылышы ята, ирекле, азат киләчәккә ирешү турындагы хыял яктылыгында мәгърифәтле яшәеш моделе тәкъдим ителә.

Алда әйтеп үтелгәнчә, тәнкыйди реализм әсәрләре җәмгыятьтәге билгеле бер күренешләрне кире кагу тенденциясенә нигезләнеп иҗат ителә, еш кына кире кагу фаш итү, көлү формасын ала. Шушы үзенчәлеккә бәйле рәвештә бер төркем әдипләр сатирага йөз белән борылалар. Яңа әдәбиятның сатира, юмор, ирония, сарказм алымнарына мөрәҗәгать итүен Д. Заһидуллина да билгеләп үтә[3]. «Начар, бозык, әдәпсез дип исәпләнгән күренешләрдән үтергеч көлүгә»[4]

---

[1] *Бәшири З.* Зариф Бәшири шигырьләре. – Казан, 1927. – Б. 17.

[2] Шунда ук. – Б. 17.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – Б. 92.

[4] Әдәбият белеме сүзлеге / төз-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 160.

нигезләнгән сатира әдипнең чынбарлыкны бозык, камил булмаган, җимерек күренеш буларак күзаллавыннан килеп чыга[1]. Татар әдәбиятында сатирик мотивлар XIX гасыр проза һәм поэзиясендә үк киң таралган. Без Г. Кандалый, Акмулла, К. Насыйри, З. Бигиев, З. Һади, Ф. Халиди, Ш. Мөхәммәдов кебек авторларның сатирик әсәрләре белән таныш. Әдәбият галиме Р. Ганиева билгеләп үтүенчә, бу чор сатирасы шәхеснең аерым характер сыйфатларын тәнкыйтьләү белән чикләнә. Ул беренче рус революциясеннән соң гына гражданлык сыйфатларына һәм иҗтимагый-сәяси әһәмияткә ия була [2]. И. Нуруллин күрсәтүенчә, яңа заман сатирасы «иҗтимагый эчтәлек ала», «тәнкыйтьче» юнәлештә үсеп китә, «тәнкыйди реализмга өлеш булып керә»[3]. Гомумән, XX йөз башы татар сатирасы җәмгыятьтәге вакыйгаларга бик сизгер, милли рух белән өретелгән, һәм алар тәнкыйди реализмның югары ноктасы буларак каралырга лаеклы.

Без өйрәнгән чор татар поэзиясендә сатирик поэмаларны төрле шагыйрьләрнең иҗатында күзәтергә мөмкин: Г. Гайнуллин-Чокалы, Давыл, Х. Исхакый һәм, әлбәттә, Г. Тукай һәм Ш. Бабич. Бу әдипләрнең барысын да милләт язмышы, аның бүгенге артталыгы, битараф караңгылыгы һәм киләчәге борчый. Алар, мәгърифәтчелек идеяләрен үстереп, җәмгыятьнең аянычлы хәленә наданлык, белемсезлек, мулла-ишан, байлар тарафыннан изелеп яшәү сәбәпче дип саныйлар. Поэмалар арасында татар әдәбияты тарихындагы традицияләрне дәвам иткәннәре дә, чоры өчен яңалык буларак карала алганнары да бар.

---

[1] Литературный энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – С. 370.

[2] *Ганиева Р.К.* Сатирическое творчество Г. Тукая. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964. – С. 8–12.

[3] *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 40–41.

Мәсәлән, Г. Гайнуллин-Чокалы үзенең **«Биш мужик»** (1910) поэмасында, җәйге бер көндә сөйләшеп утырган биш татарның сүзләренә әйткәннәргә таянып, татар милләтен артка сөйрәүче сәбәпләрне санап чыга. Поэмада күзгә ташланып торган бер үзенчәлек бар: шагыйрь, поэманы каймалап алу, биш мөстәкыйль монологны үзара бәйләп кую өчен, әсәргә автор образын кертеп җибәрә. Баштарак бәяләүче кебек ачылган образ поэма ахырында үгет-нәсыйхәт бирүчегә әйләнә. Бу – мәгърифәтчелек традицияләренең бер чагылышы буларак каралырга хаклы. Автор беренче юллардан ук инде милләтне пассивлыкта, алга, яхшылыкка омтылышы сүлпән булуда гаепли: *Шулай безнең үтә җәйләр, үтә кыш та, гомер дә үтә. / Җәһаләтебез безне шуйлә сөйләтеп, халыкны көлдертә*[1].

Биш ир монологының һәрберсе, төгәлләнгән хикәят булып, билгеле бер идеяне җиткерү максатына хезмәт итә. Бүлекләрдән күренгәнчә, алар җен күрү, аны ниндидер ысуллар белән җиңүе турында бәян итә. Биредә әлеге мифологик образ татар халкының иске хорафатларга ышануын, гомерен юк-барга табынып үткәрүен, дөньядан артталыгын исбатлау өчен кертелә. Әйтерсең, аның җеннәр белән көрәшүдән башка кайгысы юк.

Сөйләгәннәрнең чынбарлыкка туры килмәве, ягъни тышкы батырлык белән эчке куркаклык, күп белгән атлы булып күренергә тырышу белән томаналык каршылыгы әсәрдә көлке тудыруның төп алымы буларак чыгыш ясый. Һәркем үзенең кылган «батырлыгы», күргән хикмәтләре турында шул дәрәҗәдә рухланып сөйли ки, хәтта үзләре дә үз ялганнарына ышана төсле тоела. Автор да, аларны бәяләгәндә, ирония, хәтта сарказм ысулын куллана: ул башта татар ирләрен мактый-мактый да аннан соң аларның чын асылын ачып куя. Һәр монологның ахырында *«Бу сүзләрем һәммәсе*

---

[1] *Гайнуллин-Чокалы Г.* Биш мужик. – Казан, 1910. – Б. 2.

*хак, сезләрә әйтмим юри»* юлларының кабатланып килүе сөйләгәннәрнең абсурдлыгын тирәнәйтә, эчтәлек белән форманың туры килмәвен кискенәйтә генә. Бу юллар, авторның мөнәсәбәтен белгән хәлдә, капма-каршы мәгънәдә ачыла, һәм кабатлау сатира тудыруның бер алымына әверелеп китә.

Әсәр башыннан ук килгән автор комментарийлары ахырга таба интенсивлаша, үсә барып, соңгы бүлекләрдә турыдан-туры ачулану, мыскыллау дәрәҗәсенә җиткерелә, язучының мондый беркатлылыкка, томаналыкка нәфрәте арта: *Күзең күрде, ишеттең һәм, бусы тагы ниләр сөйли! / Ачып агызын сөйләп утыра, үзе белмәгәнен белми. / Газиз гомерләрнең кадерен тиеш белмичә тормаска, / Җыелышып, сөйләп җилне, лыгырдашып утырмаска*[1]. Күренеп тора: үз мөнәсәбәтен җиткерү өчен, автор гади сөйләм сүзләренә дә мөрәҗәгать итә, бу да аның шундый хәлләргә ачыну, борчылу һәм нәфрәтләнү дәрәҗәсен күрсәтүче бер чара булып тора.

Әйе, автор татар халкының аңын томалаган наданлык, хорафатларга ышану, битарафлык кебек сыйфатлардан фаш итеп, сатирик көлү белән көлә. Әмма аның көлүе шушы хәлгә ачыну белән бергә үрелеп бара, шагыйрь, XX йөз башы татар шигъриятендә актив булган йокыдан уяну мотивына мөрәҗәгать итеп, татар халкын пассивлыктан котылырга, алга омтылырга, белемгә өнди, бу халәттән чыгу юлын да күрсәтә: *Вакыт җитмәдеме безгә сикереп торырга – уйганып, / Хәлемезнең ничеклеген карарга да һәм уйланып. / Гарифлар тартса да уңга, кире без тартамыз сулга, / Тиеш безгә чыгып сулдан, керергә инде хак юлга*[2].

Шул ук авторның **«Надан ата»** (1910) поэмасы да мәгърифәтчелек идеяләрен сатирик пафоста җиткерү ягыннан игътибарны җәлеп итә. Шунысы үзенчәлекле: әсәр башында надан атаның улын ничек тә укырга җибәрмәү

[1] *Гайнуллин-Чокалы Г.* Биш мужик. – Казан, 1910. – Б. 16.
[2] Шунда ук. – Б. 16.

теләге белән бәйле рәвештә өстенлек алган сатирик яңгыраш, поэма дәвамында ирониягә күчеп, ахырда хәерхаклы мөнәсәбәт белән алышына.

Й. Нигматуллина хезмәтендә без өйрәнгән чорда сатираның үсеп китүе XIX–XX гасыр чикләрендә татар җәмгыятенең, аеруча руханилар яшәешенең комик ситуацияләргә бай булуы белән аңлатыла[1]. Бу – әдәбиятта сатирик йөзле дин әһеле образын тудыруга китерә, билгеле бер дәрәҗәдә әлеге тенденция тезмә сүз сәнгатенә дә үтеп керә. Хәбиб Исхакыйның **«Шәкерт һәм хәзрәт вакыйгасы»** (1911) дип аталган поэмасында, уңай һәм тискәре герой каршылыгы сакланып, икенче төр образ буларак аңлашылган хәзрәт моңа мисал була ала. Әлеге поэманың Г. Тукай каләменнән төшкән «Муллалар», «Мулла зары» кебек шигырьләр белән уртаклыгы зур. Поэма сюжетыннан аңлашылганча, яңача укырга омтылган, башкаларны да шуңа өндәгән шәкертне надан, байлык артыннан куудан башканы белмәгән хәзрәт мәдрәсәдән куып чыгара. Шуңа бәйләп, хәзрәтнең үткәндәге кыңгыр эшләре, укуга, белемгә булдыксызлыгы, ялагайлыгы, хәйләкәрлеге аркасында гына «зур» кеше булып китеп, хәзер балаларны надан калдыруга үзеннән зур өлеш кертүе хакында сөйләнелә. Поэманың вакыйгалар катламы әнә шуларны үз эченә ала. Шул рәвешле, әлеге образ, типиклашып, XX гасыр башы җәмгыятендә тамыр җәйгән күренешкә тәнкыйди караш ташлый. Әсәрнең сатирик пафосын җиткерү өчен, автор геройга башкалардан бәя бирдерү юлын сайлый: вакыйгалар турында үзара сөйләшеп утыручы ике карт, мулланың «изге эшләрен» (мәдрәсәдә укый алмавы, куштанлык белән мулла булуы, икенче мәхәлләгә мулла куйдырмас өчен тырышуы, сәдака гына җыеп ятуы, ашка йөрүдән башканы белмәве, мәдрәсәдән керем беткәч, кибет ачуы) санап чыгалар да, «ихлас» ышану белән *«Тырыша, һич тик тормый тәмам уңган, /*

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – С. 82.

*Башына әллә нинди эшләр тулган. / Шулай да мәктәпкә килгәлидер, / Уңган шул бу мулла, бигрәк уңган»*[1] дип куялар. «Уңган» эпитеты хәзрәтнең реаль гамәлләре белән һич тә туры килми, шул рәвешле, эчке мәгънә белән тышкы форманың каршылыгы иронияга нигез сала.

Әлбәттә, без югарыда карап үткән сатирик поэмалар камиллектән ерак. Бу, иң беренче чиратта, ижтимагый яңгырашлы сатираның татар әдәбиятында әле туып кына килүе, чор рухының, нигездә, романтик һәм модернистик әсәрләр язылуга этәргеч бирүе белән аңлатыла. Шундый шартларда сатирик иҗатта үз көчен бөтен тулылыгында ачкан Г. Тукай һәм Ш. Бабич әсәрләре югарыдагы үрнәкләр арасында камиллекләре, сәнгатьчә эшләнешләренең тирәнлеге, үтемлелеге белән аерылып торалар.

Г. Тукай иҗатын өйрәнү һәм бәяләүнең бер гасырлык бай, катлаулы, вакыты белән каршылыклы тарихы бар. Аның кыйммәтле лирикасы матур әдәбиятның, әдәбият тарихы һәм әдәби тәнкыйтьнең үсеш юлын, дәрәҗәсен билгели торган ориентир, бизмән булып торды, дип яза Т. Гыйлаҗев, шагыйрь иҗатының әһәмиятен билгеләп[2]. XX йөз татар сүз сәнгатен, чыннан да, Тукай шәхесеннән башка күз алдына китереп булмый. Әдипнең реалистик сүз сәнгатен, аерым алганда, сатираны үстерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Билгеле булганча, реалистик сәнгать халыкчанлыкка йөз тоту белән аерылып тора[3]. Г. Тукай иҗатының да төп сыйфатлары: халыкчанлык, халыкчылык, миллилек[4].

---

[1] *Исхакый Х.* Шәкерт һәм хәзрәт вакыйгасы // Исхакый Х. Милләт бакчасы. – Казан, 1911. – Б. 37.

[2] *Гыйлаҗев Т.Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 14.

[3] Основы литературоведения: Учеб. пособие для филол. фак-тов пед. ун-тов / Мещеряков В.П., Козлов А.С., Кубарева Н.П., Сербул М.Н.; под общ. ред. В.П. Мещерякова. – М.: Московский Лицей, 2000. – С. 240.

[4] *Гыйлаҗев Т. Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 15.

Шагыйрь әсәрләренең әлеге үзенчәлеген үз чорында ук Җ. Вәлиди[1], Г. Ибраһимов[2], Г. Исхакый[3] кебек әдипләр дә игътибар итә. Хәзерге чор тикшеренүчеләре тарафыннан да бу фикер алга сөрелә.

Г. Толымбай, Г. Гали, Х. Госман, Г. Халит кебек галимнәр фикерен дәвам итеп, Й. Нигъмәтуллина Г. Тукай иҗатында милли стиле формалашуының да алшарты итеп шигъриятенең халык авыз иҗатына якынлыгын күрсәтә[4]. Сатирик поэма үрнәге булган **«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»** (1908) әсәре дә халык иҗаты һәм дини мифология традицияләрен дәвам итә. Бу әсәрне өйрәнү өлкәсендә күп кенә галимнәр тарафыннан хезмәт куйган[5]. Без, әлеге поэманы

---

[1] *Вәлиди Җ.* Татар шагыйрьләре // Вакыт. – 1913. – 24, 25, 26 июль; Вәлиди Җ. Тукай хакында берничә сүз // Тукай турында замандашлары. – Казан, 1960. – Б. 259–263.

[2] *Ибраһимов Г.* Татар шагыйрьләре // Әсәрләр: сигез томда. – Казан, 1978. – 5 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Б. 74–156.

[3] *Исхакый Г.* Тукай мәктәптә // Мәктәп. – 1914. – № 6. – 10 апрель; Исхакый Г. Милли җитешсезлегебез // Сүз. – 1916. – 14, 19, 23 август.

[4] *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – С. 157.

[5] *Ганиева Р.К.* Сатирическое творчество Г. Тукая. – Казань, 1964; *Ганиева Р.К.* «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында нәзыйрәчелек һәм тамаша күрсәтү традицияләре // Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Г. Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2011. – Б. 27–29; *Нуруллин И.З.* XX йөз татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 109–111; *Халит Г.* Тукай и его современники. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. – С. 85–89.; *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – С. 168–172; *Яхин Ф.З.* «Кисекбаш» китабының мистик-мифологик эчтәлеге һәм Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы // Тукай укулары. 22 апрель 1998 ел. – Казан, 1999. – Б. 68–169; *Заһидуллина Д.Ф.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 184–189; *Загидуллина Д.Ф.* Основные мотивы в поэзии Габдуллы Тукая: отражение посвященной народу жизни // Научный Татарстан. – 2011. – № 2. – С. 46–52.

һәр яклап анализлау максатын куймастан, бары тик аның сатирик әдәбиятны үстерүгә керткән өлешен ачыклауны гына бурыч итеп алдык. XIII йөз шигъри ядкәрләреннән саналган «Кисекбаш китабы»на назыйрә рәвешендә язылган әсәрдә фантастик сюжет чор белән параллель үткәрергә, авторга татар тормышындагы аерым бер катлау кешеләрен тәнкыйть утына тотарга мөмкинлек бирә. Моңа персонажларның прототиплары булу, шул рәвешле, әсәрнең реаль җирлеккә нигезләнүе дә ярдәм итә.

Билгеле булганча, сатира үзенең сурәтләү объектын модельләштерә, образны югары дәрәҗәдә шартлы итеп тасвирлый һәм әлеге максатка реаль контурларны бозу, арттыру, гипербола, гротеск алымнары ярдәмендә ирешә. Сатирикның идеалы антиидеал аркылы чагыла[1]. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрендә Кисекбаш образы авторның антиидеалы буларак сурәтләнә, шул ук вакытта ул «Печән базары» әһелләре өчен идеал, үрнәк булып аңлашыла. Әлеге образны тудыруда Г. Тукай гротеск, гипербола алымнарын куллана. Кисекбашка хас сыйфатларны бер-бер артлы санап китү, арттыра бару, күпертеп сурәтләү татар җәмгыятендә хөкем сөргән кимчелекле якларны тәнкыйтьләргә мөмкинлек бирә. Р. Ганиева фикеренә нигезләнсәк, Карахмәт, Кисекбаш, Дию, Камчылы ишан һ. б. образларның бер җыелма образ – «Печән базары» образының – төрле вариацияләре булуы ачыклана[2]. Чыннан да, Кисекбашка бирелгән характеристиканы *(Чөнки бер мең тәгассыб бу мидә. / Бу мидә йөзләп гыйнад амбары бар, / Бу мидә мең пот сыраның пары бар. / Бу мидә бардыр җәһаләт ун вагон, / «Минбеләмлек» дәгъвасы – бер мең вагон. / «Иске – изге» фикре бардыр ун келәт, / «Һәр җәдит – кяфер» – егерме*

[1] Литературный энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – С. 370.

[2] *Ганиева Р.К.* Сатирическое творчество Г. Тукая. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964. – С. 80.

*склад...)*[1] татар дөньясындагы иске карашлы, фанатик, милләтне артка сөйрәүче кешеләр катлавына карата кулланып булыр иде. «Печән базары» төшенчәсе астында тупланган сәүдәгәрләр, шәкертләр, байлар, иске карашлы руханилар Тукай тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә. Яшәешкә бәя бирүдә ирония юлын сайлап, шагыйрь татар милләтенә «ат кәмите» атамасы белән бәя бирә: милләт кайгысын уйлап, алгарыш идеяләрен тормышка ашырасы урында, халыкның көлке-кәмит, алдау, наданлык, искелек белән гомер кичерүе турындагы фикер әсәрне иңләп үтә. Шул рәвешле, әсәрнең типиклаштыру, гомумиләштерүгә йөз тотуы аның тәнкыйди реализмга каравын дәлилли. Поэмада көлке тудыру алымнарының мул кулланылуы күренеп тора һәм сатирик көлү артында зур проблемалар яшеренүе ачыклана.

Татар әдәбият белемендә Шәехзадә Бабичны Г. Тукай идеяләрен дәвам итүче шагыйрь дип бәялиләр[2]. Н. Хисамов бу турыда болай дип яза: «Тукай һәм аны төсмерләтеп торган шагыйрьләр көчле мәктәп тудырганнар. Ул мәктәпне дәвам итүче иң күренекле талант Ш. Бабич иде. Тукай талантының ике сыйфаты да – лирика һәм сатира-юмор аңарда үзенең лаеклы дәвамчысын таба»[3]. Чыннан да, 1915–1917 еллар аралыгында иҗатының яңа юнәлешен ачкан әдип, Тукай кебек, сатира өлкәсендә олы казанышларга ирешә. Т. Галиуллин сүзләре белән әйтсәк, Ш. Бабич сатираны илаһи бер көч дип саный, табигый сәләте белән шул

---

[1] *Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. – Академик басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908). – Б. 273.

[2] *Ганиева Р.К.* Романтические мотивы творчества Шаехзаде Бабича // *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 124.

[3] *Хисамов Н.Ш.* Хәтер сагында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 53.

төргә тартыла[1]. **«Кандала»** (1916) әсәре дә шагыйрьнең әлеге юнәлештәге эзләнүләренең нәтиҗәсе булып тора. Автор үзе аны баллада дип атаса да, Р. Ганиева, Д. Заһидуллина кебек галимнәр фикеренә таянып, без аның жанрын сатирик поэма дип билгеләү ягында торабыз. Әлеге галимнәр тарафыннан әсәрнең, романтик һәм реалистик сурәт мөмкинлекләреннән үсеп, шартлылыкка мөрәҗәгать итеп язылуын да искәртәләр. Бу, чыннан да, шулай: поэма кандаланы символик образ буларак уйнатуга нигезләнә, әмма XX йөз башында төрле агымнарның бер-берсенә керешеп яшәве һәм шигърияттә сатираның, нигездә, тәнкыйди реализм кысаларында кулланылуы безгә бу әсәрне дә югарыда тикшерелгән поэмалар янәшәсендә карарга мөмкинлек бирә.

М. Гайнетдинов «Кандала» поэмасының, Тукайның «Печән базары» әсәре йогынтысында язылып, конкрет тарихи чорның кимчелекле якларын фаш итүен билгели[2]. Поэманың вакыйгалар катламы көлке итеп уйланылган хәл турында бәян итә: йоклаган Адәмнең канын эчәргә кандала килә һәм, егылып төшеп, корсагын яра. Кандалага күз теләктәшлек белдерә, ә кул исә аңа дошман буларак сурәтләнә. Кандаланың аллегорик-символик образ буларак уйланылуы әсәрне төрлечә аңларга мөмкинлек тудыра. Шунысы ачык: поэма Беренче бөтендөнья сугышы барган вакытта иҗат ителгән. Шулай булгач, биредә иҗтимагый аһәң эзләү максатка ярашлы, автор үзе үк әсәрнең шул рәвешле интерпретацияләнү мөмкинлегенә ишарә ясый: *Кып-кызыл кан белән болганган идән, / Тиңләшерлек булган ул Балкан белән*[3]. Әлеге юллардан чор вакыйгалары белән әсәрдә сурәтләнгән хәлләр

---

[1] *Галиуллин Т.Н.* Шәехзадә Бабич – сатира остасы // *Галиуллин Т.Н.* Дәгъва. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 247.

[2] *Гайнутдинов М.В.* Татарская литература зыбких времен (1917–1929 гг). – Казань: Экоцентр, 2001. – С. 32.

[3] *Бабич Ш.* Кандала // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 205.

арасында параллель үткәрелүе ачык күзаллана, «кандала йөзендә Бабич сугыш уты кабызучыларның җыелма образын тудыра»[1], поэмада «ил елау» мотивы кулланылу бу фикерне төгәлләштерә. Д. Заһидуллина билгеләвенчә, әсәр кан коючыларның язмышы кандала язмышы кебек төгәлләнәчәк, дигән фикер үткәрә.

Р. Бикбаев күз образының илдәге канкойгыч сәясәткә битараф консерватив карашлы интеллигенция, руханиларны чагылдыруын билгели[2]. Илдә барган куркыныч хәлләргә күз йому, халык язмышыннан читләшү аяныч нәтиҗәләргә китерә.

Поэмада милләт яшәеше белән бәйле уйланулар сиземләнә, Адәмнең берни белми йоклап ятуы чор әдәбиятында еш очраган йокы мотивын калкыта һәм халыкның фаҗига алдында калуы белән бәйле уйлануларга китерә. Г. Кунафин фикеренчә, бу ноктада Ш. Бабичның сатирасы трагизм белән кисешә[3].

Шул рәвешле, «Кандала»да Ш. Бабич, символик образны үзәк төшенчә итеп алып, гадәти вакыйгадан ил күләмендәге иҗтимагый хәлләргә килеп чыга һәм фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый.

Димәк, югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, XX йөз башында татар лиро-эпикасында реалистик иҗат ысулы мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализм кысаларында үзен раслады дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Мәгърифәтчелек реализмы традицияләре белән бәйле уку-укыту, хатын-кыз иреге, мәгариф мәсьәләләре, искелеккә каршы чыгу кебек

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Шәехзадә Бабичның иҗат юлы: мәгърифәтчелектән шартлы сурәткә таба // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 158.

[2] *Бикбаев Р.Т.* Современная башкирская поэма (1956–1965): дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 1966. – С. 129.

[3] *Кунафин Г.С.* Развитие жанровой системы в башкирской поэзии II половины XIX – нач. XX в.: дис. ... д-ра филол. наук. – Уфа, 1998. – С. 407.

күренешләр чынбарлыкка тәнкыйть күзлегеннән карап язылган поэмаларда да үзәк проблемаларны тәшкил итә. Шул рәвешле, XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә яңа сыйфатка күчеш рухында иҗат ителгән поэмалар турында сөйләү мөмкинлеге туа. Г. Рәшиди, Я. Мамишев, Х. Усадова кебек авторларның лиро-эпик мирасы шушы рухта. Әсәрләрнең иҗтимагый яңгырашы көчәя, аерым шәхес язмышын сурәтләүдән бигрәк, эш-гамәлләре иҗтимагый мотивлашкан образ тудыру алгы планга чыга.

Тәнкыйди реализм әсәрләренең иҗтимагый тормыштагы аерым кимчелекләрне кире кагу формасында язылуы реалист әдипләрнең сатирага йөз белән борылуына китерә. Г. Гайнуллин-Чокалы, Х. Исхакый кебек шагыйрьләр янәшәсендә Г. Тукай һәм Ш. Бабичның сатирик мирасы аерым урын алып тора.

Гомумән, агымдагы чорда иҗат ителгән реалистик поэмалар, тормышчан вакыйгага нигезләнгән бер катламлы тормыш моделен торгызып, аны уку-укыту, социаль тигезсезлек, яшәешнең авырлыгы, ямьсезлеге, аерым катлауларга караган тискәре сыйфатлар кебек мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализмга хас проблемалар яктылыгында тасвирлау белән характерлана.

## 1.2. XX йөз башы татар әдәбиятында романтик поэмалар

XX йөз башы татар сүз сәнгатендә романтизм иҗат агымының үсүе күзәтелә. Д. Заһидуллина татар әдәбиятында әлеге юнәлешнең көчәюен бер катлам татар зыялыларының идеализм фәлсәфәсе, аерым алганда, кешенең субъективлыгын үзәккә куйган И. Кант, И. Фихте, Ф. Шеллинг өйрәтүләре белән кызыксынып китүенә бәйләп карый[1].

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 18.

Татар әдәбияты дөньясына Кант фәлсәфәсе исә Гегельнең эстетик концепциясе белән бергә үтеп керә. Сәнгатьнең максатын Абсолютны хисси чагылдыруда күргән Гегель әсәрләр ярдәмендә шәхес үз-үзен танып белү юлына чыга, дип карый. Әдәбиятны «акыл сатучы» реализм кысаларыннан чыгарып, матурлык, илаһилык, хыялыйлык баскычына күчерергә теләгән татар әдәбиятчылары өчен Гегель концепциясе романтизм иҗат юнәлешен тәкъдим итәргә нигез була[1]. Шул рәвешле, романтизм эстетикасына йөз тоткан әдәби-нәзари мәктәп барлыкка килә. Д. Заһидуллина аны «рухиятчеләр мәктәбе» дигән исем белән атый[2]. Әлеге мәктәпнең юнәлешен Г. Ибраһимов, Г. Баттал, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин кебек авторлар билгели. Төп законны, мәктәп хасил итәрлек үзәк кагыйдәне Г. Ибраһимов тәкъдим итә һәм аны «Татар шагыйрьләре» китабында нәзари яктан нигезли[3].

Әдәбият дөньясында барган әлеге тенденцияләр XX йөз башы татар сүз сәнгатендә романтизм иҗат агымының ныклап тамыр җәюенә, әһәмиятле сыйфат үзгәрешләре кичерүенә нигез булып тора. Татар поэмалары да шул яктан характерлана. Романтизмның иҗади үзгәреш кичерүе лиро-эпиканы да баета.

Билгеле булганча, Европа әдәбиятлар романтизм агымы җәмгыятьтә буржуаз үзгәрешләр башлану белән бәйле рәвештә барлыкка килә һәм классицизмны кире кагудан башланып китә[4]. Әлеге агымның төрле халыкларның сүз сәнгатенә зур йогынты ясавы – кире кагылгысыз факт. Татар

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 19.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман (татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – Б. 242.

[3] Шунда ук. – Б. 208.

[4] Основы литературоведения... – М.: Московский Лицей, 2000. – С. 220–221.

әдәбияты, шул исәптән романтизм рухында үскән лиро-эпика да моннан чыгарылма түгел, әмма үз үсешендә шәркый традицияләр тәэсирен аеруча ачык тойган милли сүз сәнгатебезнең романтик әсәрләре Европа әдәбиятыннан гына үрнәк алмаган. Р. Ганиева билгеләвенчә, татар әдәбиятында традицион Шәрык тибындагы романтизм XVIII гасырларга кадәр күзәтелә[1]. Татар әдәбиятындагы романтизм, нигездә, суфичылык иҗат агымына барып тоташа. Әлеге фикерне үз чорында Г. Гобәйдуллин дә әйтә[2]. XX гасыр башы татар сүз сәнгатендә дә әлеге традицияләр саклана, шул ук вакытта М. Гафури, Н. Думави, С. Рәмиев кебек авторларның иҗаты Гареб романтизмына йөз тотуы белән аерылып тора һәм традицион шәрык романтизмы белән Европа романтизмының үзенчәлекле синтезын тәшкил итә. Шул рәвешле, Р. Ганиева фикерен нигез итеп алсак, XIX гасыр башына кадәр мөселман Көнчыгышының сәнгати-эстетик фикерләү традицияләре, суфичылык фәлсәфәсе йогынтысында үскән романтизм, әлеге гасырның уртасыннан үзенә яңа сыйфат үзгәрешләре кичереп, XX йөз башына неоромантизмга үсеп җитә[3].

Тезмә төрнең кыска жанрында – шигырьдә, романтик рух төп урынны биләп тора. Лиро-эпик әсәрләр язуга алынган әдипләр иҗатында да романтик үрнәкләр гаять күп тәкъдим ителә. Гомумән, әдәбият галимнәре романтизм чорында поэма жанрының активлашып китүен күрсәтәләр. Мәсәлән, XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә зур өлеш керткән Т. Гыйлаҗев билгеләвенчә, узган гасырның унынчы елларында романтик поэма һәм баллада жанры аеруча

---

[1] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – С. 76–77.

[2] *Газиз Г.* Сәгыйть Рәмиев шигырьләре тугрысында // Аң. – 1913. – № 11. – Б. 192.

[3] *Ганиева Р.К.* Художественные методы в тюркских литературах начала XX века // *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 55.

активлаша, аларның электән килгән традицияләре үстерелә, яңа сыйфатлар белән баетыла. Галим романтик рухта иҗат ителгән лиро-эпик үрнәкләрнең түбәндәге үзенчәлекләрен аерып чыгара: фольклор әсәрләре сюжетын иҗади файдалану, Европа һәм рус әдәбиятындагы романтик поэмаларны татарчалаштыру яисә аның сюжетын милли шартларга җайлаштырып үзгәртеп эшләү, дини мифологиягә мөрәҗәгать итү[1].

Хезмәттә иҗатлары тикшерелгән әдипләр арасында Ф. Бурнаш, Г. Рәхим, Б. Мирзанов, К. Юлдашев, Д. Гобәйди, Х. Исхакый кебек шагыйрьләрнең поэмалары романтик буяулар белән бизәлгәннәр һәм шушы агымга хас үзенчәлекләрне саклыйлар. Әлеге авторларның лиро-эпик мирасы татар милләте белән бәйле мәсьәләләрне романтик яссылыкта яктырту белән үзенчәлекле. Бу әсәрләрнең үзәк проблематикасы милли тарих, дәүләтчелек, халыкның киләчәге кебек мәсьәләләр тирәсендә оеша, һәм шул яктан бу поэмалар XX йөз башы татар әдәбиятындагы гомуми агымга кушылып китәләр.

Әлеге чорда язылган лиро-эпик әсәрләр милли теманы төрле аспектта сурәтлиләр, халык үсешен мәгърифәт, бердәмлек, азатлык кебек төшенчәләр белән бәйләп карыйлар. Шул нисбәттән, милли алгарышны аң-белемле булу белән алшартлау нәтиҗәсендә, аерым бер поэмаларда мәгърифәтчелек идеяләренең йогынтысы көчәеп киткән. Давыт Гобәйдинең **«Башкорт кызы Маһинур»** (1913) поэмасыда шундыйлардан. Поэма, эпиклыкка йөз тотып, Гәрәйнең башкортның кызы Маһинурның укырга теләве һәм шул сәбәпле әтисе белән каршылыкка керүенә нигезләнеп үстерелгән вакыйгаларны бәян итә. Әлеге әсәрдә автор идеалы рәвешендә тасвирланган Маһинур образы мәгърифәтле

[1] *Гыйлаҗев Т.Ш.* XX йөз башы татар әдәбияты тарихын укыту мәсьәләләре: Методик кулланма. – Казан: Печатный двор, 2002. – Б. 45.

киләчәккә ишарә булып аңлашыла, кызның әледән-әле шәм белән чагыштырылуы наданлык караңгылыгыннан чыгуга өмет барлыгын искәртә. Аның романтик фикерләүгә хас портреты *(Маһинур җаным иде ул кызыл гөл, / Матурлыгын сыйфатлаудан гаҗиз тел, / Каләм гаҗиз язудан һәм үзене, / Кара кашын әйтимме, ал йөзене? / Чулпан йолдызыдай янган күзенме? / Үлеккә җан багышлардай сүзенме? / Озын чәчен яки энҗе тешенме? / Әдәп, инсаф, кыланыш һәм эшенме?*[1]*)*, кызның күңел дөньясын тасвирлауга зур урын бирелүе, аның тирәлек белән каршылыкка керүе, чынбарлык ямьсезлегеннән котылу юлын тау куышындагы идеаль яшәештә *(Чәчәкләр хуш исле, тәмле иде, / Мәгарә оҗмахтай ямьле иде*[2]*)* табуы Маһинурны романтик герой буларак карарга мөмкинлек бирә. Саннар символикасына мөрәҗәгать итү *(Җиде карт утырадыр мәгарәдә,<... > / Җиде карт агарган, бик карт иде, / чәчләре карт булса да, яшьләр кебек, / Йөзләре нураный шап-шат иде, / Галим иде бу картлар, укыганнар*[3]*),* Маһинур барасы юлның тылсымлы вакыйгаларга бай булуы кебек үзенчәлекләр әсәрне экияткә тартым итә һәм аның романтик табигатен тагын да баетып җибәрә.

Югарыда әйтелгәнчә, тау куышындагы тормыш реаль яшәешкә капма-каршы куела. Шул рәвешле, автор тарафыннан идеаль яшәеш аң-белем, мәгърифәт, ирек, хөрлек, тигезлек төшенчәләренә бәйле рәвештә торгызыла. Әлеге картлар янына төрле милләт кызлары килгән, ә Маһинур – башкорт кызлары арасыннан әле беренчесе, аңа олы миссия йөкләнгән: *Якты шәмне тотып кулга, башкортларга барырсың, / Һәм беренче бирерсең син аларга гыйлем нурын, / Өйрәтерсең кызларына күзләрен ачу юлын. / Алырсың тартып*

[1] *Гобәйди Д.* Башкорт кызы Маһинур // *Гобәйди Д.* Башкорт кызы Маһинур. Төлкенең яңа хәйләсе. – Казан, 1913. – Б. 4.

[2] Шунда ук. – Б. 21.

[3] Шунда ук. – Б. 20–21.

*аларны тирән караңгылыктан, / Коткарырсың бичара хатыннарны коллыктан*[1]. Димәк, Маһинур үз милләтен алга җибәрергә, аңа яңалык кертергә тиешле шәхес итеп күзаллана. Мондый укылыш аны мәдәни герой архетибы итеп карарга мөмкинлек бирә.

Мәгърифәтче язучыларга хас булганча, шагыйрь үз әсәренә уңай геройга капма-каршы куеп сурәтләнгән Мәхмүт образын кертә. Искелек, кара көч рәвешендә гәүдәләнгән Мәхмүтнең үз апасын үтерүе схоластика, начарлыкның мәгърифәтле яшәешкә каршы торуы турында уйлануларга этәрә. Поэма ахырында нурлы кабер образының килеп керүе якты киләчәккә өмет барлыгын хәбәр итә. Әлеге бетем романтик фәлсәфәнең бер үзенчәлеге белән аңлатыла: идеаль геройның чиксез Галәмдә чикле вакыт аралыгындагы көнкүреше аны үлемсезлеккә илтүче гомер үрнәге итеп карала. Димәк, кешелек дөньясында якты көчләрнең яшәеше вакыт ягыннан чикләнгән булса да, алар сызган юл, балкыш, ак нур дөньяның, җиһанның киләчәген билгели. Романтик геройның үлеме, Шәрык фәлсәфәсендәгечә, киләчәп буыннарга яктылык, илаһи матурлык чыганагы итеп сурәтләнә[2]. Поэмадагы Маһинур образы да әлеге фәлсәфә кысаларында карала. Гомумән, без өйрәнгән чор татар сүз сәнгатендә мондый геройлар бик күп, бу – заман таләбе белән билгеләнә: инкыйлаблар, төрле тетрәнүләр кичергән халыкның яктылык, хаклык, илаһилык гәүдәләнеше булырлык идеалга ихтыяҗы зур була.

XX гасыр башы тезмә әдәбиятында романтизм чагылышы турында сүз алып барганда, Фәтхи Бурнаш иҗаты үзәк урынны алып тора. А. Әхмәдуллин билгеләвенчә, бү-

---

[1] *Гобәйди Д.* Башкорт кызы Маһинур // *Гобәйди Д.* Башкорт кызы Маһинур. Төлкенең яңа хәйләсе. – Казан, 1913. – Б. 21.

[2] *Даутов А.И.* Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. – Казан: Интелпресс, 2002. – Б. 100.

генге көнгә шагыйрьнең егерме дүрт поэмасы булуы ачыкланган. Аларның Октябрь инкыйлабына кадәргеләре һәм 20 нче елларда язылганнары романтик рухта. Ул – Урта гасырлардан бирле татар әдәбиятында юл салып барган Көнчыгыш романтизмы рухын XX гасырда да дәвам иткән авторлардан[1]. Әдипнең без өйрәнгән чорда иҗат ителгән лиро-эпик әсәрләре арасында «Казакъ кызы», «Авылда», «Дулкыннар арасында», «Габделман», «Айсылу» поэмалары романтик традицияләрне аеруча калку чагылдырулар белән аерылып торлар. Болардан тыш, Ф. Бурнаш поэмаларын романтик күзаллау ноктасыннан тикшерүгә үзеннән зур өлеш керткән галим А. Әхмәдуллин «Коркыт» поэмасын да шулар рәтендә карый[2]. Без исә, әлеге әсәрдә романтик сурәтләр булуын кире какмаган хәлдә, аны Фәтхи Бурнаш иҗатында 1917 елга кадәр шактый ачык чагылыш тапкан тагын бер юнәлеш – экзистенциализм фәлсәфәсен үзәккә алган үрнәкләр рәтендә карыйбыз.

Әдәбият белемендә оптимистик һәм пессимистик романтизм дигән төрләрне бүлеп карау кабул ителгән. Оптимистик романтизм үзенең идеалын я киләчәккә, я үткәнгә мөнәсәбәттә күрә, сайлый. Пессимистик караш вәкилләре исә рухи көрәшкә кергән ике «мин»нең бергә яшәргә мәҗбүр ителүен фаҗига дип кабул итәләр[3], төшенкелек, алдагы көнгә ышаныч сүнү – аларның даими халәте. Шушы билгеләмәләргә нигезләнгән очракта, Фәтхи Бурнаш әсәрләренең күпчелеге романтизмның икенче канатына каравын тәгаенләргә була. Шагыйрьнең поэмалары төшенкелек, язмыш алдында шәхеснең көчсезлеге, үткәннәрне кире кайтарып та, киләчәкне матурлатып та булмаячагы турындагы

---

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Фәтхи Бурнаш поэмалары // Мирас. – 2002. – № 11. – Б. 37.

[2] Шунда ук. – Б. 39.

[3] *Даутов А.И.* Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. – Казан: Интелпресс, 2002. – Б. 25.

фикерләр белән сугарылган. Әлеге үзенчәлекне А. Әхмәдуллин язмыш һәм кеше каршылыгы белән бәйләп карый. Галим фикеренчә, «Авылда», «Дулкыннар арасында», «Коркыт» әсәрләрендә фатализм идеяләре көчле. Боларда, дини ышаныч, өмет эзләп, Аллага мөрәҗәгать итү, рухи төшенкелек өстенлек итә. Язмышны фаталистик яссылыктан сурәтләү ягыннан «Казакъ кызы» да шуларга якын карала[1]. Чыннан да, Ф. Бурнаш әсәрләрендә язмыш фәлсәфәсе гаять көчле бирелә, аның герое, нигездә, язмыш каршында көчсез, нәрсәнедер үзгәртергә сәләтсез, аларда шәхес / язмыш оппозициясе алгы планга чыга. Әсәрләрне бер бәйләмгә туплаган язмыш төшенчәсе аларны XX йөз башы иҗтимагый-сәяси вазгыяте фонында карарга ярдәм итә, аерым кеше язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерә. Бу үзенчәлек шагыйрь поэмаларын модернистик әсәрләргә якынайта, аерым очракларда төп фәлсәфәгә әверелеп, аларны экзистенциаль мотивлар чагылыш тапкан үрнәкләр рәтендә тикшерергә мөмкинлек бирә.

Шагыйрьнең язмыш фәлсәфәсе ачык бирелгән лиро-эпик әсәрләре рәтеннән булган **«Казакъ кызы»** (1916) поэмасы романтизм таләпләренә җавап бирә, шул ук вакытта анда импрессионистик мотивларның да чагылыш табуын күрәбез, бу – XX гасыр башы татар әдәбиятының синтез характерында булуын раслаучы тагын бер дәлил. Импрессионистик алымнарга мөрәҗәгать итү романтизмның иҗат үзенчәлекләре белән дә бәйле. Билгеле булганча, «романтизм табигать матурлыгын культ дәрәҗәсенә күтәрә һәм шәхеснең табигать белән гармониясен тасвирлауны бер максаты итә»[2]. Импрессионизм исә, «кәеф, халәт, тойгы, кичереш һәм

---

[1] *Әхмәдуллин А.* Фәтхи Бурнаш поэмалары // Мирас. – 2002. – № 11. – Б. 38.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 158.

аларның үзгәрүен югалырга әзер мизгел кебек күрсәтүче, тышкы сурәт, кыяфәт, күренешне төсләр, тавышлар гармониясе ярдәмендә тергезүче агым»[1] буларак, геройның психологик халәтен еш кына пейзаж ярдәмендә җиткерә. «Казакъ кызы» әсәре дә, күпчелек романтик әсәрләргә хас булганча, табигать сурәтләрен җентекле тасвирлаудан башланып китә: *Моңсу тынлык... Сандугачлар сайрамыйлар, / Пырылдашып кунар урын сайламыйлар. / Тын чабында... Һич бераү юк... Яшь егетләр, / Тавыш биреп, парлап чалгы кайрамыйлар. / Яшеренем, дип, алтын кояш Каф тавына, / Кача-кача иңә урман артларына, / Уйный үзе, соң шәүләсен сибә-сибә, / Ак ярдагы матур кызның кашпавына. / Селкенмиләр агачларның яфраклары, / Селкенмиләр чәчәк, үлән сабаклары, / Уйга баткан, тулкынланмый ак Җаеккай, / Уйнамыйлар чума-чума чабаклары*[2].

А. Әхмәдуллин билгеләвенчә, романтик буяулы табигать сурәте кызның эчке кичерешен сурәтләү өчен кирәк[3]. Әлеге тасвирда тынлык төшенчәсенең алгы планга чыгарылуы ачык күренеп тора. Тынлык, татар әдәбиятында киң кулланылган образ буларак, бу әсәрдә кыз күңелендәге билгесезлекне генә белдереп калмый, аның таянычсыз булуы, кайгы-хәсрәте белән ялгыз калуы турындагы уйлануларга да этәрә. Әсәр дәвамында тынлыкның әлеге мәгънәсе, яңа сурәтләрдә гел калкып, яңадан-яңа төсмерләр белән баетыла тора һәм кыз кичерешләренә тирәнлек өстәүдә төп чараларның берсенә әверелә. Табигатьнең гамьсез тынлыгы поэма героен рухи газапка сала, җанына авырлык өсти. Тынлык – караңгылык янәшәлеге әлеге фикерне тагын да ныгыта: *Җаек буен серле тынлык баскан инде, / Тау буена*

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 90.

[2] *Бурнаш Ф.* Казакъ кызы // Аң. – 1916. – № 22. – Б. 338.

[3] *Әхмәдуллин А.* Фәтхи Бурнаш поэмалары // Мирас. – 2002. – № 11. – Б. 38.

*караңгылык яткан инде*[1]. Әлеге образга бәйле рәвештә, поэмага сызлану мотивы да килеп керә, ул, егет образына мөнәсәбәтле кулланылса да, иң беренче чиратта, казакъ кызының даими рухи халәтен чагылдыра: *Кичке тынлык яшь күңелне сызландыра*[2].

Романтиклар иҗатына ирекне яшәешнең иң төп кыйммәте дип сурәтләү хас. Ф. Шлегель үзенең бер мәкаләсендә «Иркле булу – кеше булу дигән сүз» тәгълиматын алга сөрә[3]. Романтиклар өчен кеше гомере һәм азатлык төшенчәләре аерылгысыз кыйммәтләр булып тора. Яшәеш бары тик ирек булганда гына мөмкин, ягъни хөрлеге буылган кеше шәхес була алмый[4]. «Казакъ кызы» поэмасында да кызның һәм аның энесенең эш-гамәлләре «ирек», «иреккә омтылыш» идеяләре ярдәмендә аңлатыла. Кызның үз энесен, күрә торып, дошманга каршы ялгызын җибәрүе (димәк, үлемгә этәрүе) гади үч алу белән генә түгел, ә, беренче чиратта, рухи азатлыкка, хөрлеккә омтылышының көчлелеге белән нигезләнә.

Поэма ачык беленеп торган ике өлештән тора. Беренчесендә казакъ кызының хис-кичерешләре сурәтләнсә, икенче өлештә азатлык, хөрлек идеяләрен гәүдәләндерүче төп образ буларак егет образы калка. Ф. Бурнашның милли идеалын гәүдәләндергән әлеге образ романтик геройга хас сыйфатларны үзендә туплаган: ул үзеннән күпкә зур көчләр белән каршылыкка керә, ул – батыр, көчле рухлы һәм курку белмәс. Аның куйган максатын тормышка ашырмыйча туктамаячагы, идеалына ирешү өчен, гомерен дә кызганмаячагы түбәндәге юлларда ачык чагыла: *Адәм булмыйм, шул дош-*

---

[1] *Бурнаш Ф.* Казакъ кызы // Аң. – 1916. – № 22. – Б. 339.

[2] Шунда ук. – Б. 339.

[3] *Шлегель Ф.* Эстетика. Философия. Критика: в 2 т. – М., 1983. – Т. 1. – С. 135.

[4] *Милюгина Е.Г.* Идея универсального человека в романтизме // Романтизм: грани и судьбы. – Тверь, 1998. – С. 106.

*манны табалмасам, / Кайтармасам, явыздан үч алмасам. / Казакъ булмыйм, нугай булсын атым минем, / Шул камчымны кызыл канга маналмасам!..*[1] Үч алу идеясе биредә милли азатлык, рухи хөрлек, шәхес иреге мәсьәләләре белән тыгыз үрелә. Шул рәвешле, романтик фикерләүгә хас булган – шәхес кыйммәте, аның индивидуальлеге белән бәйле ялгыз шәхес концепциясе әлеге поэма кысаларында сыйфат үзгәреше кичерә: иҗтимагый, милли, тарихи бәйләнешләрдән азат булырга тиешле герой бөтенләй башка яссылыкта ачыла, һәм шәхес хөрлеге милләт иреге белән тәңгәлләштерелә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрендә карала. Бу – XX йөз башы татар романтик поэмаларының зур күпчелеген үтәли иңләгән мөһим үзенчәлек, ул, нигездә, әдәбиятның иҗтимагый функциясе алга чыгарылу белән бәйләп аңлатыла.

Егет образына мөнәсәбәтле рәвештә, лиро-эпик әсәрдә аны халык әкиятләре белән якынайтучы акбүз ат образы уңышлы кертеп җибәрелә. Әлеге образ берничә мәгънәдә кулланыла. Беренчедән, үткәнендә бәйгеләрдә гел беренчелекне алган, тоягыннан утлар чәчкән, ә хәзер курка-курка гына атлаган акбүзат халык язмышын күз алдына китереп бастыруга хезмәт итә. Икенчедән, егетнең атка үз итеп дәшүе, аның белән сөйләшүе, алай гына да түгел, аннан көч-дәрман, кыюлык алуы егетнең үз җанына, рухына мөрәҗәгате булып кабул ителә. Бу яктан ат образы дөнья әдәбиятындагы игезәкләр архетибының бер модификациясе буларак бәяләнә ала. Шул ук вакытта, акбүз ат татар халык әкиятләреннән үк килүче тылсымлы юлдаш ролен дә башкара.

Әсәр хронотобында төн төп урынны били. Ул – төп романтик образларның берсе. Төн образының кулланылышы ике яссылыкта ачыла. Беренчедән, ул романтик геройның тормыш чынбарлыгыннан, яшәеш авырлыгыннан качу

---

[1] *Бурнаш Ф.* Казакъ кызы // Аң. – 1916. – № 22. – Б. 339.

урыны булып төгәлләшә. Гомумән, бу яктан караганда, дөнья романтизмында төн чынбарлыкка параллель дөнья, аннан ышыклану чарасы буларак та чыгыш ясый. Икенчедән, төн образы халык яшәешенә бәя кебек кабул ителә. Бу – поэманың гомуми эчтәлегенә дә туры килә: әсәр кешелек язмышындагы караңгы, югалтулардан торган газап тулы чор турында. Яктылык, нурлы яшәеш, янган кояш төшенчәләре бары тик егет уйлануларында, ретроспектив вакытка бәйле төстә генә чагылыш таба. Әсәрдәге яктылык – караңгылык һәм, шуның бер вариациясе буларак, көн һәм төн дихатомиясе романтик фикерләүдәге дуализмга бәйле рәвештә торгызыла. Яктылыкның бары тик үткәндә, халык азат, ирекле яшәгән чорда гына булуы, ә яуланган халыкның хәзер караңгылык белән характерланган яшәеше үткән һәм бүгенге каршылыгына нигез сала. Гомумән, үткәнне идеаллаштыру, аннан үрнәк-өлге эзләү – XX йөз башы әдәбияты өчен гадәти күренеш. Әлеге чорда иҗат иткән шагыйрьләр үткәндә калган мәхәббәт, дуслык, ышаныч, өмет, батырлык кебек төшенчәләрне юксыналар[1]. Әлеге поэмада да дуалистик каршылык әсәрнең төп идеясен җиткерергә ярдәм итә: рухи яктан азат халык кына бәхетле, якты гомер кичерә ала, кол дәрәҗәсенә төшерелгән, түбәнсетелгән милләт бары тик үч алу тойгысы белән генә яши һәм бетүгә дучар була. Күренә ки, идея романтизмга хас азат шәхес концепциясе белән турыдан-туры бәйле рәвештә ачыла.

Поэма язмыш җиңүен сурәтләү белән төгәлләнә. Романтик герой чынбарлыкны үзгәртә алмый, чөнки ул ялгыз. Бу очракта инде экзистенциаль мәгънә төсмере белән баетылган битараф тынлык әсәр ахырында яңадан кабатлана, шул тынлыкны кискән ат кешнәве исә геройның ачынулы җан авазы булып кабул ителә: *Әнә кинәт моңсу гына яңгырады /*

[1] *Иванова И. С.* Феномен времени в лирике Серебряного века: дис. ... канд. филос. наук. – М., 2002. – С. 147.

*Тынга калган ак Җаекның аргы ягы... / Ялгызсынып, кызганулы кешни әнә, / Яшь егетнең бәхетсезе – аргамагы...*[1]

Ф. Бурнашның **«Авылда»** (1916) поэмасында язмышның кешедән өстенлеген раслау идеясе аеруча калку гәүдәләнеш таба. Әсәрнең жанрын автор үзе баллада дип тәкъдим итсә дә, төп хасиятләре поэма үзенчәлекләренә тәңгәл килгәнлектән, бу ике жанрның якынлыгын, үзара керешеп яшәвен исәпкә алып, без бу хезмәттә әлеге әсәргә дә анализ бирәбез. Әсәр табигатьтәге гармонияне тасвирлаган идиллик сурәт белән башланып китә, романтик иҗатка тугры рәвештә, әлеге пейзаж үзәгендә – тын кич: *Матур җәй... Кичке тынлык басты илне, / Матурлап, кичке салкын кочты җирне, / Исәнләште кояш, елмайды, бакты – / Күренмәс булды шунда, ул да батты. / Азан тавышы, бөтен шау-шу килде, / Малайлар тупларын атмаска булды, / Егетләр гармунын тартмаска булды, / Берен-бере куып чапмаска булды. / Көлеп, һичбере кул чапмаска булды, / Бу салкын кичке җил исмәскә булды, / Агачлар инде селкенмәскә булды, / Сулар шау-шу килеп акмаска булды, / Асыл кошлар канат какмаска булды...*[2] Шагыйрь иҗатында киң очраган тынлык образы биредә дә традицион рухта ачыла: беренче карашка идиллия тудырырдай манзара төсле тоелган тынлык, чынында, тиздән көчле давыл булачагын, кешелеккә кайгы-хәсрәт киләчәген кисәтә.

Поэманың үзәгендә – кыз образы. Кыз портреты, романтик иҗат тибына хас булганча, искиткеч матур итеп сурәтләнгән. Матурлык дәрәҗәсен җиткерү өчен, Фәтхи Бурнаш гипербола алымына мөрәҗәгать итә: кызның чибәрлегеннән ямь алып, аларның иске генә өйләре дә нурлы булып күренә *(Бу өй нинди сөекле, нинди ямьле!..* [3]). Алай гына да түгел, аның фәрештәләргә тиң гүзәллеге каршында табигать үзе

[1] *Бурнаш Ф.* Казакъ кызы // Аң. – 1916. – № 22. – Б. 342.
[2] *Бурнаш Ф.* Авылда // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 122.
[3] Шунда ук. – Б. 122.

дә баш ия: *Менә тик шул фәрештәдән, матурдан / Оялган, һәрбере дә сәҗдә кылган*[1]. Чыннан да, романтик герой буларак тасвирланган кызның матурлыгы чиктән тыш арттырып бирелә. Әмма, билгеле булганча, романтик образ рухи матурлыкның, иҗади мөмкинлекләрнең, хисләрнең, омтылышларның күпертелеп бирелүе аркасында гына идеаль, гадәттән тыш булып күзаллана, ләкин язучы һич кенә дә образны тормыш ваклыкларыннан аерып карамый[2].

Романтикларга хас булганча, кеше күңелен табигать ярдәмендә ачу монда да урын алган[3]. Чыннан да, кызның күңел халәте шашып яуган яңгыр, дулаган давыл белән тәңгәл килә. Аның йөрәгендә сагыш булуы, җанын хәсрәт, билгесезлек телгәләве аңлашыла. Кызның хис-кичерешләрен сурәтләү, өмет – өметсезлек каршылыгында яшәвен җиткерү өчен, автор шәм образына мөрәҗәгать итә. Тәрәз төбендә «бер янам, бер сүнәм» дип янган шәм белән кыз күңеле арасында турыдан-туры тәңгәллек үткәрелә. Бу фикер аның, яшенле яңгырдан куркып, Ходайга ялвару мизгелендә тагын да ныгытыла. Кызның күңел монологы аша без бер гаилә тарихы, фаҗигасе белән танышабыз, Фәтхи Бурнаш аның үткән язмышын һәм бүгенгесен тасвирлап бирә. Балачак идиллиясе хөкем сөргән үткәндә калган бәхет, ваемсызлык, хөрлек турындагы истәлекләр ретроспекция алымы ярдәмендә торгызыла һәм ачлык-ялангачлык, билгесезлек, ятимлек коллыгындагы бүгенгегә каршы куела. Әлеге бәхетсезлекләрдә автор да, кыз үзе дә беркемне гаепләми, поэмада бу хәлләрнең төп сәбәпчесе итеп язмыш атала. Кыз язмышына берсүзсез буйсынган *(Күнеп җиттек мәшәкатькә, аңа да, / Авырлыклар да баштан үтте бар*

[1] *Бурнаш Ф.* Авылда // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 122.

[2] *Гаджиев А.А.* Романтизм и реализм. Теория литературно-художественных типов творчества. – Баку: Элм, 1972. – С. 66.

[3] *Әхмәдуллин А.Г.* Фәтхи Бурнаш поэмалары // Мирас. – 2002. – № 11. – Б. 38.

*да[1])*, ул һәр авырлыкны Ходайдан килгән сынау итеп кабул итә һәм аңа үпкә белдерми генә түгел, хәтта рәхмәтләр укый: *Ходаем! Мең шөкер булсын, сүзем юк! / Көчең зур: без бүген сау, без бүген тук*[2].

Шул рәвешле, «Авылда» поэмасы, язмыш фәлсәфәсен үзәккә куеп, язмыш сынауларына буйсынган кыз образын тудыра. Әсәрнең нигезенә салынган идея дә шушы фәлсәфә белән бәйле рәвештә ачыла: яшәештә бар нәрсә дә язмыш теләгенә буйсынган, авырлыклар – Ходай сынавы, аларны сабырлык белән үткәреп җибәрә белергә кирәк. Бу җәһәттән, Ф. Бурнашның әлеге поэмасы романтизмның пессимистик канаты кысаларына сыеша.

Романтик әдәбият матурлык категориясе белән эш итә, бу исә әдәбиятның эстетик функциясе белән турыдан-туры бәйле. А. Мәхмүтов XX йөз башы татар сүз сәнгатендә әлеге категориянең җәмгыятьнең матурлыгы, кешенең камиллеге, табигать гүзәллеге һәм сәнгатьтә торгызылган матурлык рәвешендә чагылуын билгели3. Әлеге чорда язылган романтик поэмаларның күбесе исә үткәндә калган матурлык турында уйланулар белән сугарылган. Еш кына әдипләр тарафыннан матурлыкның кешеләр кулы белән юкка чыгарылуы хакындагы идея үстерелә. Аларның күбесендә кыз образы матурлык символы буларак гәүдәләнеш таба. Мәсәлән, Мәннаф Минһаҗның фольклор мотивларын эшкәртеп иҗат иткән «Сырдәрья буенда» (1916) поэмасы, явыз үги ананың үги кызын коллыкка сатуы, кызның хурлыклы яшәештән үлемне өстенрәк күрүе турындагы вакыйгаларны сурәтләп, юкка чыгарылган гүзәллек хакындагы уйлануларын сентименталь рухта җиткерә. Алдарак

---

[1] *Бурнаш Ф.* Авылда // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 224.

[2] Шунда ук. – Б. 124.

[3] *Махмудов А.* Торжество прекрасного. – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – С. 86.

каралган «Башкорт кызы Маһинур» поэмасының үзәгендә дә әлеге идея ята.

Ф. Бурнаш иҗатында бу юнәлеш аеруча калку күренә. Шундыйлардан әдипнең **«Дулкыннар арасында»** (1916) дип исемләнгән поэмасы романтизм канатына караган әсәрләре арасында аерым урын алып тора. Әлеге әсәр яшь егетнең табигать стихиясе һәм үз-үзе (бер мизгелгә күңеленә чарасызлык иңдергән икеләнү, шөбһәләре) белән көрәшен романтик яссылыкта тасвирлый. Яшәешне тәэмин итүче төп көч буларак, табигатьтә мәңгелек көрәш баруы турындагы фикер поэмада диңгез символы аркылы ачыла: *Дулкынлана диңгез, чайкала ул, / Әллә нинди ямьсез төс биреп. / Исә җилләр, һаман ыжгыралар, / Диңгез өсләренә көч биреп. / Тәңре каргап, нәләт төшкән төсле, / Җирдә ямь юк – йоклый, булдыксыз. / Күккә баксаң, фәләк беткән төсле, / Ул да нурсыз, айсыз, йолдызсыз. / Уйнап кына болыт сөрелгәндә, / Айдан көмеш нурлар таркала. / Тау-тау булып килгән дулкыннар да / Шаулый, ак күбекләр чайкала. / Каплый тагы болыт ай нурларын, / Караңгы төн каулый яктысын. / Тагы шаулый диңгез, шаулый дулкын, / Тагы суга көчсез яр читен*[1].

Әлеге символ – егетнең табигать белән көрәшен күрсәтергә ярдәм иткән хәлдә, аның үз күңелендә кайнаган уй-хисләр тирәнлеген җиткерү чарасы да. Бу уйлар бәхетен эзләп алга барган шәхес кичерешләре белән бәйле: егет үз максатына ирешү юлының үлемгә китерәчәген дә аңлый, әмма аның күңелендәге хисләр өермәсе шулкадәр көчле, мәхәббәте шул дәрәҗәдә олы ки, ул сөйгәне белән очрашу хакына барысына да әзер. Шул рәвешле, романтик әсәр сюжетында ялкынлы мәхәббәт көрәш идеяләре белән янудан алып юкка чыгу ноктасына кадәр үстерелә, герой гамәлләренең төп мотивына әверелә. Бер караганда – тыныч, икенче караганда инде караңгылык белән көрәшкә ташланучы диң-

[1] *Бурнаш Ф.* Дулкыннар арасында // Аң. – 1916. – № 16–17. – Б. 258.

гез сыман, егет тә билгесезлек утында яна. Герой кичерешләренә фон булу белән беррәттән, диңгез образының башка мәгънәви функциясе дә бар: әлеге образ аркылы XX йөз башы рус әдәбияты өчен хас булган тенденциянең татар сүз сәнгатендә чагылышы хакында сүз алып бару мөмкинлеге туа, ул – яшәеш мәгънәсен эзләү белән бәйле. Рус галимәсе Н. Мокина билгеләвенчә, XX йөз башы рус шигърияте яңа мәгънәдә кулланыла башлаган традицион төшенчәләр белән характерлана. Диңгез образы шундыйлардан[1]. Галимә тәкъдим иткән аспекттан чыгып тикшергәндә, диңгез һәм кеше гомере (гомумән, яшәешнең) параллель кулланылуы ачыкланыр. Татар әдәбиятында да әлеге образның суфичылык идеяләре белән бәйле үз традицияләре бар. В. Брагинский фикеренчә, суфичыл традицияләрдә диңгез (океан), гадәттә, илаһи Асылны (Яшәешне) символлаштыра[2]. Д. Заһидуллина билгеләвенчә, бу укылышта җир тормышының, кеше язмышының Алла һәм Яшәеш каршында кечкенә, көчсез, ихтыярсыз булуы ассызыклана[3]. Шул рәвешле, әлеге әсәрдә егетнең диңгез буйлап йөзүе кеше яшәешенең билгесезлеге, аерым бер тышкы факторларга бәйле икәнлеген белдерә. Димәк, бу поэмада романтик әдәбият өчен хас булган юл мотивы диңгездә йөзү модификациясе төсендә чагылыш таба. Юл үткәннән киләчәккә юнәлгән, ул романтик рухтагы өмет, ышаныч белән сугарылган. Ретроспекция алымы һәм эчке монолог ярдәмендә автор геройның үткән юлы хакында сөйли: егет күп тапкырлар үлем белән күзгә-күз очрашкан,

---

[1] *Мокина Н. В.* Русская поэзия Серебряного века: концепция личности и смысла жизни в динамике художественных мотивов и образов: дис. ... д-ра филол. наук. – Саратов, 2003. – С. 327.

[2] *Брагинский В.И.* Символизм суфийского пути в «Поэме о Море Женщин» и мотив свадебного корабля // Суфизм в контексте мусульманской культуры. – М., 1989. – С. 176.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 71.

әмма аны һәрвакыт ниндидер бер очраклылык коткарып калган. Шул рәвешле, максатына юл тотучы шәхес һәртөрле авырлыкларны җиңеп чыга ала, язмыш киләчәккә ышанучыларга хәерхаклы, дигән фикер әсәрне иңләп үтә. Әлеге идеяне җиткерүдә Хозыр образы төп рольне уйный. Бу образ татар әдәбиятында Акыллы карт архетибының бер модификациясе итеп карала. Билгеле булганча, дөнья мәдәнияте үсешенең башлангыч этабында бик охшаш булган, кабатланучы образлар бар. Үсешләренең соңгырак этапларында, үзләрендә беренчел образның билгеләрен саклаган хәлдә, алар әдәбият һәм фольклорда төрлечә трансформацияләнә[1]. Әлеге төшенчә швейцарияле психолог К. Юнг тарафыннан кертелә. Ул кешенең аң төпкелен өйрәнә һәм коллектив аң төпкелендә архаик тәҗрибә берәмлекләре саклануын билгели, ягъни коллектив аң төпкеле кешелекнең үткәне турындагы архетипик хәтерне саклый[2]. Архетип, эчтәлексез форма буларак, һәрвакыт нинди дә булса тәҗрибә белән кушылып, аңлы рәвештә эшкәртелүгә дучар ителә һәм бары тик шуннан соң гына рухи эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә кулланыла башлый. Шул рәвешле, милли архетипик образлар барлыкка килә. Архетипларның нигезе борынгы мифларда саклана. Мифлар аркылы алар әдәбиятка да үтеп керә[3]. К. Юнг тарафыннан түбәндәге архетиплар аерып чыгарыла: анима (ир кеше психикасында хатын-кыз башлангычы булу); анимус (хатын-кыз психикасында ир-ат башлангычы); күләгә (психиканың, шәхеснең караңгы, үзе таныrга, күрсәтергә теләмәгән якларын белдерә); шәхсилек (индивидуаль

---

[1] *Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI в. – Казань: РИЦ «Школа», 2006. – С. 27.

[2] Введение в литературоведение: учеб. пособие / под. ред. Л.В. Чернец. – М: Высшая школа, 2004. – С. 534.

[3] *Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI в. – Казань: РИЦ «Школа», 2006. – С. 29–30.

башлангычка ия, яшәештә үз урынын табарга мөмкинлеге булган кеше); бала; бөек Ана; акыл иясе, карт архетиплары[1].

Урта гасыр төрки әдәбиятында, шул исәптән татар әдәбиятында да, карт архетибының бер варианты Хозыр-Ильяс образы аша реальләшә. Ул кешеләргә юл күрсәтүче, ярдәм итүче, җәза бирүче мәңгелек юлчы буларак тасвирлана. Әдәбият галимнәре аның әдәби әсәрдә өч вазифа башкара алуын күрсәтәләр: сакраль (җәза бирүче, коткаручы, юл күрсәтүче), иҗтимагый (тормыш һәм рухи тәҗрибәне саклаучы, үлеләр белән тереләр арасында арадашчы, алдан күрүче, шаман), әдәби (милли йолаларны саклаучы, философ, изге һәм дөньяви төшенчәләр, явызлык һәм яхшылык арасында арадашчы)[2].

«Дулкыннар арасында» поэмасында исә юлдан тайпылган, сайлау алдында калган романтик герой, Хозыр белән очрашудан соң, үзенә көч ала, рухи ныклыкка ия була. Шул рәвешле, бу поэмада карт архетибы белән тәңгәл килгән мифологик образ традицион сакраль вазифа үти: ул билгесезлектә калган егеткә матди (көймә) һәм рухи (үз-үзеңә ышаныч һәм киләчәккә өмет) ярдәм бирә, юл күрсәтә, коткара. Әсәрнең төп идеясе дә Хозыр монологы аша җиткерелә: *Юлыңда бул, кулда көч барында, / Алга бар, тик кара алдыңы*[3].

Романтик геройның алга барыр юлы матурлыкка омтылу булып аңлашыла. Хан кызына булган мәхәббәте егеткә авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Матурлык символы буларак ачылган Хан кызы образы үткәндә калган гүзәллек турындагы уйлануларга этәрә. Кайчандыр бәхет-сәгадәттә гомер кичергән кыз, әтисенең тәхетен югалтуыннан куркуы

[1] Введение в литературоведение / под ред. Л.В. Чернец. – М.: Высшая школа, 2004. – С. 534.

[2] *Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI вв. – Казань: РИЦ «Школа», 2006. – С. 118.

[3] *Бурнаш Ф.* Дулкыннар арасында // Аң. – 1916. – № 16–17. – Б. 259.

аркасында, читкә сөреләә, шайтан коллыгына ташлана. Тормыш ямен югалткан егет тә читтә гомер кичерә. Димәк, кемнәрнеңдер үз мәнфәгатьләрен өстен куюы сәбәпле, җирдә матурлык юкка чыга, гүзәллекне тоеп, аңа омтылып яшәүчеләр исә мәңгелек газапка дучар ителә. Шул рәвешле, поэмада бүгенге һәм киләчәк үткәнгә каршы куела, романтик әдәбиятка хас булганча, үткән – бүгенге дихатомиясе үзәк урынны алып тора. Үткәндә калган матурлык хакында сызланулы уйланулар ямьсез бүгенге аша өметсез киләчәккә юнәлтелә. Әлеге фикер әсәрнең соңгы юлларында аерым калкытыла: *Өзелә таң җилләре... Җылый, сыкрый, / Искәртәләр моңнар, зарларын. / Иренеп кенә диңгез җавап бирә, / Сугып ташлый биек ярларын*[1].

Бу юллар, диңгезгә ташланып, шайтан коллыгыннан котылырга тырышкан егет белән кызның язмышы аяныч тәмамланачагына, димәк, җиргә матурлыкның әле тиз генә иңә алмаячагына ишарәли.

Ф. Бурнашның без өйрәнгән чорда иҗат ителгән лиро-эпик әсәрләрен анализлау аларда романтик мотивларның байлыгы-төрлелеге, аерым бер образларның әдип иҗатында әсәрдән әсәргә күчүе (тынлык, язмыш) күзәтелә, язмышның шәхестән өстенлеге расланып бара. Шул рәвешле, әсәрдә хакимлек иткән язмыш фәлсәфәсе берничә яссылыкта ачыла: кешенең язмыш белән көрәшергә омтылуы, язмышны үзгәртү мөмкинлегенең юк дәрәҗәсендә булуы һәм, ниһаять, язмыш каршында көчсезлек. Шагыйрьнең романтик поэмалары чор поэзиясендә экзистенциаль мотивлар белән сугарылган, фаталистик идеяләрне гәүдәләндергән төркемне тәшкил итә. Аның әсәрләре, XX йөз башы татар поэмаларында хөкем сөргән иҗтимагый-сәяси рухтан бераз читләшеп, аерым кеше, шәхес күңеле, язмыш, яшәү мәгънәсе,

[1] *Бурнаш Ф.* Дулкыннар арасында // Аң. – 1916. – № 16–17. – Б. 262.

матурлык югалу кебек проблемаларны үзенең сурәтләү объекты итә.

Әлеге чорда романтизмның билгеле бер сыйфат үзгәрешләре кичерүе әдәбиятның иҗтимагый функциясе арту белән дә аңлатыла. Мәсәлән, Г. Гыйльманов романтик әдәбиятка хас ике дөнья бирелешенең социаль яңгыраш алуын билгели һәм Б. Мирзановның **«Инкыйлаб»** (1916) поэмасын мисал итеп китерә[1]. Чыннан да, бу әсәр ике катламлы тормыш моделен үзенчәлекле рәвештә ачар омтыла. Әсәрдә чынбарлык һәм идеаль яшәеш берлеге реальлек һәм күл асты тормышы мисалында тергезелә. Чынбарлык *җил, караңгылык, атмас таң* кебек ачкыч сүзләре ярдәмендә күз алдына китереп бастырыла. Бар дөньяны каплап алган яңгыр артыннан таң атуын көтеп яткан лирик герой образы (*Карганып, әрнеп ятам күккә карап таңны көтеп!*[2]) XX йөз башы татар шигърияте өчен хас таң символик образы белән бәйләнештә карала. Билгеле булганча, әлеге чорда яңа тормыш төзү идеясе, яшәештәге позитив үзгәрешләр әдәбиятта нәкъ менә яңа көн туу символы ярдәмендә ачыла. Моның иң ачык мисалы – С. Рәмиевнең «Таң вакыты» шигыре. Бу символның өмет, ышаныч белән бәйле мәгънәсе әлеге поэмада да сәнгати үстерелә, шул ук вакытта өмет мәгънәсе «якты ай туу» тезмәсе ярдәмендә дә җиткерелә. Бу – романтик фикерләү таләпләре белән аңлатыла, чөнки әлеге агым кысаларында төн чынбарлыктан качу урыны булып кабул ителә. Якты ай туу мотивы күл төбендә гомер кичергән хатыннар галәме белән турыдан-туры бәйләнештә карала: *Кемдә гамь, күңеле сынык, кил, килче, без күңелең ачыйк, / Кил, кирәк кем бул. Өметсезме яки дәртле гашыйк. / Без барында курыкма, бел: юк кайгы-зар, көенеч сиңа, / Без күзең бәйләп үлемнән,*

[1] *Гильманов Г.Х.* Татарская баллада. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – С. 40.

[2] *Мирзанов Б.* Инкыйлаб // Аң. – 1915. – № 7. – Б. 101.

*сөйлимез сөенеч сиңа. / Нәкъ көмеш безнең тавыш, ул синдә ни барсын куар, / Һәм караңгы күкрәгеңдә шунда якты ай туар!*[1]

Шул рәвешле, яшәеш ямьсезлегеннән ышыклану урыны идеаль яшәеш моделе буларак тәкъдим ителгән күл төбендә табыла. Күл тормышын якты буяулар белән сурәтләү ярдәмендә, автор тарафыннан идеаль җәмгыятькә хас асыл сыйфатлар барлана һәм укучы хөкеменә тапшырыла: *Анда дөнья балкый нурда, аңкый хуш ис гөл генә, / Анда ишетелә моңлы саздан бер сихерле өн генә. / Анда нур балкый, түгелгән анда ак таң нурлары! / Анда нурлар сипкәли күктә ае, йолдызлары! / Анда сазлар патшасы былбыл, тутый, ак күбәләк, / Барысы шат, уйный, көлә, барысын сөя изге мөлек. / Анда сүнми, яктыра күк солтаны ак кына да ай, / Мәңге сүнмәскә аңа кушкан булыр, бәлки, Ходай. / Кыскасы: шундый нәфис, нечкә, тисәң берсен генә, / Юк булыр барысы, укып өрсәң дә бер әфсен генә!*[2]

Идеаль яшәешне бу рәвешле сурәтләү XX йөз башы татар сүз сәнгатендә мифик, ягъни үткәнгә мөнәсәбәтле романтизмның чагылыш табуы турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Үткән заман романтизмы чынбарлыктан еракләшу кебек аңлашыла, чөнки ул яшәешнең җимерелүен, юкка чыгуга таба баруын гәүдәләндерә. Шәхес еш кына бу тормышның җимергеч көчләреннән үзе уйлап чыгарган, хыялдагы әкияти дөньясына китәргә мәҗбүр була[3]. Мифик романтизм хакында А. Лосев хезмәтләрендә тулы бер өйрәтү бар[4]. «Инкыйлаб» поэмасында романтик герой үзенең рухына гамьсез тынычлык тапкан әкияти дөньяны реаль яшәеш белән бәйләп торган образ – көзге. Дөнья мифоло-

[1] *Мирзанов Б.* Инкыйлаб // Аң. – 1915. – № 7. – Б. 102.

[2] Шунда ук. – Б. 102.

[3] *Даутов А.И.* Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. – Казан: Интелпресс, 2002. – Б. 26.

[4] *Лосев А.* Ф. Бытие. Имя. Космос. – М.: Мысль, 1993. – 958 с.

гиясендә, төрле халыкларның фикерләвендә әлеге предмет чын яшәешне параллель дөньяга бәйләүче чара буларак күзаллана[1]. Бу әсәрдә исә көзге образы, романтик фикерләү төренә буйсындырылып, дөньяның ике катламы арасында канал, бәйләнеш ролен үти башлый: ул геройга тарихның канлы сугышлар белән бәйле фаҗигале сәхифәләре турында сөйли: *Мин күрәм үткән тарихның пәрдәсен ул көзгедән, / Башкаларга нисбәтән йөземез бүген ямьсез нидән. / Күз ала алмыйча торам мин, әй торам тик аптырап, / Шундагы чиксез тарихның дәһшәтеннән калтырап*[2]. Бу сугышта дөнья тоткасы булган картның җиңелүе һәм үлеме киләчәккә бәйле бөтен өметне юкка чыгара: *Ауды. Шуннан соң бары бердән мамыктай бәйләнеп, / Очты китте шунда барысы җил белән, көлгә әйләнеп*[3]. Реаль яшәештән, сугышлар барган чынбарлыктан күл төбенә килеп чыккан бәхетсез хатынның җимерелгән, юкка чыгарылган шәһәр турындагы ачыну тулы монологы вакыйгаларның кабатлануын искәртә, яшәешне караңгылыкка, бетүгә бару рәвешендә тасвирлый.

Автор әлеге торгынлыктан чыгу юлын да күрсәтә, ул аны мәгърифәт белән бәйләп карый *(И, җир бер балкысын! Без, әйдәгез, шәм яндырыйк! / Мәгърифәт, хикмәт белән күзләрне без нурландырыйк!* [4]*)* Шул рәвешле, Б. Мирзанов халыкның киләчәген аң-белем белән бәйли, әмма хатыннар галәме оештырырга теләгән инкыйлабның тормышка ашмавы һәртөрле ышанычның юкка чыгуга дучар ителүе турындагы фикерне тагын бер кат раслый. Димәк, XX йөз башы татар лиро-эпикасында әйдәп барган өмет – өметнең юкка чыгуы структурасы бу әсәрне шәрехләүдә төп терәк булып тора.

---

[1] *Вовк О.В.* Энциклопедия знаков и символов. – М.: Вече, 2006. – С. 430.

[2] *Мирзанов Б.* Инкыйлаб // Аң. – 1915. – № 7. – Б. 110.

[3] Шунда ук. – Б. 110.

[4] Шунда ук. – Б. 113.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, без өйрәнгән чор әдәбиятында реализм һәм романтизм иҗат агымы саф төстә сирәк очрый. Нигездә, алар бер әдәби әсәр кысаларында кушылып китә һәм модернистик элементлар белән баетыла. Моны Р. Ганиева да билгеләп үтә[1]. Татар әдипләре, нигездә, импрессионистик алымнарга мөрәҗәгать итә, суфичылык чорларыннан ук актив булган символларга, ачкыч сүзләргә таяна, ә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, милләтнең киләчәге турында уйланулар экзистенциаль мотивлар белән баетыла.

Иҗат агымнарының үзара бәйләнеше турында башка милләт галимнәренең дә фикерләре кызыклы. Мәсәлән, рус әдәбиятчыларының күпчелеге романтизмның символизмга турыдан-туры яки читләтеп тәэсир итүен раслый, кайбер галимнәр, әйтик, В. Севостьянова әлеге йогынтыны абсолютлаштыру дәрәҗәсендә фикер йөртә[2]. Й.Г. Нигъмәтуллина, татар һәм рус әдәбиятларын чагыштырма планда өйрәнеп, Урта гасырда һәр ике әдәбиятта да дөньяга карашның романтик төре өстенлек итүен күрсәтә. Сурәт тудыру алымы буларак символларның еш кулланылуын романтизмдагы асыл сыйфатларның берсе дип раслый[3].

Чыннан да, романтик төшенчәләрнең символик иҗат үрнәкләрендә кабатлануы – гадәти күренеш. Шулай ук романтизмның да тотрыклы символлар системасы билгеле. Гомумән, әлеге агым символларга бик теләп мөрәҗәгать итә. XX йөз башында иҗат ителгән татар поэмаларында бу тенденция шулай ук ачык чагылыш таба, аерым бер үрнәкләрдә

[1] *Ганиева Р.К.* Художественные методы в тюркских литературах начала XX века // *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 56.

[2] *Севостьянова В.С.* Архетипика романтического двоемирия в поэтике русского символизма: дис. ... канд. филол. наук. – Магнитогорск, 2004. – С. 5.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань: Фэн, 1997. – С. 63.

төп фикер тотрыклы образлар аркылы җиткерелә. Шулай да символлар бу поэмаларда үзәк төшенчә булып кабул ителмиләр, аларның үзәгендә романтик лирик герой тора. Шунлыктан, алар романтизм агымына кертеп карый да. Мәсәлән, шундыйлардан Гали Рәхимнең лиро-эпикасы романтик символлар кулланылу, алар аркылы фәлсәфә үткәрү мөмкинлеге тутыду ягыннан аерылып торалар. Бүгенге көн укучысына әдипнең ике поэмасы килеп җиткән. Аның символларга бай **«Баллада»** әсәре 1915 елда дөнья күрә. Баллада жанры үзе – фантастик сюжетлы, тарихи яки легендар эчтәлекле, героик-романтик характердагы лиро-эпик әсәр[1]. Гадәттә, аңа трагизм, драматизм һәм фаҗигалелек хас[2]. Уңышлы баллада чорга хас зур мәсьәләләрне, халык тормышында урын алган әһәмиятле вакыйгаларны, күренекле эпизодларны сайлап ала, һәм моның белән генә дә чикләнми. Шул вакыйганың, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтнең иң киеренке, иң мөһим һәм күп очракта драматик коллизияле моментын үзәккә куя да, аны ачык төсләре тирә-якка сирпелеп, ямь биреп торган куе эмоциональ буяулар аша калку итеп сурәтли, «гаҗәеплеге» белән күңелгә сеңә торган үзенчәлекле характер тудыра[3]. Әлбәттә, Г. Рәхим әсәрендә дә әлеге сыйфатларның кайберләре күзәтелә, әмма әлеге әсәрне без поэма жанрына кертеп тикшерү ягында торабыз, чөнки ул үзенең жанр хасиятләре белән нәкъ менә шушы төргә якын.

Берничә әдәби катламның синтезы төсендә иҗат ителгән «Баллада» әсәренең нигезенә бер сугыш батыры

[1] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Раннур, 2002. – Б. 207.

[2] Литературная энциклопедия терминов и понятий / под. ред. А.Н. Николюкина. Институт научной информации по общественным наукам РАН. – М.: МПК «Интелвак», 2003. – С. 69.

[3] *Галиуллин Т.Н.* Балладаларыбыз турында // *Галиуллин Т.Н.* Яңа үрләр яулаганда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – Б. 87.

турындагы легенда салынган. Әлеге легенда мифологик катламны тәшкил итә: ул – кырда булган гаять көчле, канлы сугыш турында. Сугыш кырын – үлем кырын караңгы төн каплагач, карга-козгыннар, үлеләрдән шаркылдап көлгән төсле каркылдаша-каркылдаша, үле сугышчыларның күкрәкләренә менеп басалар, үлем калдырган байлыкны бүлешергә тотыналар. Кара кашлы, кара күзле бер сугышчы егет берүзе исән калган, чыдап булмаслык сусау аның йөрәген яндыра. Г. Рәхим үзенең әлеге әсәрендә романтизмга хас каршы кую алымын төп композицион принцип итеп ала да реаль чынбарлыкны һәм егетнең хыялын – рәхәт, идеаль яшәешне – җентекләп тасвирлый. Үлем хәбәрчеләре козгыннар тавышына капма-каршы куеп сурәтләнгән чишмә чылтыравы оҗмах билгесе буларак кабул ителә.

Реаль һәм идеаль дөньяның романтизмга хас каршылыгы поэманың нигезенә салынган легенданың ике өлешкә бүленүендә дә ачык күренә. Беренче өлеш югарыда аталган үлем дөньясы – чынбарлык турында булса, икенче кисәктә егетнең саташулары рәвешендә идеаль яшәеш – оҗмах тәкъдим ителә.

Үзе дә шартлылык үрнәге буларак кабул ителгән легенда поэмадагы шартлы-символик катламны аңлауга җирлек әзерли. Бу катламның үзәгендә егет образы тора. Ул батырлык һәм, гомумиләшеп, кешелек символы буларак ачыла. Әлеге образны төгәлләштерүдә, җентеклерәк тасвирлауда автор импрессионизмга хас сурәтләү алымнарыннан да мул файдаланыла, алар егетнең кичерешләрен кискенләштерү, тирәнәйтү максатына хезмәт итә. Г. Рәхим табигать тавышлары, төрле авазлар, музыкаль аһәңнәр аша егетне әйләндереп алган чынбарлыкны укучы күз алдына китереп бастыра. Әлеге чаралар шулай ук егетнең эш-хәрәкәтләрен үткенрәк җиткерүгә дә хезмәт итә. Беренче өлештә, сугыш кыры тасвирланган абзацта, шаркылдап көлгән козгын

тавышы батырның үлем хөкем сөргән далада япа-ялгыз калуын, яраларының бик нык сызлавын, чыдап булмаслык сусаудан газаплануын реаль буяулар белән күз алдына китереп бастыра, һәм укучы күңеленә тетрәндергеч тәэсир ясый. Карга-козгыннарның шомлы, явыз, мыскыллы көлүләренә чишмә тавышы каршы куела дидек. Чишмәнең челтерәп агуы оҗмах тавышына тиң, ул яшәүгә өмет уята: *Кинәт шунда, ерак түгел, агачлар арасында, оҗмах тавышы шикелле татлы бер тавыш ишетте ул: чишмә ага иде анда, шуңарга таба китте ул*[1]. Чишмә образы биредә егетне матурлыкка өндәүче символ, яшәеш чыганагы буларак ачыла. Чишмә – дөнья әдәбиятында сафлык, яшәеш символы буларак билгеле. Биредә ул ике яшәеш чиген аңлата һәм яшәүгә юл булып кабул ителә. Егетнең әлеге чиккә барып җитә алмавы аның үлемгә дучар булуына ишарәли.

Романтик үзенчәлекләрнең импрессионистик алымнар белән баетылуы егетнең халәтенә табигатьнең мөнәсәбәтен белдергәндә дә ачык чагыла. Табигать аңа теләктәш: әйләнәтирә күңелсезлек, моң пәрдәсенә төренгән: *Усак яфраклары җилгә: «Җилбер, җилбер, җилбер», – диләр; җил югында җилбердәшеп, әйтерсең лә җил телиләр. Нидер бер-берсенә алар акыртын гына сөйлиләр, яралының колагына моңлы көйләрен көйлиләр*[2]. Табигать күренешләрен җанландыру алымына мөрәҗәгать итеп тасвирлау хикәяләүче авторның да егеткә булган мөнәсәбәтен җиткерергә ярдәм итә.

Әсәрдә вакыйгалар барган сугыш кыры хронотопның шартлылыгын билгели һәм бөтен Җир шары моделе булып аңлашыла башлый. Димәк, җирдә сугыш, үлем, үтереш, кан кою, кешеләрнең гомерен өзү – даими халәт. Егетнең хыялындагы сурәт тә бөтен эчтәлеге белән шартлы: ул матурлык, гүзәллек дөньясын күрә, ә матурлык күктән иңә.

---

[1] *Рәхим Г.* Баллада // Аң. – 1915. – № 23–24. – Б. 394.

[2] Шунда ук. – Б. 394.

Бу исә безгә поэмада романтизмга хас җир / күк бинар оппозициясе турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Үлем, караңгылык, ачлык гәүдәләнеше булган җир матурлык, рухи тынычлык хөкем сөргән күккә каршы куела. Күк тормышын сурәтләгәндә, автор төсләр символикасына мөрәҗәгать итә, бу дөньяны ак төскә төреп бирә, биредәге һәр нәрсәдән аклык, пакьлек, чисталык бөркелә: баскычлар – ак мәрмәрдән, кызлар ак асылга чорналганнар, кулларында – ак лаләләр... Бу рәвешле тасвирлау реаль һәм идеаль тормыш каршылыгын тагын да кискенләштерә, шул ук вакытта ак төс бакыйлык турында уйлануларга да этәрә.

Җир тормышын сурәтләгән катламда үзәк символ буларак егет образы калыкса, күк тормышының үзәгендә кыз тора: *Баскыч буйлап моңар таба югарыдан төшә бер кыз. Мәхәббәтле караш белән карый моңар бу матур кыз. Кигән киеме бу гүзәлнең һава кебек зәңгәр атластан, алтын таҗы башындагы, тукылган якут-алмастан*[1]. Бу юллардан кызның матурлык символы булуы ачыклана. Әлеге фикерне ныгытуда авторның кабатлау алымына мөрәҗәгать итүе дә зур роль уйный, «матур» сүзенең кыска гына өзектә берничә мәртәбә кабатлануы аның гадәти сурәтләү чарасы гына булмавын ачыкларга, кызны матурлык символы дәрәҗәсенә күтәрергә ярдәм итә. Егетнең аңа бер күрүдән гашыйк булуы да гаҗәп түгел. Әнә шул рәвешле, Г. Рәхим, символистларга хас булганча, әфләтун мәхәббәтен өстен куя, тормыштагы куркыныч вакыйгалардан, кан коеш, сугыш афәтеннән котылу юлын бары тик чын сөю, рухи якынлык аша гына табарга мөмкин, дигән фикер үткәрә. Герой рухи мәхәббәт, саф сөю аша гына яшәешнең тирән серен – матурлыкны ача, яшәү мәгънәсен таба. Шул рәвешле, рус символистлары иҗатында аеруча калку гәүдәләнгән «абсолют шәхес» идеясе биредә дә билгеле бер дәрәҗәдә чагылыш таба.

---

[1] *Рәхим Г.* Баллада // Аң. – 1915. – № 23–24. – Б. 394.

Кыз кулындагы чәчәк тә символик яссылыкта кабул ителә. Чәчәк, бигрәк тә кызыл чәчкәләр, әдәбиятта элек-электән мәхәббәт символы булып йөри. Кызлар кулындагы ак лаләләр дә, баскычка сибелгән кызыл гөлләр дә – матурлык һәм мәхәббәт символлары алар. Егетнең алтын тәхеткә менәр юлы – мәрмәр баскыч та кызыл гөлләр (мәхәббәт һәм сөю дип уйлыйк) белән түшәлгән. Әдип, шул рәвешле, күңелендә илаһи мәхәббәткә урын булган, сөю кадерен белгән кеше генә чын матурлыкны аңлый ала, дигән фикер үткәрә.

Кыз егеткә гәүһәр савытка салынган шәраб бирә. Шәраб – борынгы Шәрык әдәбиятыннан килгән символ, ә суфи шагыйрьләр өчен ул илаһи гыйшык билгесе булып тора, илаһи мәхәббәт касәсеннән шәраб эчеп исерү – алар тормышының төп мәгънәсе[1]. Г. Рәхим дә, әлеге традицияне дәвам итеп, шәрабне мәхәббәт билгесе буларак тасвирлый. «Алтын» эпитеты белән бирү, гәүһәр касәгә салу мәхәббәтнең никадәр кыйммәтле, кадерле булуына ишарә: *Эчкәннән соң шәрабны ул, таралганнан соң канына, ак канатлы җиңел шатлык иңә батырның җанына. Рәхәт тынлык, бәхетлелек урнаша күкрәгенә һәм гаҗәп ләззәт тула аның йөрәгенә. Тоела аңар, гүя ул нур дөньясына баткан төсле. Ишетелгән күк була аңар акрын гына бер моңлы көй; гаршеләргә алып менеп китә аның рухын бу көй...*[2] Г. Рәхим биредә дә, егет күңелендә мәхәббәткә бәйле туган хисләрне сурәтләү өчен, импрессионистик алымнарга мөрәҗәгать итә. Баштагы ямьсез тавышларның инде эзе дә калмаган, матурлык, гүзәллек дөньясына аяк атлаган егетнең күңелендә ниндидер бер тынлык, бәхет урнаша. Ул үзен нурга чумган кебек тоя: *Тоела аңар, гүя ул нур дәрьясына баткан төсле, нурдан*

[1] *Сибгатуллина Ә.Т.* Суфыйчылык серләре (төрки-татар шигъриятендә символлар, образлар, атамалар). – Казан: Матбугат йорты, 1998. – Б. 349.

[2] *Рәхим Г.* Баллада // Аң. – 1915. – № 23–24. – Б. 394.

*булган дулкыннарда тирбәнеп ул яткан төсле*[1]. Суфичылык әдәбиятыннан килгән нур мотивы егетнең батырлык белән яуланган якты үлемен генә түгел, ә үлемнең дөнья газапларыннан котылу чарасы буларак та кабул ителүен дә нигезли. Каяндыр акрын гына ишетелгән бер моңлы көй шундый яшь көенчә үлемгә дучар ителүенә кайгырып сызланган егетнең күңел моңы булып кабул ителә, ләкин хыялында туган сурәт аның авыр яраларын да оныттыра, үлеме дә җиңел кебек тоела, шул нур дәрьясына илтүче юл төсле кабул ителә. Димәк, егетнең язмышы күккә ашу белән төгәлләнә. Әлеге моментта әсәр романтик әдәбият өчен хас булган юл, хәрәкәт мотивы белән кисешә. Романтиклар өчен юл лирик геройларның ике дөнья чигендә яшәеш формасын чагылдыра һәм шәхеснең үзен бар иткән абсолют башлангычка кайтуы рәвешендә күзаллана. Төп хәрәкәт исә упкынга (диңгез), югарыга, киләчәккә һәм Аллага кайту рәвешендә бара[2]. Соңгы шәрехләү исә суфичылык традицияләре рухына туры килә һәм шунлыктан XX йөз башы татар романтик поэмаларында да сәнгати эшкәртелә. Гали Рәхимнең «Баллада»сында да егетнең үлеме гадәти, табигый хәл буларак кабул ителә һәм, һәркемнең тормышы мәңгелек хәрәкәттән гыйбарәт булып, соңгы тукталышы Аллага кайту икәнлеген искәртә. Поэманы болай шәрехләү аның суфичыл үзенчәлекләргә ия булуы турында фикер йөртергә җирлек әзерли. Шул рәвешле, поэмада егетнең ике дөнья – фани һәм бакый дөньялар киселешендә калуы романтик поэтика үзенчәлекләренә туры килә. Егетнең чынбарлыкта кичергәннәре һәм саташулы уйланулары дуализм принцибына нигез сала. Поэмада авторның суфичылык символикасына мөрәҗәгать

---

[1] *Рәхим Г.* Баллада // Аң. – 1915. – № 23–24. – Б. 394.

[2] *Севостьянова В.С.* Архетипика романтического двоемирия в поэтике русского символизма: дис. ... канд. филол. наук. – Магнитогорск, 2004. – С. 67.

итүе кешенең Аллаһка булган мәхәббәтен дә чагылдыра һәм Аллаһка мәхәббәт авырлыктан, ямьсезлектән коткарачак, дигән фикергә этәрә.

Фәлсәфи катламда авторның сугышлар тудырган ямьсезлек турында борчулы уйланулары чагыла. Романтиклар яшәешнең асылы дип билгеләгән хаклык, яхшылык һәм матурлык триадасын җәмгыятьнең үз куллары белән юкка чыгаруы хис катламында үзәк урынны биләгән ачыну катыш сагыш хисенең төп сәбәбен билгели.

Әсәрдә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе модернистик әсәрләрдәгечә хәл ителә. Сугыш барган җир тормышы көрәш, суеш мәйданы кебек кабул ителә, ә «теге» дөнья аклык, нур тулы урын, рәхәтлек чыганагы буларак күзаллана. Мондый чишелеш үлем – йокыга китү янәшәлеге аркылы оеша һәм «кешене яшәеш ямьсезлегеннән коткаручы үлем хакындагы концепция»[1] белән кисешә. Поэмада батыр егетнең үлеме, матур кыз белән җитәкләшеп, мәрмәр баскычтан күтәрелү, моңлы көйгә ияреп, җанының күккә ашуы рәвешендә күрсәтелә. Мондый әсәрләр кешенең үлемсезлеген раслый, яшәешне җир тормышы һәм күккә ашу (үлем) бөтенлеге итеп күзаллый.

Гали Рәхимнең **«Яу»** (1916) поэмасы да символик образларга таянып язылган һәм берничә катламны үз эченә ала.

Беренче өлештә егетнең сугышуы күрсәтелә. Очсызкырыйсыз даладагы күл буенда яшәгән халык, үгезләрен җигеп, бүтән җиргә китәргә әзерләнә. Кинәт дала ягыннан яу килгәне күренә; җилкенеп, атлар дулаша башлый, барча халык куркуга төшә: ана – баланы, бала ананы белмәс хәлгә җитә. Батырларга үзләренең кемлеген күрсәтергә җай чыга: дала сөңге бәрелешкән, ук сызгырган тавышларга күмелә.

---

[1] *Кузьмичева Н.В.* Мотив сна в поэзии русских символистов (на материале поэзии Ф. Сологуба): дис. ... канд. филол. наук. – Ярославль, 2005. – С. 154.

Күкбулат исемле егет тә сугыша. Яшьләр көлкегә калмыйк дип тырышалар, башларын томан басып, күзләрен кан каплый. Алар өчен бу беренче һәм соңгы сугыш була: егетләр далада мәңгегә ятып кала.

Еллар үтә... Инде күл дә кипкән, кайчандыр монда сугыш булуы да онытылган. Бу тирәдә адәм сөякләре генә кояшта ялтырап ята. Алар – үткән елларның, монда булган канлы сугышларның телсез шаһитләре. Кайчакта бу урыннан атлы юлчы узгалый, ул һаман алга бара, ә артыннан баш сөякләре ямьсез итеп көлеп кала. Шулай итеп, үткәннәр белән бүгенгенең кисешү урыны булган дала образы поэманың каршылыкка нигезләнгән хронотобын билгели. Бик күпләрнең соңгы йортына әверелгән, батырлар каны белән сугарылган дала – ачы фаҗигаләр шаһите – аянычлы үткән белән өметсез бүгенгене тоташтыру ноктасына әйләнә. Әдипнең беренче әсәрендә дә дала символына мөрәҗәгать итүе моны тагын бер кат раслый.

Поэмадагы шартлы-символик катлам Күкбулат образын милләт символы буларак ачыклый. Бу образ бирелешендә татар халкын һәлакәткә китергән төп сәбәпләр барлана: гайрәт, батырлык белән янәшә йөргән мин-минлек, алдагысын уйлап бетермәү, таркаулык. Шул рәвешле, билгесез чор сугышын тасвирлаган лиро-эпик әсәрендә автор үз чорында татар халкының таркаулыкта яшәве хакында уйлана. Даладагы күчмә тормыш белән көн итүче халык – турыдан-туры безнең бабаларыбызга ишарә итә. Гали Рәхим тарихның әнә шул борынгы чорларыннан ук инде милләтнең көрәшеп яшәргә дучар булуын сөйләргә тели. Сугыш – милләтне юкка чыгаручы, киләчәген бетерүче: *Исте җилләр, үтте еллар, булмаган төсле булып, / Илне – яуны алды үлем фани дөньядан йолып. / Кипкән инде күл дә хәзер, һич азы да калмаган, / Күл төбен дә бөдрә яллы каты «кылган» каплаган. / Җәй көнендә ул урында тик рәшәләр калтырый, / Җирдә*

*яткан ак сөякләр тик кояшта ялтырый*[1]. Биредәге күл образы шулай ук символик мәгънәгә ия. Ул татар милләтенең аянычлы үткәнен, бетүгә дучар ителүеннән туган фаҗигале хәлен чагылдыра. Еллар үтү белән, күл кипкән, шул күл юкка чыккан төсле, халыкның сугыш афәте турындагы хәтере, тарихы да онытылган...

Әйе, татар милләтенең язмышы фаҗигале, ләкин аның төп фаҗигасе сугышып яшәүдә, күпләп кырылуда түгел, ә үзенең хаталарыннан сабак ала белмәүдә. Курку белмәс батырлары булган халык, сукырларча алга гына ыргылу, масаю кебек сыйфатлары аркасында үлемгә дучар ителгән. Шулай дәвам итсә, аның киләчәге булмаячак. Поэманың фәлсәфи катламы әнә шул фикерне алга сөрә. Ул юлчы образы аркылы ачыла. Җирдә күмелмичә яткан исәпсез сөякләр дә юлчының күңеленә тәэсир итми, аны уйландырмый. Хәтта аның аты да нидер сизенеп пошкыра, калтырана, аяк астындагы күгәргән калкан шалтыравы йөрәккә шом сала, ул да юлчыны кисәтергә, үлемнән йолып калырга тели кебек, әмма җайдак бернигә дә игътибар итми, бары үлемгә баруын гына белә, сөякләрнең, калканнарның телсез кисәтүен ул аңламый. Автор күңелендә туган борчылу хисенең дә төп сәбәбе шул. Шагыйрь үткәргән фәлсәфи фикер соңгы ике юл белән ныгытыла: *Алмый искә үләсен, юлчы һаман алга бара, / Аның арты баш сөякләр көлеп-ыржаеп кала*[2].

Шул рәвешле, үзенең поэмаларында Г. Рәхим, үткәнгә мөрәҗәгать итү юлы белән, милләтнең киләчәге турында уйлануларын чагылдыра. Үткән / киләчәк бердәмлеге милләтнең бетүгә юлы булып кабул ителә. Әсәрдә мәгънәсез сугышлар милләтне юкка чыгармасын иде, тарихтан сабак ала белсәк иде, дигән фикер үзәккә куела, тик авторның бу уйлары уңай хәл ителми, икенче поэмадагы бер

[1] Рәхим Г. Яу // Аң. – 1916. – № 24. – Б. 375.

[2] Шунда ук. – Б. 375.

тайпылышсыз алга баручы юлчы образы шуны раслый. Милләтнең хәзерге торышы, таркаулыгы, авыр язмышының сәбәпләрен Гали Рәхим аның үткән тарихыннан эзли, шул вакытларда да үз ялгышыннан сабак ала белмәвенең аяныч нәтиҗәләргә китерүе турында искәртә. Әлеге фикерне үткәрүдә төрле символлар үзәк урын алып тора.

Гомумән, әдәбият галимнәре билгеләвенчә, матурлык турында хыял белән көнкүреш ваклыкларының тәңгәл килмәве, иллюзия-хыялларның җимерелүен аңлау һәм шуның белән бергә идеалга омтылу, аңа ышану романтик сәнгатьнең асылын тәшкил итә[1]. Әлеге үзенчәлекләр XX йөз башында татар халкының иҗтимагый тормышына, яшәешенә аеруча туры килгән. Идеалларның юкка чыгуы, Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең деградацияләнүе, шулар нәтиҗәсендә милләтнең киләчәгенә өмет югалу – болар барысы да әлеге чорда иҗат ителгән романтик поэмаларның күпчелегендә чагылыш таба. Без моны югарыда иҗатларына күзәтү ясалган әдипләрнең әсәрләре мисалында ачык күрдек.

Татар сүз сәнгатендәге романтик әсәрләрнең тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге – татар халкының милли тарихы, рухи азатлыгы белән бәйле тарихи шәхесләрне төп сурәтләү объекты итеп алу. XX йөз башында иҗат ителгән татар поэмаларының да бер катламы тарихи җирлеккә нигезләнеп язылган. Иҗтимагый-сәяси вазгыять белән бәйле рәвештә, татар әдипләре Болгар, Казан ханлыгы чорына йөз белән борылалар, Чыңгыз яуларын сурәтлиләр. Халыкның милли азатлык хәрәкәте белән бәйле рухи халәтенә Сөембикә, Чыңгыз, Чура батыр кебек тарихи шәхесләр образы аеруча якын була. Шул ук вакытта, абсолют төгәллеккә, хаклыкка дәгъва итмәгән хәлдә, алар тарихи үткәннәрне бүгенге яшәеш белән

[1] Основы литературоведения....– М.: Московский Лицей, 2000. – С. 227.

бәйләп куюлары ягыннан кызыклы. Поэмаларда сурәтләнгән тарихи шәхесләрнең күпчелеге символ дәрәҗәсенә күтәрелә һәм әсәрне символизм агымы кысаларында тикшерүгә җирлек әзерли. Романтик әдипләр исә иҗтимагый тетрәнүләрне аерым герой язмышы, күңел кичерешләре аша ачу юлына басалар.

Чор поэмаларының күпчелегендә иҗтимагый аһәңнең беренче урынга чыгуы мәгълүм. Романтик иҗат үрнәкләре дә әлеге тенденциядән читтә кала алмый. Шуңа мөнәсәбәтле, XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләргә карата идеяләр романтизмы дигән төшенчә кулланыла. Бу очракта романтизм иҗат методының реалистик үзенчәлекләр белән баетылган булуы күздә тотыла. Идеяләр романтизмы кысаларында карала торган әсәрләргә рациональ һәм публицистик башлангычларның алга чыгуы хас. Татар әдәбиятында ул милләт язмышына бәйле уйланулар булып төгәлләшә[1]. Әлеге агымга хас дөньяны үзгәртү, чынбарлыктан качу идеясе шагыйрьләргә чор вакыйгаларына, иҗтимагый-сәяси вазгыятькә үз бәясен бирергә мөмкинлек тудыра. Мәсәлән, XX йөз башында Беренче бөтендөнья сугышы белән бәйле мәгълүм вакыйгалар тәэсирендә халыкта билгеле бер дәрәҗәдә азатлыкка омтылыш көчәю, милли үзаң үсү, әлбәттә, сүз сәнгате үсешенә дә йогынты ясамый калмый. Шушы елларда милләтнең азатлык, ирек символлары дәрәҗәсендә кабул ителгән шәхесләрен үзәккә алган поэмалар бер-бер артлы мәйданга килеп, милли тарих темасы алгы нәүбәткә чыга. А. Әхмәдуллин да поэмаларга шул елларның иҗтимагый тормышындагы мохитнең йогынтысы зур булуына игътибар итә. Галим билгеләвенчә, гомумгражданлык һәм милли азатлык хәрәкәтенең җанлануы поэма жанрының активлашуын

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 255.

китереп чыгара[1]. Әлеге тенденция тарихи җирлекле романтик поэмалар язылуга да сәбәп була.

Романтик әдипләрдән тарихи темага төрле яссылыкта Фәтхи Бурнаш, Кыям Юлдаш, Гариф Шәрифи кебек авторлар мөрәҗәгать итә. Еш кына тарихи вакыйгалар фольклор мотивлары белән баетыла, төрле легендаларга нигезләнә. Зәйнәп Сәгыйдәнең **«Бикчәнтәй бабай»** (1915) әсәре, мәсәлән, «Пугач хакында Каргалы легендасы» дип искәртелә. Биредә «усал, нурсыз, кара йөзле» Пугачев шәхесенә тискәре бәя бирелә һәм, аңа капма-каршы буларак, «нурлы» эпитеты белән характерланган Бикчәнтәй бабай образы сурәтләнә. Нур образы әсәрнең буеннан-буена кабатланып килә һәм ил тынычлыгы, халык иреге өчен яшәүне тормыш максатлары иткәннәр турында уйлануларга китерә. Нурлы йөзле кешеләрнең нурлы йорт – мәчеткә җыелуы, шунда күңелләренә тынычлык табулары исә кан кою, сугышларның дин тарафыннан да тыелган гамәл булуына басым ясый. Үтереш, суеш хөкем сөргән яшәеш символы рәвешендә кабул ителгән көз образы чор вакыйгаларына ишарә итә. Шул рәвешле, легенданы сәнгати эшкәртү нәтиҗәсендә, һәртөрле сугышларга каршы чыгу белән бәйле гуманистик идеяне җиткергән әсәр иҗат ителгән.

Кыям Юлдашның **«Чура батыр»** (1916) поэмасы төркитатар халык авыз иҗатыннан билгеле образны милли идеал дәрәҗәсендә сурәтли. Казан шәһәрен салу турындагы риваятьләргә нигезләнгән әлеге поэмада төрле каршылыкларны җиңәргә сәләтле батыр тасвирлана. Гипербола алымы кулланылып, Чура батыр әкият каһарманнарына туры килерлек романтик герой буларак ачыла: *Илләрендә күп икән бик көчле, гайрәтле юан, / Зур батырлар, дошманын еккач аталган пәһлеван. / Шул шәһәрдә бар пәһлеваннан да өстен*

[1] *Әхмәдуллин А.* Фәтхи Бурнаш поэмалары // Мирас. – 2002. – № 11. – Б. 37.

*зур батыр, / Хәйләле, эшлекле, гайрәтле икән – Чура батыр. / Җәйге көн чыккан Чура, безнең батыр, бер иртәдә, / Билгә балта кыстырып, урман кисәргә киртәгә. / Көн буе йөргән урман кисеп, урманда кешеләрне суыра / Торган аждаһа очравыннан курыкмыйча батыр Чура. / Туктамый кискән агач, кискән саен арткан көче, / Шак та шок бәргән тавыштан тетрәгән урман эче / Бу тавыштан куркынып, барлык еланнар «аһ» йота*[1].

Чура батырның дошман пәһлеваннарын бик ансат кына җиңүе, юха белән көрәштә өстен чыгуы, күлдә тулып яткан куркыныч еланнарны юк итүе геройның чиксез көчкә ия булуы турындагы фикерне тагын да үстерә килә. Батырның идеаллаштырылган сурәте милләтнең үзен саклап калырлык, башкаларны үзе артыннан ияртә алырлык каһарманнарга мохтаҗлыгы турындагы идеяне җиткерә. Вакыйгаларның Казан шәһәре белән турыдан-туры бәйләнеше идеяне тагын да конкретлаштыра, татар халкы белән бәйләп куя. Шул рәвешле, тарихи дөреслекне сурәтләү максат итеп куелмастан, курку белмәс, батыр, рухи яктан нык герой чор идеалына тәңгәл китерелә. Авторның милләт киләчәге белән бәйле өмете әнә шундый шәхесләрдә, әмма поэма ахырында экзистенциаль тенденциянең көчлелеге (Чура батыр, язмышыннан уза алмыйча, тып-тыныч бер көндә елан чагуыннан һәлак була) әлеге ышанычның сүнүе хакында сөйли.

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, XX йөз башы татар әдәбиятында, шул исәптән романтик лиро-эпикада да, чор тудырган милли фаҗиганең сәбәпләрен ерак тарихтан эзләү иң актуаль темаларның берсе булып тора. Күп кенә әдипләрнең иҗат мәсләген, татар тарихының сугышлар кичергән дәверен сурәтләү аша, үз чорының мәгънәсез кан коюларына тәнкыйди бәя бирү; тарихның кабатлануын искәртеп, халыкны бердәмлеккә өндәү; сугышлар, таркаулыкның

[1] *Юлдашев К.* Чура батыр // Аң. – 1916. – № 5. – Б. 76.

һәрвакытта да милләтне юкка чыгарачагына ачынып чаң кагу кебек мәсьәләләр тәшкил итә. Ф. Бурнашның әлеге проблемаларны аерым шәхес язмышы аркылы ачу юнәлешендә язылган «Айсылу» поэмасы һәм аңа охшаш «Габделман» әсәре бер үк мәсьәләне ике яссылыктан чагылдыруы белән игътибарны җәлеп итәләр.

**«Айсылу»** (1918 елда басылган) поэмасында Казан ханлыгының руслар тарафыннан яулап алынуы китергән хәсрәт, кайгы, сагыш хисләре татар әдәбиятында билгеле булган Айсылу язмышы аша гәүдәләнеш таба. Композицион яктан поэма реалистик һәм романтик агымнарны үзендә берләштерә, һәм язмыш, вакыт хакында уйлануларны үз эченә алган фәлсәфи башлангыч турында да сүз алып барырга мөмкин.

Лириклыкка йөз тоткан «Айсылу» романтик поэмасы хронотопның үзенчәлекле булуы белән аерылып тора. Реалистик катламда, сурәтләнеләчәк вакыйгаларга кереш рәвешендә, Ф. Бурнаш рус дәүләтенең Чыңгыз тарафыннан яулап алынуы турында бәян итә. Рус халкы бөтен җиһанны буйсындыра килгән Чыңгызны «дәҗҗал», «күктән иңгән газап», «җен» дип атый. Халык, бу афәттән коткаруын сорап, Аллага мөрәҗәгать итә, яуга каршы торып карый, әмма барыбер колга әйләндерелә. Автор фикеренчә, халыкны коллыкка төшерүче төп сәбәп – таркаулык: *Төрле ханнар бер дә юкка үзара / Берсе-берсен төртешергә кузгала. / Ызгышалар, тузышып яклаш китә... / Кайсыберсе кан түгә дә, баш кисә... / Шатланып читтән караучы күршеләр / Белделәр дә көч җыеп өлгерделәр*[1]. Шартлылыкка мөрәҗәгать итеп, автор шушы вакыйгалардан кинәт кенә Казан ханлыгы чорына күчә: берничә гасыр алга китә. Монда инде хәл башкачарак: рус патшасы татарларның язмышына кул суза. Беренче сугыш сурәтендә романтик буяулар өстенлек

[1] *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 6.

итсә *(Тик бу тылсымлы җегетләр каушамый, / Ук түгел, атсаң да төзләп Каф тавын[1]),* Казан ханлыгы өчен барган яу тулысы белән реалистик, хәтта урыны белән натуралистик сурәтләрдә тасвирлана: *Тукта бу ни? Алда нинди манзара? / Нинди ялкын, нинди ут соң, ни яна? / Ник халык шашкан, кыямәт көн кебек? / Ник төтен соң, ник караңгы төн кебек? / Нишлиләр соң, анда нишләп ызгыйлар? / Шаулыйлар ник, каулыйлар? Ни эзлиләр? / Тукта, нәрсә? Ах, бу нинди куркыныч! / Анда сугыш, ялтырый алмас кылыч... / Күрче: «Җау бетсен!» дә «Җау бетсен!» диләр, / Күр: һавада уйный үткен сөңгеләр... / Уйныйлар анда мөкаддәс җан белән... / Былчырыйлар җир йөзен яшь, кан белән... / Каршылап вәхшәт белән тәңре таңын / Агызалар ал таңда пакь инсан канын...*[2]

Шул рәвешле, элеге тарихи моментлар белән XX гасыр башында барган вакыйгалар арасында параллель үткәрелә. Поэмада сурәтләнгән орыш манзаралары Беренче бөтендөнья сугышы китергән авырлык, михнәткә ишарә булып аңлашыла. Укучы, тарихи хронотоптан читләшеп, үз чорына бәя бирә, XX гасыр башында барган вакыйгалар турында уйлана. Тарих кабатлана, халык үз хаталарыннан сабак ала белми, дип ачына автор.

Реалистик катлам сугыш вакыйгаларын тасвирлый һәм Айсылу исемле татар кызының анасы белән фаҗигале аерылуы, аның, үткәне турында берни дә хәтерләмичә, рус кенәзе йортында үсүе, шуннан качып китүе кебек вакыйгалар белән дәвам иттерелә.

Әсәрдә төп урынны алып торган романтик катлам Айсылу образы белән бәйле. Кыз кенәз йортында рәхәт, гамьсез-борчусыз гомер кичерә, үзенең туган милләте, әнисе белән аерылу хәлләрен оныта. Зиһене оныта, әмма җаны, хәтере – юк. Романтик катламда Айсылуга бәйле сызлану

---

[1] *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 4.

[2] Шунда ук. – Казан, 1918. – Б. 6.

һәм ашкыну мотивлары үзәккә куела: *Тик алай да кайвакыт күңеленә / Нәрсәдер төшкән булып ул җилсенә, / Җитми аңа нәрсәдер, ул азсына, / Тарсына ул барчасыннан, ятсына, / Күңеле нәрсәләр сизгән була... / Әткәсеннән, әнкәсеннән ятсына, / Белми ул, тик кайдадыр очмак тели, / Кемнедер ак күкрәге кочмак тели, / Тарланып, бу зур сарайлардан бизә, / Каядыр китмәк тели ул мәңгегә*[1]. Җан ашкыну, очу мотивы Айсылуның үткәнен исенә төшерәчәгенә, хәтере уяначагына өмет тудыра.

Романтик катламны автор импрессионистик буяулар исәбенә баетып җибәрә, Айсылуның хис-кичерешләре, уйланулары янәшәсендә табигатьнең дә аның белән бергә сызлануы, кызга хәерхаклык күрсәтүе ачыла. Чишмә челтерәве, сагышлы җил, карт каен шаулавы, чәчкәләр сөйләшүе булып, табигать үзе кызның күңелендә үткән турындагы хәтерне уятырга омтыла сыман. Айсылу үзе дә моны сизә, әмма сәбәбен аңлый алмый: *Ник минем хакта һаман сүз йөртәләр, / Кызганып сызлауларын белгертәләр?*[2] Табигать сурәтләре поэманың Айсылу белән бәйле өлешен башыннан ахырына чаклы иңләп ала. Ахырдан, таулар, агачлар, чишмәләр, ислам диненә йөз тоткан кызны элекке кыйбласы өчен кичерүен сорап, Аллага мөрәҗәгать итәләр.

Романтик катламның ачкыч сүзе булып тавыш тора. Бу сәер, серле тавышны бары тик Айсылу гына ишетә. Башта ул аның нәрсә әйтергә теләвен аңламый, әмма соңрак, үсеп җиткәч, тавыш аңа ачыктан-ачык ишетелә башлый: *Әй, кыз бала, / Бу дворецлар сиңа үрнәк түгел, / Тормышың – тормыш, көнең һәм көн түгел; / Әллә кай җирдән, еррактан, тын гына / Бер тавыш бар ич сиңа әкрен генә, / Анда, ул*

---

[1] *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 10.

[2] Шунда ук. – Б. 11.

*җирдә, сиңа ак көн генә, / Елмаеп анда синең бәхетең көлә*[1]. Әнә шул рәвешле поэмада, югалган, онытылган хәтерне яңартып, аң төпкеленнән тавыш калка. Мәгънәсе, вазифасы романтик катламда ачылган төш ярдәмендә Айсылуның үткәннәре белән бәйле хәтере тагын да ачыклана төшә. Төштә дини мифологияләрдән килгән Хозыр сурәтенә кергән хәтер сөйли: *Тарсынасың син, фәрештәм, бик белеп, / Әллә кайларда илең, халкың күреп. / Мондагы байлык сиңа кер, былчырак, / Анда керсез, күренә тик зур елтырап. / Монда ятлар, анда барысы дусларың, / Бар да үз халкың, туганың, үз каның*[2]. Бу поэмада карт архетибы буларак гәүдәләнгән Хозыр юллар чатында адашып калган, тормышта үз асылын таба алмыйча сызланган, рухи газап кичергән Айсылуга юл күрсәтә, ягъни бу әсәр мисалында әлеге образ үзенә хас сакраль вазифаны үти: коткара һәм ярдәм итә, дөрес юлга чыгара: *Туктаңыз, чү! Әллә шулмы? Әйе... шул... / Шул... Миңа ул изге карт күрсәткән ил... / Юл... күңел сизгән ерак илнең юлы... / Изге юл... Сахра... Матур диңгез буе... / Анда шатлык... Анда үз халкым минем...*[3]

Поэманы каймалап алган юл хронотобы берничә мәгънәви һәм эстетик яссылыкта ачыла. Беренчедән, ул – Айсылуны туган иленнән аерган һәм анда алып кайтачак юл. Икенчедән, ул – Айсылуның хәтерсезлектән хәтергә кадәр үткән юлы. Өченчедән, ул – хаклыкка ирешү, хакыйкатьне төшенү юлы. Юлның өченче мәгънәсе суфичылык әдәбиятыннан ук килгән тынлык образы ярдәмендә төгәлләштерелә. Гомумән, XX йөз башында әдипләр тынлык образына еш мөрәҗәгать иткәннәр һәм аңа төрле мәгънә биргәннәр. О. Мандельштам фикеренчә, беренчел тынлыкта

---

[1] *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 11.

[2] Шунда ук. – Б. 11.

[3] Шунда ук. – Б. 16.

яшәү чыганагы тупланган. Ул тынлык образын диңгез күбегенә тиңли, ә борынгы грек мифологиясе буенча, диңгез күбегеннән матурлык алиһәсе Афродита яралган. Шул ук вакытта шагыйрь чиксез ялгызлык тоя, үзен дөнья болгавырыннан ярга чыгарып ташланган «энҗесез кабырчык» кебек хис итә. Шушы чагыштыру белән, галәм тынычлыгы кеше язмышына гамьсез, битараф дигән фикерне алга сөрә. Аныңча, галәм тынлыгы образы үз эченә тормыш матурлыгын һәм шул ук вакытта аның фаҗигалелеген дә ала икән[1]. «Айсылу» поэмасында тынлык хакыйкать мәгънәсендә килә, ә хакыйкать исә кешенең тоткан кыйбласы, дине, тарихи хәтере белән бәйләп аңлатыла. Гомумән, төрле чорларда иҗат итүче романтикларны тормышның романтик концепциясен раслау берләштерә. Үзләренең иҗат үзенчәлекләренә, фикерләү юнәлешләрендәге аерымлыкларга карамастан, алар барысы да һәртөрле материаль байлыкны, чынбарлыкны кискен кире кагалар һәм кешенең рухи дөньясын бердәнбер хакыйкать, кыйммәт итеп күтәрәләр[2]. Бу поэмада хакыйкать мәгънәсендәге тынлык образы шушы концепцияне раслауга буйсындырыла. Автор, шул рәвешле, милләт темасын дин проблемасы белән бергә бәйләп куя, ул татар милләтен саклап калуның бер шарты буларак динне саклауны күтәрә, ә дин ул – гореф-гадәтләр бөтенлеге, буыннардан буыннарга тапшырыла килгән традицияләр, рухи бәйләнешләр, вөждан, намус, хәтер, киләчәк дигән сүз. Айсылуның шул хакыйкатькә төшенүе, димәк, тормышта үз вазифасын аңлавы нур мотивы ярдәмендә җиткерелә: *Кулдагы тәресен идәнгә ташлый ул... / Шулвакыт өстендә ак нур ялтырый... / Айсылу курка, дерелди, калтырый... /*

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – С. 113.

[2] *Гуляев Н.А*. О формах романтической типологии // Романтизм: Грани и судьбы. Ч. 1. – Тверь, 1992. – С. 11.

*Күренәләр алда туган-үскән җире, / Урнаша күкрәккә пакь ислам дине...*[1]

Димәк, романтик катлам милли азатлык идеясен хәтер, дингә тугрылык проблемалары белән бәйләп куя. Айсылу образы исә, символик югарылыкка күтәрелеп, татар халкының милли азатлыкка, рухи хөрлеккә омтылышы булып тәгәлләшә, XX йөз башы татар сүз сәнгатендә туган яңа идеал – нәби буларак гәүдәләнә. Рухи терәкне шул рәвешле тарихтан эзләү, үткәнне идеаллаштыру тенденциясе – XX гасыр башы сүз сәнгатенә өчен хас күренеш[2]. Ф. Бурнаш та милли бәйсезлек проблемасын узганнарны сурәтләү аша күтәрә, бүгенгене һәм үткәнне кисештереп, язмыш, тарих, милләт турында уйланулар белән бәйле фәлсәфи башлангычка нигез сала. Әдип язмышның аяусызлыгы, кешенең язмыш алдында көчсезлеге хакындагы фикерләрен Чыңгыз явыннан җиңелгән халыклар мисалында җиткерә. Автор фикеренчә, дөнья гел бертөрле генә тормый: бүген син – җиңүче, иртәгә – кол: *Уйный язмыш, көлдерә, шатландыра; / Күп тә үтми, көйдерә дә яндыра, / Нишлисең, инсан – табигатьнең колы, / Уйный шул, көн бирми шул ул коргыры...*[3]

Милләт турында уйланулар поэманы бер төенгә җыеп торса да, автор үзен борчыган уйларын аерым бүлекчәгә дә чыгарырга булган. Лирик чигенеш рәвешендә тәкъдим ителгән әлеге бүлекчәдә Ф. Бурнаш Идел буендагы мәгърур шәһәр турында горурланып яза. Автор укучыга мөрәҗәгать итә: рус халкыныкымы бу шәһәр? Герман, француз халкыныкымы? Дөнья гизгән Португалия халкыныкымы? Һәм үзе үк шушы соравына җавап та бирә: *Йөрми анда*

---

1 *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 17.

2 *Иванова И. С.* Феномен времени в лирике Серебряного века: дис. ... канд. филол. наук. – М., 2002. – С. 147.

3 *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 3.

*һич берәүнең фәрманы / Ул татарларның мөкаддәс гыймраны...*[1] Әлеге юллар әдипнең татар милләтенең бөеклеге, олылыгы турындагы фикерләрен җиткерергә теләве булып аңлашыла. Шуның белән бергә, чынбарлыкта милли таркаулык хөкем сөрү, илнең сугыш утын кабызуы хакында уйланулар авторның сызлануын тагын да арттыра. Шул рәвешле, «Айсылу» поэмасы, Казан ханлыгы яулап алыну белән бәйле вакыйгаларны үзәккә куеп, хәтер, иманга тугрылык, хакыйкать кебек мәңгелек төшенчәләрне шигъри юлларга чыгара.

**«Габделман»** (1918 елда басылган) поэмасы исә үзгәрәк рухта иҗат ителгән. Поэманың хронотобы беренче әсәрнекеннән шактый тар, әмма аңа бик якын. Башлам өлешендә үк рус яуларының дәһшәтлелеге, аларның явызлыгы, вәхшилеге турында искә төшерелә. Күптәннән инде тыныч гомер кичергән, үзе башлап яуга чыкмаган Казан ханлыгының кыен хәлдә калуыаркасында табигатьтә дә гармония югалган: *Яшел чирәм кипте, сулды чәчкә, / Яшәрмәстәй булып яңадан. / Элек шатлык көен көйләп торган / Бакчаларда яфрак саргайды. / Качты җырлап торган былбыллары, / Аларга да киң җир тар иде. <... > / Хан кызлары элек җырлый-җырлый / Су тутырган салкын чишмәдән / Кызыл каннар акты; җылый-җылый / Ханбикәләр качты илләрдән*[2]. Шул рәвешле, романтизм поэтикасында төп урыннарның берсен алып торган пейзаж, импрессионистик тенденция белән кушылып, чынбарлыкка бәя бирү һәм хикәяләүче автор кичерешләрен җиткерү чарасына әверелә.

Күренеп тора: шушы моменттан вакыйгалар вакыты икегә аерыла: яуга кадәр булган хөр, ирекле чор һәм сугыш китергән афәтле, җан өшеткеч, шыксыз бүгенге. Яулап

---

[1] *Бурнаш Ф.* Айсылу // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 6.

[2] Шунда ук. – Б. 22.

алучыларның вәхшилеге Казан халкын иленнән китәргә мәҗбүр итә, буйсынган шәһәрдә берәүнең дә яшәп каласы, рус патшасына баш иясе килми. Алар караңгы урманда качкын тормышын кол халәтеннән артыграк күрәләр. Әнә, шул рәвешле, иленнән сөрелгән халык табигатьтә яклау таба.

Урмандагы халык арасында хан малае Габделман да бар. Беренче поэмадан аермалы буларак, аны беркем дә туган йортыннан көчләп аермый, киресенчә, ул ирекле, иптәшләре арасында абруе бар, аны «көчле солтан итеп таныйлар». Әмма Габделманның үткәннәр турындагы хәтере башкарак вакыйгаларны, хыял-теләкләрне үзендә саклый. Ул кечкенәдән Казан тәхетенә утыру турында хыялланган, шөһрәткә сусаган: *Шөһрәт тели иде, өмет итә, / Көтә иде ак таң каршында. / Өмет итте алтын тәхетләргә / Кайчан булса барып җитәргә, / Казан туфрагына мин хан, диеп, / Төрле якка игълан итәргә. / Ул уйлары инде җимерелде, / Һаман тели, өмет киселми*[1]. Байлык, мул, ваемсыз тормыш, тәхет, хакимлек турында хыялланган Габделман язмыш әзерләгән сынаулар алдында югалып кала. Ул иле, халкы белән бәйле хәтерен югалта. Ә хәтерсез, тарихсыз кеше халкын сатарга, хыянәткә барырга һәрвакыт әзер. Һәм Габделман ул адымны ясый да. Аның иленнән, милләтеннән ваз кичүен иптәшләре генә түгел, табигать тә кичерә алмый: *Караңгы төн, көзге вак яңгырлар / Аны дусларыннан аерды... / Сызгыра җил шунда нәрсәгәдер, / Актык көчен җыеп кайгырды*[2]. Димәк, импрессионистик алымнар биредә дә хискичерешләрне тирәнәйтү вазифасына хезмәт итә.

Көзге караңгы төн метафорасы Габделманның язмышына ишарә итеп килә. Муллык, байлык тулы гомер кичерсә

---

[1] *Бурнаш Ф.* Габделман // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 25.

[2] Шунда ук. – Б. 30.

дә, аны хыянәтче язмышы, вөҗдан хөкеме көтә. Җил образы шушы фикерне тагын да ныгытуга хезмәт итә.

Габделман үзе кылган гамәлләрен аңларлык хәлдә түгел, байлык, хакимият, тук тормыш аның күңелен томалаган. Ул бик күп милләттәшләренә хыянәт итә, шул рәвешле, Мәскәү ханының ышанычын, ихтирамын яулый. Кылган «изгелекләре» өчен Габделманга җир бирәләр, меңләгән кол бүләк итәләр. Габделман кебек кансыз идарәчене татар халкының, мөгаен, күптәннән күргәне булмагандыр: *Рәхәт гомер итә... Кирәк булса, / Чыгып акча җыя халыктан. / Бирмәүчеләр күздән яшен түгә, / Кылычыннан үтә карышкан. <... > / Салкын кышлар җитсә, калтыранып, / Килеп бар да сәҗдә итәләр. / Ачлык белән кипкән ак кулларын / Сузып, зарыгып ярдәм көтәләр. / Көчсез куллар кайчан хәлсезләнә, / Ук кадала ачлар бәгъренә. / Керсез күкрәк сулып, сынган күңел / Кайта еглап изге Тәңренә*[1].

Шул рәвешле, Габделман чиксез байлыкта-муллыкта яши, бик күпләрне үзенә буйсындыра, әмма аның бөеклеге, хакимияте парадоксаль характерда: Габделман үзе – рус ханының колы, ул хәтта җанына, намусына, вөҗданына да хуҗа түгел. Шул рәвешле, автор коллык проблемасын фәлсәфи яссылыкта күтәрә: намусын башка берәүгә саткан кеше беркайчан да ирекле була алмый.

Габделманның хыянәтчел, мәкерле, кансыз гамәлләре турындагы фикер поэманың буеннан-буена шулай үстерелә килә, һәм укучы гадел финал көтә: Габделман, һичшиксез, җәзасын алырга тиеш, чөнки аның кылган гамәлләре гафу итәрлек түгел. Үлем геройны үзе кайчандыр мәсхәрәләгән хатын кулы аркылы эзләп таба. Бу хатын монологы поэмада зур урын алып тора. Ач, ялангач, баласын да туендырырлык хәле калмаган әлеге ялгыз хатын йөзендә чит дәүләт изүе

---

[1] *Бурнаш Ф.* Габделман // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 36.

астында көчкә-көчкә сулыш алган милләт, ил сөйли сыман, хатынның Аллага мөрәҗәгатенең риторик характерда булуы, кешене яшәткән Ходайга таянычның юкка чыгуы *(Күрә микән, Тәңрем, кодрәт күзең / Сыкраганны керсез күңлемнең; / Күрә микән күлдәй яшь түккәнен / Канга баткан нурсыз күземнең? / Ишетәсеңме, Ходам, чыдый алмый, / Күкрәгемнән ташкан аһымны? / Ишетәсеңме минем сыкравымны, / Теләгемне, моңлы зарымны? / Ишетмисең, беләм, ишетмисең... / Алар сиңа, Ходаем, җиталмый...*[1]*)* илдәге авырлыкларның үтәчәгенә ышанычны юкка чыгара.

Поэма ахырында Габделманның җаны кара болыт булып, ә хатынныкы нурга әйләнеп күккә аша. Әлеге юллар милләт хакындагы фикерләрне көчәйтә һәм әсәр идеясен җиткерүгә хезмәт итә. Ф. Бурнаш фикеренчә, шәхеснең кыйммәте малы белән түгел, ә халкына, милләтенә тугрылыгы белән билгеләнә. Хыянәтчеләрне барган, тарихтан, хәтердән ваз кичкәннәрне хурлыклы үлем көтә. Димәк, әсәрдә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе иҗтимагый җирлектә тәкъдим ителә: кешенең үлемсезлеге халык гамен уйлап яшәү, башкалар мәнфәгате өчен үзеңне корбан итү кебек сыйфатлар белән яулана, дигән фикер алга сөрелә. Әлеге фәлсәфәнең мондый вариациясе чор вакыйгалары белән аваздаш, һәм ул XX йөз башы татар әдәбиятында кызыл җеп булып сузылган мотивларның берсе саналырга хаклы.

Шул рәвешле, Ф. Бурнашның «Айсылу» һәм «Габделман» поэмалары бер үк теманы ике яссылыкта ача. Беренче әсәрдә милләтнең азатлыкка омтылышы символы дәрәҗәсенә күтәрелгән Айсылу образы милли хәтерне саклаучы буларак ачылса, икенче поэманың үзәгендә торган Габделман исә милләтен саткан рухи кол образын символлаштыра. Гомумән, Ф. Бурнашның әлеге поэмалары татар

---

[1] *Бурнаш Ф.* Габделман // *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – Б. 37.

тарихының фаҗигале бер сәхифәсен сурәтли һәм аны ике шәхес язмышы аркылы ача.

Романтиклар иҗатында тормыш идеал белән чынбарлыкның органик берлеген тәшкил итә. Идеалның гамәлгә ашу юлы исә камиллеккә омтылу хәрәкәте кебек тәкъдим ителә, башкача әйткәндә, яшәеш үсеш, формалашу барышы кебек яктыртыла. Моның асылын романтиклар киң мәгънәдә, кешедәге Җан, Тән, Рух башлангычының идеалга омтылуы рәвешендә аңлаталар[1]. Тикшерүләр күрсәткәнчә, XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгате, романтизмның әлеге үзенчәлеген нигез итеп алган хәлдә, милли эстетикага йөз тота һәм камиллеккә ирешү юлын милләткә хезмәт итү буларак күзаллый. Югарыда анализланган поэмаларда бу үзенчәлек ачык күренә.

Шул рәвешле, XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә романтизм агымының ни дәрәҗәдә эволюция кичерүен күзәтү кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Поэмаларга игътибар итсәк, аларның, гасырлар дәвамында сакланып килгән шәркый традицияләрне саклаган хәлдә, Европа тибындагы романтизмга йөз белән борылуын күрербез. Ф. Бурнаш, Г. Рәхим, К. Юлдаш, Б. Мирзанов кебек авторларның без тикшергән әсәрләре, Гареб романтизмына хас булганча, шәхесне, аның эчке дөньясын беренче планга чыгару, дуалистик принципка нигезләнеп, яшәешне, нигездә, үткән һәм бүгенге кысаларында сурәтләү, әлеге агым өчен хас булган төн, диңгез кебек традицион образларны куллану һ. б. ягыннан кызыклы. Шул ук вакытта, XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә романтизм иҗат юнәлеше «чиста» формада бик сирәк күзәтелә. Нигездә, әдипләр романтик поэмаларны модернистик тенденцияләр белән баеталар. Бу исә, үз чиратында, әсәрләрдә яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең үзенчәлекле

---

[1] *Бердяев Н.А.* Философия творчества, культуры и искусства: в 2-х т. – М.: Искусство, 1994. – Т. 1. – С. 85.

ачылуына, кайберләрендә экзистенциаль мотивларның алгы планга чыгарылуына, язмыш категориясенең киң планда чагылуына, модернизм өчен хас булган аерым символ-образларның әсәр кысаларына кертеп җибәрелүенә һ.б. китергән. Аерым бер әсәрләрдә реалистик тенденцияләрнең әдәби катлам төсендә урын алуы исә чор вазгыятенә бәя бирергә ярдәм иткән. Әлбәттә, болар барысы да поэмаларның идея-эстетик, тематик җәһәттән төрлелегенә, сәнгати яктан баюына хезмәт итә. Шунысын искәртергә кирәк: әлеге поэмаларның барысы да диярлек милли эчтәлек белән сугарылган, һәм аларда төрле иҗат агымнарына хас күренешләрнең урын алуы да, нигездә, шушы максаттан чыгып аңлатыла. Милли эчтәлек белән баетылу романтик поэмалардагы хронотопны да үзенчәлекле итә. Әсәр вакыты һәрвакыт ике өлешкә бүленә: ретроспекция алымы ярдәмендә торгызылган матур, бәхетле, азат үткәнгә һәм ачлык-ялангачлык, коллык белән характерланган бүгенгегә. Бу – романтизмга хас дуализм принцибына нигезләнеп башкарыла. Поэмаларның күпчелеге әнә шул үткәндә калган матурлык, азатлык турында ачынып уйлануларга бәйле сагыш хисе белән сугарылган.

Димәк, XX йөз башында традицияләргә таянып иҗат ителгән поэмаларны күздән кичергәннән соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин.

Күп гасырлар дәвамында татар поэмасы романтизм кысаларында үсә-үзгәрә. XX йөз башында исә татар әдәбияты, шул исәптән лиро-эпика да яңа үсеш юлына чыга. Алдагы гасырда формалашкан мәгърифәтчелек реализмы һәм романтизм йогынтысын тойган хәлдә, тәнкыйди реализм агымына хас үзенчәлекләр барлыкка килә. Сәнгатьчә фикерләүнең реалистик канатына караган әсәрләрнең күпчелегендә әле алдагы гасырда формалашып җиткән мәгърифәтчелек реализмы тенденцияләренең тәэсире зур, һәм бу

XX йөз башы татар сүз сәнгате кысаларында күчеш характерындагы лиро-эпик әсәрләр турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә.

Күпчелек галимнәр XX гасыр башы татар әдәбиятының тизләтелгән үсеш дәвере кичерүен раслыйлар. Һәм ул төрле иҗат методларының һәм әдәби агымнарының очрашуы, аралашуы яки янәшә яшәве формасында чагылыш таба. Әлеге чорда милли әдәбият традицион романтизм һәм XIX гасырның икенче яртысында үсеш алган мәгърифәтчелек реализмыннан тәнкыйди реализм, синтетик характердагы романтизм һәм модернизм агымнарының янәшәлегенә йөз белән борыла һәм әлеге агымнарның катлаулы кушылмасы күзәтелә. Тәнкыйди реализм үсешенең иң югары ноктасы булган сатирик әсәрләр исә чор сулышы белән сугарылу һәм иҗтимагый-сәяси вәзгыятькә бәя бирү ягыннан кызыклы.

XX йөз башында романтик иҗатта да үзгәрешләр күзәтелә. Романтик поэмаларда моңа кадәр сурәтләнгән лирик герой, мәхәббәт утында янып-көю кысаларыннан чыгып, милләт язмышы өчен хафаланучы, азатлык, киләчәк өчен көрәшүче буларак ачыла. Әсәрләрнең милли эстетикага йөз тотуы, бердәмлек, тынычлык идеяләрен алга сөрүе аларны XX йөз башындагы иҗтимагый тормыш фонында карарга нигез тудыра. Бу чорда иҗат ителгән поэмаларның барысы да диярлек халыкның сугышлар, кан коюю белән характерланган ирексез гомер кичерүенә ачыну хисе белән сугарылган һәм шагыйрьләрнең беришесе шул хәлдән чыгу юлын эзли, кайберләре исә язмышның өстенлеген танып, киләчәккә өмет юклыкны алга сөрәләр.

Күпчелек әсәрләрнең синтез характерында булуы авторларга катлаулы сурәтләр тудырырга, поэмаларның сәнгати һәм фәлсәфи тирәнлеген арттырырга мөмкинлек биргән.

## Икенче бүлек

# XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ПОЭМАЛАРЫНДА ЯҢАЧА ЭЗЛӘНҮЛӘР

### 2.1. XX йөз башы татар поэмаларына символизм агымы йогынтысы

XX йөз башы – татар әдәбияты тарихына бай һәм катлаулы үсеш чоры буларак кереп калды. Бу дәвер милли сүз сәнгате үзенең байлыгына карап кына түгел, язучыларның аны үстерү юнәлешләрен эзләү мөмкинлекләре, моңа кадәр күзәтелмәгән алымнардан файдалану, татар укучысына традицион булмаган әсәрләр тәкъдим итү ягыннан да чын мәгънәсендә «алтын чорга» аяк баса[1]. Әдәбиятка татар сүз сәнгатендә яңа күренеш булган модернистик агымнар килеп керә. Реализм кануннары чор үзенчәлекләрен ачып җиткерми дип санап, яшь буын язучылар сүз сәнгатен яңадан-яңа формалар белән баетырга омтылалар.

XX йөз башы татар әдәбиятындагы модернистик үзгәрешләр аз өйрәнелгән. Модернизм йогынтысын аеруча ачык тойган татар лиро-эпикасы да тиешенчә тикшерелмәгән. Озак вакытлар дәвамында әдәбият белеме фәне гасыр башы татар әдәбиятына мөнәсәбәтле бер эчтәлекле юнәлешне – милләтчел халыкчанлык идеяләрен тормышка ашыруны игътибар үзәгендә тота. Мәсәлән, И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» хезмәтендә «декаданс», ягъни модернизм, бүтән яклардан тыш, җитлеккән реализмга, тәнкыйди

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 6.

реализмга реакция рәвешендә, реализмны инкяр итә торган күренеш буларак мәйданга килә, гасыр башы сүз сәнгатендә бу күренешкә урын юк, дип белдерелә[1]. Г. Халит исә совет чорында ук әдәбиятта модернизмның булуы мәсьәләсен күтәреп чыга. Галим модернизм белән декадансны берләштерүнең мәсьәләне артык гадиләштерүен ассызыклый, мондый карашның алар артында торган күренешләрнең чын мәгънәсен чагылдырмавын күрсәтә. Чөнки модернизм, декаданстан аермалы буларак, сәнгать өлкәсенә карый, һәм аның үзенчәлекле эстетик билгеләре бар, дигән карашны алга сөрә[2].

Соңгы елларда исә әлеге күренешләргә игътибар артты, татар әдәбиятының моңа кадәр өйрәнелмәгән катламнарына яңача бәя бирү ихтыяҗы галимнәрне эзләнүләргә этәрде. 1980 елларда ук Р. Ганиева Н. Думави иҗатында экспрессионизм билгеләре булуы хакында сүз күтәрә[3], шулай ук Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов кебек әдипләр иҗатында да модернистик алымнар таба[4]. Галимәнең соңрак чыккан хезмәтендә бу мәсьәләләр тагын да тирәнрәк тикшерелә[5]. А. Саяпова исә XX йөз башы шагыйре Дәрдемәнд иҗатының, символизм кысаларында иҗат ителеп, экзистенциализм фәлсәфәсе йогынтысын тоюы хакында язып чыга[6]. Й. Нигъмәтуллина татар дөньясында «соңарган модернизм»

---

[1] *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 27.

[2] Татар әдәбияты тарихы: 6 томда: –Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 3 т. – Б. 55.

[3] *Ганиева Р.К.* Каршылыклы еллар авазы // Казан утлары. – 1983. – № 6. – Б. 166–177.

[4] *Ганиева Р.К.* Татар әдәбияты һәм Фатих Әмирхан // Мәгърифәт. – 1996. – 13 гыйнв.

[5] *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 272 с.

[6] *Саяпова А.М.* Поэзия Дардменда и символизм. – Казань, 1997. – 210 с.

булуы хакындагы фикерне ассызыклый һәм XX гасыр милли мәдәниятендә модернизмның ике тапкыр күтәрелүен әйтә: XX йөзнең беренче чирегендә әдәбиятта һәм 1970 еллар ахырында – рәсем сәнгатендә[1]. Д. Заһидуллина монографиясендә исә XX йөз башы татар прозасы модернизм чагылышы ноктасыннан җентекле анализлана[2]. Т. Мирсияпова тикшеренүләрендә XX йөз башы прозаигы М. Хәнәфи иҗатындагы экзистенциаль мотивлар өйрәнелә[3]. XX йөз башы татар поэмаларындагы аерым бер модернистик тенденцияләр Н. Йосыпова[4] мәкаләләрендә яктыртыла.

Модернизм юнәлеше символизм, акмеизм, футуризм, экспрессионизм кебек күп кенә сәнгати һәм әдәби агымнарны берләштерә. Шулардан XX йөз башы татар сүз сәнгатендә импрессионизм, символизм һәм экзистенциализм юнәлешләре аеруча киң тарала. Поэмаларда да шушы тенденция саклана, әлеге агымнарның бер әсәр кысаларында үзара үрелеп, керешеп китүе дә еш очрый. Гомумән, модернист шагыйрьләр поэма жанрында аеруча актив эшлиләр. Н. Исәнбәт, Ф. Ибраһимов, Г. Кәрам, Г. Рәхим, Н. Думави, Б. Мирзанов, Г. Сөнгати, С. Сүнчәләй, З. Бәшири, Ф. Бурнаш кебек авторларның модернистик поэмалары шул чор вакытлы матбугатында дөнья күрә.

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – С. 12–13.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 255 б.

[3] *Мирсияпова Т.И.* Экзистенциальные мотивы в творчестве М. Ханафи: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2009.

[4] *Юсупова Н.М.* Символизация в татарской поэзии начала XX века // Вестник Удмуртского университета. – 2014. Серия «История и филология». – 2014. – № 4. – С. 111–114; *Юсупова Н.М.* Мифологические образы и сюжеты в лиро-эпических произведениях начала XX века: роль, функции и художественное значение // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2014. – № 4. – Ч. 2. – С. 211–214.

Татар шигъриятендә иң киң таралган агымнарның берсе – ул символизм. «Төп асылы чынбарлыктагы кешегә яшерен булган идеяләрне, эчтәлекләрне символ ярдәмендә ачудан гыйбарәт»[1] булган әлеге агым С. Рәмиев, Дәрдемәнд һ.б. шагыйрьләр иҗатына зур йогынты ясый. XX йөз башына нисбәтле модернистик поэмаларның да күбесе символизм агымы кысаларында иҗат ителә. Татар сүз сәнгатендә символлар ике яссылыкта кулланыла. Беренчедән, алар сүз сәнгатенең тәүге дәверләрендә үк, бигрәк тә суфичылык поэзиясендә, төрле авторлар иҗатына аерым образлар буларак килеп керә. Бу традицион образлар татар әдәбиятында да киң чагылыш таба. Мәсәлән, Г. Тукай, С. Рәмиев кебек шагыйрьләр үз иҗатларында әледән-әле таң, төн, көз кебек җәмгыять һәм милләт язмышын гәүдәләндерүче символларга мөрәҗәгать итә, тик бу әдипләр иҗатында алар символизмга бәйле рәвештә каралмый. Икенчедән, символларның күпләп кулланыла башлавы татар әдәбиятына символизм агымы килеп керү белән бәйле. Д. Заһидуллина татар сүз сәнгатендә символларның дүрт төрен аерып чыгара: аерым образлар, тарихи шәхесләр, мифлар, аллегорик образлар[2]. XX йөз башы татар әдәбиятында тарихи шәхесләрне һәм аерым образларны символ югарылыгында сурәтләү аеруча еш очрый, ләкин символист әдипләрнең барысы өчен дә уртак бер үзенчәлек хас: алар үз әсәрләрен һәрвакыт милли эчтәлек белән баеталар. Әдипләрне милләтнең үткәне, киләчәге турында борчулы уйланулар берләштерә. Моны Д.Ф. Заһидуллина да билгеләп үтә. Аның раславынча, бу юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрдә милләт, татарлык, халык язмышы мәсьәләләре үзәккә куела, һәм символ халык хәтере турында сөйләүче,

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 162.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 63.

тарихны халык күңеленә тоташтыручы күпергә әверелә. Әгәр рус символистлары хәрәкәтнең ахыргы максатын үзгәргән, «азат шәхес»тә күрсәләр, татарлар «ирекле милләт» хакында хыяллана. Шуңа күрә символлар системасы һәрчак милли эстетикага йөз тота[1].

XX йөз башы татар әдәбиятында Көнбатыш әдәбияты традицияләре, яңа эзләнүләр, мифология белән кызыксыну нәтиҗәсе буларак, милли поэзиядә мифологик образларны символ дәрәҗәсендә гәүдәләндергән бер төркем лирик һәм лиро-эпик әсәрләр мәйданга килә. Һәм бу поэмаларны тикшерү чор милли сүз сәнгатендә традицион образларның ни рәвешле үсеш-үзгәреш кичерүен билгеләргә, икенчедән, XX йөз башы татар шигъриятенең милли сыйфатларын төгәлләштереп, әдипләрнең сәнгати-эстетик һәм фәлсәфи эзләнүләрен ачыкларга мөмкинлек бирә, чөнки Көнчыгыш әдәбияты традицияләренә нигезләнеп үскән һәм XX гасыр башында рус, аның аша Көнбатыш әдәбиятлары йогынтысын тойган милли сүз сәнгате мифологик мотивларга яңача караш булдыра. Моңа кадәр ислам дине белән бәйле мифологик элементлар, суфичылыктан ук килгән традицион сюжетлар, образлар дини-дидактик, үгет-нәсыйхәтчелек максатларында кулланылса, XX йөз башында әсәр яссылыгына кертелгән мифологик образлар дөньяви фикерләр үткәрү мәйданына әйләнә.

М. Ибраһимов язганча, һәрбер милли әдәбиятта үзенең «мифологик традицияләре», ягъни аеруча еш кулланыла торган мифик образлар һәм сюжетлар яшәп килә. Европа әдәбиятында ул – мәҗүси, антик һәм христианлык мифологиясе. Көнчыгыш әдәбиятларда исә төп урынны мөселман мифологиясе алып тора, шулай ук ислам дине кабул ителгәнче барлыкка килгән мифологик сюжетлар да чагылыш

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 63.

таба[1]. Шул исәптән татар сүз сәнгате дә ислам дине белән бәйле ышануларга һәм төрки-татар мифологиясенә бик еш мөрәҗәгать итә. Татар әдәбиятында мифологик материал нигезендә шигъри әсәрләр иҗат итү XX йөзнең 10 –20 елларында шактый активлашып китә. М. Гафуриның «Адәм вә Иблис», Н. Думавиның «Инсан», И. Шаммасиның «Убыр», Г. Сөнгатинең «Хозыр», «Су анасы», Б. Мирзановның «Җен туе» һ.б. поэмалар бер-бер артлы дөнья күрә.

Бу әсәрләрнең күпчелегендә ислам мифологиясеннән килгән Җен, Иблис, Хозыр, шулай ук төрки-татар ышануларына бәйле Су анасы, Убыр, Өрәк кебек мифологик затлар үзәк образлар буларак алына яки мифологик сюжетлар «яңадан корыла». Әдәбият белемендә мондый әсәрләргә карата «антижанр» төшенчәсе кулланыла, һәм ул иске форманың яңа вазифада кулланылуы итеп карала. Мифологик сюжет, башлангыч формасыннан аермалы буларак, капма-каршы эчтәлектә укучыга тәкъдим ителә. Укучы антижанрның идея эчтәлеген беренчел форманыкы белән чагыштырырга тиеш була һәм аларның ике чиктә торуын ачыклый. Әлеге жанр модификациясе тәнкыйди башлангычка йөз тоту белән характерлана. Әдәбият белемендә аның ике төре аерып чыгарыла: көлке, сатира, пародиягә корылган төр һәм җитди антижанр[2]. Без өйрәнгән поэмалар аларның икесенә дә карый. Мәсәлән, Ш. Бабичның «Газазил», М. Гафуриның «Адәм вә Иблис» кебек поэмалары пародиягә корылган антижанрга, ә Г. Сөнгатинең «Хозыр», Г. Харисның «Өрәк» әсәрләре җитди антижанрга мисал була ала. Антижанрлар сүз сәнгатендә мәдәни күчеш чорында, бер әдәби агымнан икенчесенә күчү таләп ителгәндә барлыкка килә, дип санала[3]. Татар әдәбиятында

[1] *Ибрагимов М.И.* Миф в татарской литературе XX века... – С. 39.

[2] *Давыдова Т.Т., Пронин В.А.* Теория литературы: учеб. пособие. – М.: Логос, 2003. – С. 60–63.

[3] Шунда ук. – С. 63.

XX йөз башында барган үзгәрешләр дә шушы рухтагы поэмалар иҗат ителүгә нигез була. Әдипләр, нигездә, Коръән мотивларын һәм борынгы ышанулар белән бәйле риваятьлегендаларны яңа эчтәлеккә салып тәкъдим итә.

Ш. Бабичның **«Газазил»** (1916) поэмасы – шундый рухтагы әсәрләрдән. Антижанр буларак, ул Коръән традицияләрен, дини легенданы «яңадан кора». Вакыйгалар катламы Газазилнең, ягъни күк фәрештәсенең, җиргә сөрелеп, Иблискә әверелүе турындагы сюжетны үзәккә куя. Әлеге образларның кулланылыш тарихы ерак дәверләрне үз эченә ала. Суфичылык идеяләре белән сугарылган Урта гасыр татар шигъриятендә үк инде дини-мистик күзаллаулар белән бәйле Алла, Иблис, фәрештә, пәйгамбәр кебек образлар төп сурәтләү объекты булып торалар. Мәсәлән, А. Шиммель Иблис образының суфичыл әдәбиятта каршылыклы сурәтләнүен билгеләп үтә. Бер яктан, ул – абсолют явызлык, кешенең нәфесе белән идарә итүче көч буларак күзалланса, икенче яктан аны бер аллалыкны яклавы өчен җәза күргән бәхетсез зат итеп сурәтләү дә очрый[1]. Әлбәттә, күпчелек әсәрләрдә Иблис, шайтан образы явызлык, туры юлдан тайпылдыручы символ мәгънәсендә килә. «Газазил» поэмасында да дини-мифологик образның шушы вазифасы үстерелә. Г. Кунафин билгеләвенчә, XX гасыр башында, бигрәк тә реакция елларында, башкорт һәм татар поэзиясендә бунтарьлык рухы белән сугарылган демонизм концепциясе үстерелә. Әлеге концепциянең нигезендә шикләнү, чарасызлык, явызлык төшенчәләре ята, дип белдерелә. Бер төркем шагыйрьләр иҗатында тормышның әхлаксызлыгы, караңгылыгы, илаһи башлангыч җуелу турындагы идея үткәрелә. Әсәрләрнең лирик геройлары да Аллага каршы чыккан, ирек, хөрлек, азатлык төшенчәләрен тормыш максаты иткән

[1] *Шиммель А.* Мир исламского мистицизма. – М.: Алетейа, Энигма, 2000. – С. 156.

шәхес буларак сурәтләнәләр[1]. Ш. Бабичның «Газазил» поэмасын да автор шушы аспекттан анализлый һәм демонизмның явызлык белән билгеләнгән асылына игътибар итә[2].

Д. Заһидуллина билгеләвенчә, әсәр урта гасыр Шәрык әдәбиятларындагы пәйгамбәрләр тарихлары, кыйссасел-әнбияләргә пародия итеп уйланылган. Нигезенә миф салынган әсәрләр, гадәттә, ике вазифа башкара: яки яңа миф тудыра (мифологизация), яки яшәп килүче мифны юкка чыгара (демифологизация). «Газазил» – соңгы вазифаны күз алдында тотып язылган әсәр[3]. Галимә тарафыннан бу әсәр җентекле һәм тирән анализланган, без хезмәтебездә аның фикерләренә таянып эш итәбез.

Вакыйгалар катламы Алла белән Газазил арасындагы каршылык, аны җиргә төшерергә карар кабул ителү белән башланып китә. Газазилнең Алла нәфрәтенә дучар булуының төп сәбәбе – аңа баш ияргә, буйсынырга теләмәвендә. Биредә гыйсъянчыл мотивлар күзгә ташлана: *Иблис әйтте: «Дәүләтеңне сансынам, / Әмма шунсы – буйсынырга кимсенәм? / – Чөнки мин – зур, чөнки мин – нур, мин – галим, / Үз-үземә кечкенә бер Алламын мин!* [4]. Шул ук вакытта, яшәп килүче кануннарга буйсынмау, үзеңне өстен күрү кешегә җәза булып әйләнеп кайтачагы да искәртелә. Газазилнең җиргә төшүен төрле көлкеле детальләр белән үреп биреп, әдип һәр кешенең күңелендә нәфес-шайтан утыру турындагы уйлануларга килә.

---

[1] *Кунафин Г.С.* Развитие жанровой системы в башкирской поэзии II половины XIX – нач. XX в.: дис. ... д-ра филол. наук. – Уфа, 1998. – С. 377–378.

[2] Шунда ук. – Б. 378.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Шәехзадә Бабичның иҗат юлы: мәгърифәтчелектән шартлы сурәткә таба // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 160.

[4] *Бабич Ш.* Газазил // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 206.

Символизм белән бәйле иҗат үзенең универсаль характеры белән үзенчәлекле. Иң беренче чиратта, символистлар фәлсәфә белән кызыксыналар[1]. Тарихка «көмеш чор» исеме белән кереп калган XIX йөз ахыры – XX гасыр башы рус әдәбияты өчен хас булган әлеге сыйфат без тикшергән чор татар әдәбиятына да үтеп керә. Әдипләрнең төрле фәлсәфәчеләрнең хезмәтләре белән кызыксынуы арту, әсәрләрдә фәлсәфи фикерләр тулы бер катлам итеп бирелү шул хакта сөйли. Символизм иҗат агымы йогынтысында язылган поэмаларда да бу шулай. «Газазил» әсәрендә, мәсәлән, фәлсәфи катлам яшәешкә кагылышлы фәлсәфи фикерләрне үз эченә ала һәм кешелеккә хас сыйфатлар, явызлыкның чыганагы турында уйланулар белән үрелә. Әдип яхшылык һәм явызлыкның мәңгелек категорияләр булуын белдерә, һәр кешенең күңелендә шайтан төге белән кергән нәфес утыру турындагы сүзләр аша явызлыкның кеше табигатенә хас сыйфат булуын дәлилли.

Поэмада тагын бер катлам тормышка, җәмгыятькә бәя бирү белән бәйләнгән. Иблиснең хакимияткә килүе вакыйгасы аллегорик характерда булып, хуҗага буйсынуны белдерү, хакимлеккә ирешкәннең рәхмәт нотыгы сөйләве, мәдхия уку, әләмнәр болгау һ. б. кебек вакыйгалар белән бәйләп бирелә. Хакимият, көч ярдәмендә яки алдап буйсындыру тәнкыйтькә очрый: *Таркала мәҗлес хисапсыз дәрт белән, / Керешәбез эшләргә, дип, гайрәт белән... / Дөнья халкын аздырып бетермәк булып, / Дингә, вөҗданга сугыш итмәк булып, / Дөньяга кормак булып һәр ауларын, / Китте бар да калдырып, Каф тауларын... / Би булып, әмир булып, остаз булып...*[2] Әлеге юллардан күренгәнчә, явыз, әхлаксызлар, кара максатларына ирешү өчен, һәрчак хакимияткә омтылалар.

[1] *Воскресенская М. А.* Символизм как миропонимание Серебряного века... – С. 83.

[2] *Бабич Ш.* Газазил // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 226.

Шул рәвешле, әсәр үзәгендә явызлык һәм яхшылык көрәше ята. Бу – мәңгелек конфликт. Әсәр тукымасында ул һәр кешенең үз эчендә барган көрәш сыман да аңлашыла. Явызлык категориясенең берничә яссылыкта ачылуы Иблисне явызлык символы буларак карарга мөмкинлек бирә. Моны Г. Кунафин да билгеләп үтә. Автор Алланы изгелек, табигый башлангыч символы буларак Иблискә каршы куя[1].

Димәк, поэманың мифологик сюжеты зур гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә, явызлык – изгелек, гөнаһ – җәза, мизгел – мәңгелек кебек фәлсәфи категорияләр белән эш итү исә кеше, гомумән, милләт яшәеше турында фикерләүгә этәрә.

М. Гафуриның **«Адәм вә Иблис»** поэмасында (1910) шулай ук демифологизация – яшәп килүче мифны юкка чыгару, шартлылык күренеше белән очрашабыз. Аның нигезенә дә Адәмнең яратылуы һәм җиргә сөрелүе белән бәйле дини миф салынган. Әлеге миф, антижанр таләпләренә буйсындырылып, эчтәлек ягыннан үзгәртеп корыла, милли-иҗтимагый фикерләү белән тулыландырыла.

Әсәрнең мифологик катламы Алланың, җирдә яшәү өчен, Адәмне барлыкка китерүен, фәрештәләрнең аңа сәҗдә кылырга мәҗбүр булып, Иблиснең генә бу гамәлдән баш тартуын бәян итү белән башланып китә. Фәрештәләр, алдан ук, кешенең гөнаһ белән гомер кичерәчәген, җиргә күп афәт китерәчәген әйтәләр: *Диделәр: «Бу фәсад әһлен яратмакта ни хикмәт бар? / Гаси булачак адәмнәрдә бу нинди әфзалиять бар? / Гөнаһ эшләр кылырлар һәм алар мотлак түгәрләр кан. / Тулар җиргә фәсад, сугыш, гайбәт, бөһтан»*[2]. Адәмгә сәҗдә кылырга теләмәгән Иблис җиргә сөреләә, ә җирдә яшәргә тиешле Адәмне Аллаһ җәннәткә урнаштыра,

[1] *Кунафин Г.С.* Развитие жанровой системы в башкирской поэзии II половины XIX – нач. XX в.: дис. ... д-ра филол. наук. – Уфа, 1998. – С. 385.

[2] *Гафури М.* Адәм вә Иблис. – Уфа, 1910. – Б. 3.

аңа иптәшкә Хауваны ярата. Әмма алар, Иблис коткысына бирелеп, тыелган җимештән авыз итәләр һәм җәннәттән сөреләләр. Күп михнәтләр, газаплар кичергәннән соң гына, Адәм белән Хауваның тормышы җайлана, балалары туа. Шул рәвешле, автор ислам мифологиясенә хас идеяне тагын бер мәртәбә раслый: һәр кылган гамәлең өчен иртәме-соңмы түләргә туры килә, кеше бәхеткә, матур тормышка игелекле гамәлләр аша, изгелек, яхшылык һәм сабырлык аркылы гына ирешә ала. Әмма, әсәрдә расланганча, тормышта гел киресе була: кешелек дөньясы үскән, үзгәргән саен, гөнаһ кылу, ярамаган гамәлләр кылучылар да арта. Кабил тарафыннан иң беренче зур гөнаһ эшләнә: ул энесен үтерә. Шул рәвешле, гөнаһ арты гөнаһ кылына башлый, хәзер дә адәм балалары сугыш, имансызлык, үтереш, явызлык баткаклыгына чумган.

Поэмада яшәешкә караган, кеше белән бәйле фәлсәфи фикерләр аерым катламны тәшкил итә. Ул Адәм, Хаува, Иблис кебек мифологик образлар аша тормышка ашырыла. Нигездә, фәлсәфи катлам явызлык, аның чыганагы турындагы уйланулар төсендә чагылыш тапкан. Явызлык күктән, Алла катыннан төшми, ә бәлки кешенең табигатеннән үк килә торган көч буларак тәкъдим ителә. Шуңа нисбәтле, Иблис кешенең ләззәткә омтылышы буларак кабул ителә. Аның бар начарлыгы, ялгышы – Аллага каршы килүендә, буйсынмавында дип аңлатыла. Шуның өчен дә ул Алла тарафыннан Адәм яшәргә тиешле җиргә сөрелә, ә Адәм исә җәннәткә урнаштырыла: *Өметсез хәлдә Иблис шул сәгать җиргә төшеп киткән, / Япа-ялгыз җир өстендә зарарсыз гына көн иткән. / Җир өстендә тулы җанварга кылмаган зарарлы эш, / Адәмнәр җиргә тулгач та зоһур иткән янә Иблис...*[1]

Явызлык кеше фәлсәфәсе дәрәҗәсендә дә бирелә. Шагыйрь раславынча, кеше – Җир йөзендәге бар начарлыкның чыганагы. Фәрештәләрнең кеше турында баштан ук әйткән

[1] *Гафури М.* Адәм вә Иблис. – Уфа, 1910. – Б. 6.

фикерләре, Адәм белән Хаува җиргә төшерелгәннән соң, җанварлар тарафыннан тагын бер кат кабатланып раслана. М. Гафури фикеренчә, адәм балаларының башына җиткән иң төп сыйфат – фани ләззәткә, тән ләззәтенә омтылу. Җиргә төшерелгән фәрештәләр дә, күп вакыт һәртөрле рәхәтлекләрдән баш тартып, ялгышлардан сакланып яшәсәләр дә, бер кыз аркасында гөнаһ пычрагына баталар. Әсәрдәге фикер сөрешеннән аңлашылганча, явызлык кешенең табигатенә салынган. Аның аерылгысыз сыйфаты булган нәфес – гөнаһка китерүче иң төп нәрсә, ике фәрештәнең, Аллаһ тарафыннан җисем һәм нәфесле ителеп, җиргә төшүләре һәм гөнаһ кылулары шуны раслый. Аллаһ үзе дә кешенең ялгышларына нәфесен тыя алмавы сәбәпче икәнен ачык аңлый: *Диде Алла: «Әгәр сезгә җәсәд берлән нәфес бирсәм, / Шулар төсле гөнаһ эшләр кылырсыз шөбһәсез һәм»*[1]. *Шулай булгач, кешеләрнең гөнаһ кылуына Иблис коткысы сәбәпче, дип әйтү дөреслеккә туры килми. «Кеше кылмас гөнаһ эшне, әгәр дә нәфесен тыйса»*[2], – дигән фикер идея төсендә алга чыгарыла. Кеше үз гомерен үзе теләгәнчә кора, үз юлын үзе сыза: *Үзеңнең ихтыярыңда мәгыйшәт юлларын тапмак*[3].

Авторның дингә карашы үзенчәлекле. Дин, шәригать, канун – инсаннарның хаталары күбәюгә каршы зарури барлыкка килгән кыйммәтләр. Тату яшәгән, изгелеккә хезмәт иткән җәмгыятьне кануннар белән тыеп торуның һич кирәге юк.

М. Гафури кешедәге тагын бер сыйфатны проблема дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли. Ул – курку һәм куркудан туган явызлык. Җиргә төшкән көннәрендә үз башын кайгырту белән генә мәшгуль булган Адәм куяннан да куркып гомер кичерә. Ә индеияләшеп беткәч, үзенә каршы чыгучы-

[1] *Гафури М.* Адәм вә Иблис. – Уфа, 1910. – Б. 21.
[2] Шунда ук. – Б. 11.
[3] Шунда ук. – Б. 16.

ларны очратмагач, ул көче җиткән бер әйберне таптый, изә, җәберли башлый. Шул рәвешле, биредә үзеңнән көчсезләрне рәнҗетергә омтылу проблемасы куела. Җанында курку асраган көчсез затның яклаучысыз калганнарны изүдән тәм табуы, шул рәвешле үз-үзенә «көчлелеген» раславы – аларның яшәү рәвеше.

Әлеге әсәрдә билгеле мифны куллану демифологизация максатыннан башкарыла. Автор ислам мифологиясендәге Адәм белән Хаува турындагы мифны үзгәртә. Бу – поэмадагы җәмгыятькә бәя бирү белән бәйләнгән тагын бер катлам таләпләреннән чыгып билгеләнә. М. Гафури шуның аша яшәешкә бәя бирә: *Үтә көннәр, җир өстендә фәсак-фәсад һаман арта. / Итагать юк, бирәләр һәрвакыт Хак әмеренә арка, / Ходаның үзенә дә сәҗдә кылмый башлагач инсан, / Мәләкләр әйткәненчә, башлады бунлар түгәргә кан*[1]. Автор беренче бөтендөнья сугышына да үз мөнәсәбәтен белдерә: *Адәмнәрнең газиз гомерләре үтә сугыш белән*[2]. Әсәрдәге сүз сөрешеннән аңлашылганча, кешелек дөньясы үз тарихында күп сугыш, кан коеш күргән, әмма ул шулардан сабак алып яши белми, аянычлы һәм фаҗигале тарихны оныта. Поэмадагы Иблис һәм Адәм символик образлар дәрәҗәсендә кабул ителә: Адәм образы җирдәге явызлык билгесен аңлатса, Иблис исә кешелекнең начарлыкка омтылышы булып төгәлләшә.

Әсәр экзистенциаль рухта тәмамлана. Шагыйрь фикеренчә, җир тормышта яхшылыкка урын юк, Җир үзе үк гөнаһлы булып яратылган, гөнаһ кылу, нәфес, үтереш кебек төшенчәләр кешенең табигатенә салынган. Бозыклык, явызлык, гөнаһның һаман арта баруы, туктаусыз сугышлар кешелекнең юкка чыгуына китерәчәк. Бу фикерне тирәнәйтү максатыннан, Аллаһның инсаннарны барлыкка китерүенә үкенүе ассызыклана. Тәүбәгә килү, Аллаһка сыену, рухи чистарыну,

[1] *Гафури М.* Адәм вә Иблис. – Уфа, 1910. – Б. 24.
[2] Шунда ук. – Б. 24.

изгелекне яшәү кыйбласы итү генә яшәешне бетүдән саклап калачак. Автор үткәргән төп идея шуннан гыйбарәт.

Бәхтияр Мирзановның **«Җен туе»** (1915) дип аталган символик поэмасында да без демифологизация күренеше белән очрашабыз. Җеннәр турындагы миф вакыйгаларны бәян итүче егетнең этисе тарафыннан сөйләнә. Ул буранлы караңгы кышкы бер төндә юлга чыга һәм, адашып, җен туена тап була. Җеннәр, үзләре белән ияртеп, аны бер тау куышына алып китәләр. Биредәге матурлыкны, гүзәллекне күреп, егет таң кала, әмма аңа монда озак торырга туры килми: ул җен кызының авыруына сәбәпче була. Күп алтыннар биреп, егетне өенә озаталар. Еллар үтә, байлык бетә, дәүләт китә. Хәзер инде ул малаена шул хәлләрне сөйли, ә улы исә шуннан соң юрган астында гына җен туе турында уйланып ята.

Әсәрдәге реалистик башлангыч чынбарлыкны сурәтләүгә, яшәеш тәртипләрен ачып бирүгә багышлана. Поэманың башламында ук егетнең табигатьтәге үзгәрешләр белән бәйле хис-кичерешләре сурәтләнә: *Билгеле: көз җитсә, бер көн сулса яфрак, гөл, агач, / Очмый кош, селекми канат, түкми моңын бер сандугач, / Бер генә ямь юк көнендә, юк – төнендә, нәкъ кабер! / Чәчәк – яфраксыз, киемсез, шыр ялангач һәр агач. / Көн – томан, нәкъ төн ягыннан төн буенча җил бәрә. / Бу табигать көзге көндә рәхиме юк кансыз палач!*[1] Бу өзектәге көз сурәте яшәешкә метафора булып килә: көз җитү илдәге гаделсезлекләр, сугыш китергән афәтләр буларак кабул ителә. *Мәңге чыкмаска батыр төсле, җиһанга, юк булып, / Күктә йөз чыткан кояш япкан йөзен, салкын караш!*[2] – дип, автор бу яшәештә, җәмгыятьтә хакыйкатьнең кешедән яшерелүен белдерә. Көзнең төн сурәте белән алмашынуы билгесезлекне тагын да көчәйтә, лирик геройның җәмгыятьтәге гаделсезлекләр белән бәйле

---

[1] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 242.

[2] Шунда ук. – Б. 242.

борчылу, ачыну хисен арттыра: *Төн караңгы, суык, мөмкин түгел тышта түзеп, / Төн җиле таушы колакларны китә өзеп-өзеп*[1]. Бу юллар, әйтерсең лә, кояшның мәңге чыкмаячагына, бәхетле тормышның беркайчан килмәячәгенә ишарә булып яңгырый. Шунысы кызык: кайчандыр егетнең әтисе дә шундый халәт кичергән. Ул юлга чыкканда, «кар ява, кар котрына», юл каплана: *Һич күренми юлчы юлда, булды төн – батты кояш*[2]. Шул рәвешле, әтисе, ягъни өлкән буын яшәешендәге вакыйгалар, кичерешләр яшь буын – аның улы белән дә кабатлана. Бу юллар кеше тормышындагы авырлыкларның даимилеген исбатлый. Шул рәвешле, эпик башлангычка йөз тоткан поэмада төн үткән һәм бүгенгенең очрашу урыны булып төгәлләшә. «Ике тормыш үзара бәйләнеп, сурәтләнгән дөнья икегә: якты, матур, җылы җеннәр тормышына һәм караңгы, ямьсез, өметсез чынбарлыкка аерып куела»[3].

Әсәр дәвамында кабатланган җил тавышы образына исә чорның шыксызлыгын, куркынычлыгын көчәйтү вазифасы йөкләнгәнбашкара. Кара буран, котырган кар, көчле җил кешелек яшәешенә метафора булып килә: җәмгыятьтә тәртипсезлек, хаос хөкем сөрә, алга бара торган юл билгесезлек томаны белән капланган. Ике геройның да күзенә йокы керми, бу – аларның ил гамен уйлауларын аңлата, әмма алар таңны көтә, ягъни киләчәккә өмет белән карый. Шул рәвешле, бу поэмада таң символы традицион мәгънәдә кулланыла.

Җен туен күрү вакыйгасы мифологик катламның эчтәлеген тәшкил итә. Ислам мифологиясе буенча, җеннәр явыз көчләрне гәүдәләндерә. Алар кешеләргә авыру, зәхмәт китерү, юлдан яздыру белән шөгыльләнәләр, шулай ук христиан динендә дә тискәре мәгънәдә атап

---

[1] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 242.

[2] Шунда ук. – Б. 242.

[3] *Гафиятуллина Н.М.* XX йөз башы татар шигъриятендә модернистик эзләнүләр // Фәнни язмалар – 2003. – Казань: Школа, 2004. – Б. 67.

йөртеләләр[1]. Әмма бу әсәрдә җен образына үзгә мәгънә салына. Көчле позиция алып, поэма исеменә чыгарылган җен туе образы биредә, укучы күзаллавындагы образдан бөтенләй читләшеп, семиотик билге буларак кабул ителә һәм символ дәрәҗәсенә күтәрелеп, чынбарлыкка каршы куела, кешеләрнең якты киләчәк, матур тормыш турындагы хыял-өметләрен гәүдәләндерә. Шул рәвешле, автор яшәп килгән мифны кире кага, «үзгәртеп кора». *Җен дигәч тә, җен үзенчә нәкъ безнең инсан кебек, / Шул вакыт җеннәр мине итте кадер, итте кунак*[2] дигән юллар аша, автор кешеләр арасында без начар дип карарга күнеккән җеннәрдән дә явызраклар бар икәнлегенә ишарә ясый. Җеннәр бу очракта адәм балаларыннан яхшырак та булып чыга. Шул рәвешле, халык аңында яшәп килгән, дини риваятьләр белән бәйле җеннәр турындагы күзаллау җимерелеп, аның эчтәлеге үзгә формада укучыга тәкъдим ителә. Әлеге үзенчәлек поэманы җитди антижанрга мисал буларак карарга мөмкинлек бирә.

Җеннәр геройның этисен мәгарәгә алып килә. Дөнья мифологиясендә, борынгы ышануларда мәгарә үзендә сер саклый торган урын буларак аңлатыла. Аңа керү юлы җир асты тормышына үтеп керү өчен хезмәт итә. Имеш, мәгарәгә кергән кеше яңа тормыш башлый, сынау үтә[3]. Бу әсәр мисалында да мәгарәгә керү кешенең тормыш хакыйкатенә төшенү юлына басуы кебек аңлашыла. Реаль һәм идеаль яшәеш чиге булган тау куышы ике дөньяны тоташтыра. Мәгарә эче реаль тормышка капма-каршы сурәтләнә: *Ул сарайның эче гәүһәр, якут-алтын гына, / Бик эссе түгел, җиңелчә, бертигез салкын гына, / Нәкъ сарайның эчләреннән чишмәләр шаулап агып, / Гөлләреннән тамчылап җиргә*

[1] Мифология. Энциклопедия / гл. ред. Е.М. Мелетинский. – М.: БРЭ, 2003. – С. 92.

[2] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 243.

[3] *Жульен Н.* Словарь символов. – Челябинск: Урал LTD, 1999. – С. 84–85.

*төшә нурлар тамып. / Ул сарай тулган хисапсыз чәчкә, яфраклы агач, / Моң түгәләр гөл ботагында тезелгән сандугач*[1]. Мондагы матурлык, иркенлек поэма башында бирелгән пейзажга каршы куела. Чынбарлыкта, реаль яшәештә көз, кыш фасыллары хакимлек итә: чәчәкләр көйгән, агачлар шыр ялангач, сандугачлар тынган, караңгы, шыксыз, ә сарайда исә гөлләр (матурлык символы) хуш ис таратып утыра, сандугачлар моңлы җырларын суза, «һәрвакыт сайрап тора «җен тәхетенә» былбыл кунып». Иң мөһиме: анда кануннар, тәртипләр башка: *Монда иркенлек, азатлык, юк күңелләр тарсыну, / Тарсыну юк, һичвакыт ялган «канун»га буйсыну, / Монда юк бер тиен өчен юк кан эчү, инсан талау, / Бай ягында «Ач хәррәфләр» юк тагын корсак ялау. / Бездәге төсле хиссез, пычрак, каралган җан белән. / Йөриләр җеннәр, түрәләр нәкъ намус-вөҗдан белән. / Бихисап җен мөлкәте: алтын-көмеш, алтын тәхет! / Бәлки булмастыр карун байда җыелган бу бәхет*[2]. Бу юлларда автор, киная алымына мөрәҗәгать итеп, кешеләргә хас тискәре сыйфатларны санап чыга; кешелек ялган кануннарга буйсынып яши, матди байлык өчен бар нәрсәгә әзер тора, түрәләр халыкны алдау, талау белән генә шөгыльләнә, дип фикерли. Ә җеннәр яшәеше исә – җир тормышының капма-каршы варианты, кешелек хыялындагы идеаль яшәү рәвеше, идеаль тормыш моделе. Бу – символик әдәбиятка хас ирреаль яшәеш хакындагы өйрәтүләр белән аңлатыла. Әлеге өйрәтүнең нигезендә дөньяның, чынбарлыкның, яшәешнең ямьсезлеген аңлау һәм бары бик аз кешегә генә гына тоемлау мөмкин булган чит яшәеш булу хакындагы тәгълимат ята. Язучы хыялында туган ирреаль тормыш чынбарлыкның капма-

[1] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 243.
[2] Шунда ук. – Б. 243.

каршысы буларак күзаллана, әдип, шул рәвешле, ике дөнья чигендә иҗат итүче рәвешендә чыгыш ясый[1].

Сарайда хакыйкать һәркемгә ачык, биредә ялганга урын юк. *«Гаршисендә нур төшә монда агып»*[2] дигән юлларда суфичылык әдәбиятыннан ук килгән нур образы хакыйкатьне аңлата. Ул чынбарлыктагы нурсыз, караңгы яшәешнең киресе төсендә сурәтләнә.

Поэмада Шәрык әдәбиятыннан килә торган җен кызы образының да символик мәгънәсе һәм вазифасы бар. Әлеге символ тамырлары белән татар әдәбияты үсешенә зур йогынты ясаган Көнчыгыш поэзиясенә барып тоташа. Шәрык әдәбиятында пәри образы символ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнә. Пәри Иран мифологиясендә, төгәлрәк әйткәндә Авестада, җәннәттән вакытлыча куылган, кешеләрне саклаучы буларак кабул ителгән, хатын-кыз рәвешендәге канатлы зат булып күзаллана. Бу образ, мәгънә ягыннан беркадәр үзгәреш кичереп, Лермонтов, Пушкин, Блок кебек рус әдипләренең дә иҗатына үтеп керә. Күчерелмә мәгънә алып, ул матурлыгы белән таң калдыручы хатын-кыз дигәнне аңлата башлый[3]. XX йөз башында рус символистлары да пәри образына еш мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, А. Белый «ангел-пери» дигән эпитетны матур һәм сөйкемле хатын-кыз турында язганда еш куллана. Без тикшергән поэмадагы җен кызы образы исә матурлык, камиллек символы булып төгәлләшә. Ә матурлык ул – бик тиз юкка чыга торган төшенчә, аңа кешелек тормышында урын юк, җәмгыять начарлык, явызлык белән тулган. Адәм баласы белән бер табактан аш ашаган җен кызы,

[1] *Быстров В.Н.* Идея преображения мира у русских символистов (Д. Мережковский, А. Белый, А. Блок): дис. ... д-ра филол. наук. – СПб., 2004. – С. 9.

[2] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 243.

[3] *Бертельс А.Е.* Художественный образ в искусстве Ирана IX–XV веков (Слово, изображение). – М.: «Восточная литература» РАН, 1997. – С. 142–144.

кешенең микроблары, ягъни күңелендәге явызлык хисе, табигатенә хас бозыклык, гөнаһ белән агуланып, аздан гына үлми кала. *«Һич килешмидер адәм чире безнең җен халкына*[1]*»*, – дип, автор начарлык, бозыклык, хөсетлекнең матурлыкны, изгелекне юкка чыгаручы төп сыйфатлар икәнлеген әйтә.

Җеннәр биргән алтын, байлык аша автор тагын бер фәлсәфи фикергә алып килә. Байлыгы бар чагында егетнең әтисе кадер-хөрмәттә яши, башкаларның ихтирамын казана, шул рәвешле, автор җәмгыятьтә кешене байлыгына карап бәялиләр дигән фикерне үткәрә. *Шаһ идем юл эчендә, ил эшен тордым карап, / Бихисап дәүләт бәхет, үтте гомер алтын санап! / Бәлки мин бер алпавыттан шәп идем, артык бугай? / Ул минем кулда иде чиксез болын-урман, тугай! / Яшь вакыт үтте гомер майга йөзеп, малга чумып, / Көн саен сайрап тора ак тәхтем былбыл кунып. / Уйладым бәхтем таңын һичбер вакыт сүнмәс кебек! / Күзләрем ил өстенә торды янып йолдыз кебек! / Шәүкәтем берлән даным тулган иде Чыңгыз кебек. / Дәүләтем диңгез иде, дошманыма һәм ярыма. / Кул җәеп тордым, фәкыйрь күрсәм – кулымда барына, / Ил күгендә ил күзен теккән гомерлек барына маһ идем. / Шәп иде, бик солтанат, шәүкәт нәфүзле шаһ идем!*[2] Әмма байлык – бик тиз юкка чыга торган әйбер. Дәүләт китү, акча бетү белән, башкаларның да сиңа карата мөнәсәбәте үзгәрә. Картның байлыгы бетүгә китергән вакыйга – җеннәр бүләк иткән атының ялын таравы. Монда әсәргә тагын бер ышану килеп керә. Халыкта: «Әгәр дә атның чияләнгән ялын берәү тарап куйса, ат иясе, ачуланып, бер минут тормый кача, имеш тә, шул көннән ат хуҗасының бәхете китә, фәкыйрьләнә», – дигән сүз бар[3]. Биредә кара ат – җеннәр тормышы, ягъни

---

[1] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 244.

[2] Шунда ук. – Б. 244.

[3] Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 239.

идеаль яшәеш турындагы хыял булып аңлашыла. Хыял юкка чыгу белән, киләчәккә ышаныч, максат бетә, байлык югала.

Автор фикеренчә, бу яшәеш дөрес түгел, кешеләр бер-берсеннән көнләшеп, акча колы булып гомер итәләр. Җәмгыятьтә ялган кануннар хөкем сөрә, идарә, хакимият халыкның иреген кысып, үзенә буйсындырып тора. Хакыйкатьне аңлаучылар, дөреслекне күрүчеләр дә уйларын, борчуларын эчкә яшерергә мәҗбүр. *«Уйладым бу җен туен мин, юрган астына ятып»*[1], – ди герой. Хакыйкать, әнә шул рәвешле, аерым берәүләрнең күңелендә генә яшеренеп яши ала, ә халыкның исә күзе томаланган. Сугышлар кешелекне әкренләп бетүгә илтә, дип чаң суга автор, шуңа күрә дә кешеләрнең күңелен өметсезлек, төшенкелек биләп алган, дип билгели. Б. Мирзанов мондый яшәешне кире кага, якты киләчәккә өмет кенә кешене дөнья ямьсезлекләреннән коткара ала дигән фикер үткәрә.

Габдрахман Сөнгатинең **«Хозыр»** поэмасы (1915) да – романтик рухта иҗат ителгән символик әсәрләрнең берсе. Поэманың нигезенә ислам мифологиясеннән билгеле Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләр турындагы миф салынган.

Әлеге поэма хакында XX гасырның икенче яртысында кайбер галимнәр тарафыннан фикерләр әйтелә. Мәсәлән, Х. Госман андагы төп фикернең явызлыкны актив көрәшеп түгел, ә түземлелек, сабырлык белән җиңү идеясен алга сөрүен билгели[2]. И. Нуруллин исә Г. Сөнгати, тормыштагы каршылыкларны күреп тә, аларны явызлыкка карышмау һәм әхлак төзәтү юлы белән хәл итмәкче була, дип яза[3].

---

[1] *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 244.

[2] *Госман Х.* Шигърият гомере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 36.

[3] *Нуруллин И.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – Б. 224.

Әсәрнең мифологик катламында лирик герой, юлда туктап, чанасына утырткан картның язмышы тасвирлана. Картның Хозыр пәйгамбәр икәнлеге әйтелә, аның адашкан лирик геройга юл күрсәтүче, аңа ярдәм кулын сузучы, ягъни үзенә хас сакраль вазифаны үтәүче акыллы карт архетибы булуы аңлашыла.

Поэмадагы икенче катлам автор тарафыннан яшәешкә бәя бирү өчен кертел. Әлеге романтик катламда да Хозыр образы үзәк урынны алып тора, бу катлам ә. Хозырның тормыш, юлчылар, гарәп иле турында сөйләгәннәре турыдан-туры шушы максатка хезмәт итә. Б. Мирзановның «Җен туе» әсәрендәге кебек үк, «Хозыр» поэмасында да кешелек яшәешенә метафора булып килгән буран образы әһәмиятле функция башкара. «Ачы» эпитетын куллану исә кешелек яшәешенең ни дәрәҗәдә буталчык, катлаулы, авыр икәнлеген тагын бер кат дәлилли. Традицион рәвештә, җил тормыштагы авырлыклар, сынаулар мәгънәсендә килә: *Менә ачы буран башланды, / Күрәсең бит: күз дә ачып булмый, / Җиле ничек уйнап сызгыра, / Кыяматме, бәбкәм, әй Ходаем, / Бөтен юлга буран туздыра*[1].

Чынбарлык – Кыямәт янәшәлеге үткәрелү яшәешнең мәгънәсезлеген тирәнәйтүгә алып килә. Алда маякларның да рәтләп күренмәве киләчәккә өметнең бик зәгыйфь булуын хәбәр итә. Юлчылар сурәте, гомумиләшеп, бөтен халыкны аңлата: *Бүген чиксез көчле бураны да – / Иртәгә күп булыр үлеләр... / Тәңре ярдәм итсен мескеннәргә, / Мескеннәрне Алла коткарсын, / Үлүчеләр бигрәк кызганыч бит, / Авызларына су соң кем салсын?. . / Мескен юлчыларга инде Тәңре / Үзе генә бирсен җайларын... / Шулай булмаганда, бу буранны / Ярамый да инде сөйләргә, / Кирәк бер Ходайдан, чын күңелдән, / Сау-сәламәт котылу теләргә...*[2] Димәк, татар милләтенең

[1] *Сөнгати Г.* Хозыр // Аң. – 1915. – № 4. – Б. 70.
[2] Шунда ук. – Б. 70.

үлемгә дучар ителгәнлеге тоемлана, Хозыр бу фаҗигадән чыгу юлын Аллага ялваруда, Тәңрегә сыенуда күрә.

Автор, карт образы аркылы, яшәешне шундый хәлгә төшергән сәбәпләр турында уйлана һәм фәлсәфи нәтиҗәләргә килә; карт туган гарәп илен сурәтләү аша, кешеләрнең кол хәлендә яшәве, бозыклыгы, бер-берсен үтерүгә кадәр барып җитүе һәм талау белән шөгыльләнүе кешелекнең юкка чыгуына китерүче төп шартлар булуын ассызыклый. Димәк, автор фикеренчә, явызлыкның чыганагы – кешенең үзендә. Халык мал артыннан куа, көнчелек утында яна, хаксызлыкка юл куя, кешеләрнең эчке дөньялары бозык, кара, күңелләре керле, намуслары пычрак. Автор, импрессионистик алымнарга мөрәҗәгать итеп, рухи дөньяның ямьсезлеген идеаль яшәеш үрнәге буларак кабул ителгән гарәп иленең илаһи табигатенә капма-каршы куеп сурәтли: *Беләсеңме, гөлләр чәчәк ата, / Исе бөтен җирне аңкыта? / Кояшы да кискен нуры белән / Нурга күмә, җирне балкыта... / Беләсеңме, төрле күбәләкләр / Чәчәкләргә кунып назлана, / Сихри аваз белән җырчы кошлар / Бигрәк кисә торган җыр чала... (... ) / Беләсеңме, аяз төннәрендә / Күкләрендә йолдыз уйнавын? <... > / Беләсеңме, зәңгәр, сихри төстә, / Күкрәгенә ямьле күлләрен, / Сәйярәләр белән тулган айның / Шунда төшеп уйнап-көлгәнен?*[1] Шундый идиллиядә яшәүче кешеләрнең явызлык кыла алулары Хозырны тәмам аптыраштa калдыра, укучыны да уйга сала.

Яшәешнең ямьсезлегенә икенче сәбәп тә Хозыр тарафыннан җиткерелә. Ул халыкны таркаулыкта гаепли, аны берләшергә чакыра һәм XX йөз башы татар әдәбиятында лейтмотив булып узган төп идеяне кабатлый: *Дидем: – Кардәшләрем, сез ни өчен / Бер-берегезнең каның түгәсез? / Нигә сез, кардәшләр, арагызда / Берлек җебен бушка өзәсез?.. / Әгәр сез ул җепне бер өзсәгез, / Таркалырсыз, җан-*

[1] *Сөнгати Г.* Хозыр // Аң. – 1915. – № 5. – Б. 89.

*сыз калырсыз! / Әллә кемнәр, читләр кул астында / Изелерсез, сызлап яњырсыз!..*[1] Бу сүзләр авторның XX гасыр башында татар милләтендә хөкем сөргән таркаулыкка һәм дәүләтнең мәгънәсез сугышлар алып баруына тискәре мөнәсәбәтен аңлата. Автор, дус булып, берләшеп гомер кичергәндә генә, милләт үзенең бәйсезлеген саклап кала алачак, киләчәктә бәхетле тормыш төзү мөмкинлегенә ия булачак, дигән фикерне үткәрә: *Шулай, дуслык белән торганда тик / Була-булыр сезнең юнегез...*[2]

Картның үлем белән очрашуы экзистенциаль фәлсәфәне үткәрергә мөмкинлек бирә. Аңа кадәр дә Хозыр кешеләрне хак юлга өндәп яшәгән, җирдә яхшылык орлыклары чәчәргә тырышкан, әмма нәкъ менә реаль гәүдәләнеш алган куркыныч үлемнең үзе белән очрашу мизгелендә ул яшәү мәгънәсен аңлаган, үзенең миссиясенә төшенгән. Җирдәге тормышның яхшырачагына өмет бик аз, гасырдан гасырга, елдан елга авырлык, мохтаҗлык, кешеләр арасындагы таркаулык, битарафлык арта барачак, дигән фикер туа, шуңа күрә ул мәңге шулай кешеләргә ярдәм итеп яшәргә тиеш. Хозыр, үлем белән очрашып, Аллага мәңгелек яшәү бирүен сорап мөрәҗәгать иткәннән соң, җиһанда тынлык хуҗа булып кала. Әлеге укылышта тынлык хакыйкать мәгънәсендә килә, ә хакыйкать кешенең тормыштагы урыны белән бәйләп аңлатыла. Үз гомереңне башкалар бәхете өчен корбан итү – иң көчле рухлылар гына булдыра ала торган эш. Хозыр нәкъ менә шундыйларның берсе булып тора.

Хозырның, әбелхәят суын эзләп, ямьле сахрага килеп чыгуы шыксыз чынбарлыкка капма-каршы куеп сурәтләнә: *Барып чыктым ямьле бер сахрага, / Чолганылган яшел агачтан... / Агачлары мәгърур үсеп тора, / Төрле чәчәкләрдән бизәлгән... / Күбәләкләр уйный чәчәкләрдә, / Сайрап*

[1] *Сөнгати Г.* Хозыр // Аң. – 1915. – № 5. – Б. 90.

[2] Шунда ук. – Б. 90.

*кошлар оча күкләргә, / Хуш ис борыннарны кисеп китә. / Бер гаҗәеп тәмле исләрдә... / Ул күлләре җәелеп ята, / Суы ага акрын, читеннән... / Чупыл-чупыл итеп ишетеләдер / Эчләрендә балык сикергән... <... > / Аһ... андагы сайрау авазлары / Күңелләрне ашра күкләргә. / Ишетсә бер кеше бер мәртәбә / Кайгырмаслар һич мәңге беткәнгә...*[1] Матурлык, гармония гәүдәләнеше булган бу табигать күренеше идеаль тормыш моделе булып аңлашыла.

Традицион рәвештә, Хозыр образын тудырганда, «ак», «пакь» эпитетлары киң кулланыла. *«Мескен бәндәләргә, зәгыйфьләргә / Изге ниятtә ак көн итәм мин»*[2], – дип, Хозырның изге күңеллелеге ассызыклана; *«сакалларым ак-пакь төскә керде»*[3] диюе үлемсезлек белән бергә кешеләргә ярдәм итү мөмкинлеге алуын, рухи чистарыну үтүен белдерә. Аклык, халык күзаллауларына хас булганча, изгелек, яхшылык, рухи сафлыкны гәүдәләндереп килә, Хозыр карт та кешелеккә якты юлга чыгарга ярдәм итүче булып сурәтләнә. Әмма мифларда гел ак, чиста киемнәрдән очраучы Хозыр портреты бу әсәр ахырында бөтенләй башкача тәкъдим ителә: *Килә юл буенча, дер калтырап / Өсте-башы тәмам тетелгән. / Борын очы, колак яфраклары / Өшеп, салкын белән өтелгән... <... > / Йөзе – сары, күзе эчкә баткан, / Йөзендә тапмассың зәрр бер нур, / Йөзе кайгы белән талангaн... / Маңгаенда тирән җыерчыклар – / Үткәргән кайгылар билгесе. / Йөзенә карап барын белү мөмкин, / Йөзе – узган тарих көзгесе...*[4] Картның чикмәне тетелеп беткән, бүреге кырык җирдән ямалган, чабатасы иске. Димәк, поэмада дини риваятьләрдән билгеле Хозыр белән бәйле сюжет эчтәлек ягыннан үзгәртеп корыла һәм антижанр тудырыла.

---

[1] *Сөнгати Г.* Хозыр // Аң. – 1915. – № 5. –Б. 92.
[2] Шунда ук. – Б. 110.
[3] Шунда ук. – Б. 110.
[4] Шунда ук. – Б. 69.

Ак, пакь, нурлы эпитетлары белән күзалланган традицион образ укучыга башлангыч формага капма-каршы рәвештә тәкъдим ителә. Шул рәвешле, бу портрет аша автор әсәренең төп идеясен җиткерә. Кешелектә аклыкка омтылыш юк, ул яхшылыкны явызлык белән алыштыра. Яшәештә хаос, тәртипсезлек хөкем сөрә, ил сәясәте, бетмәс сугышлар изгелекнең, рухи чисталык, сафлык, олы җанлылык кебек сыйфатларның Җир йөзеннән юкка чыгу куркынычын тудыра. «Бәндәләрнең канлы күзләре» яңадан-яңа корбаннар таләп итә. Алла тарафыннан кешеләргә ярдәмгә җибәрелгән изгелек иясе куылып яшәргә мәҗбүр. Әсәрдә бу яшәештә, бу җәмгыятьтә яхшылыкка, изгелеккә урын юк, дигән фикер үткәрелә. Г. Сөнгати билгеләвенчә, болай яшәү дөрес түгел, милли таркаулык, битарафлык, ахыр чиктә, халыкны кол хәленә төшерәчәк. Шагыйрь бу җәмгыятьтә хәтта Хозыр да асыл сыйфатларын югалткан, хәерче хәленә керә, ди кебек. Димәк, поэманың композицион бөтенлеген өч катламны бер төенгә бәйләп торган Хозыр образы тәэмин итә, әлеге образның мифологик тамырлары белән чынбарлыкның тыгыз бәйләнеше татар милләтенә дөрес юл күрсәтерлек шәхесләр хакында уйлануларга китерә.

А. Җәгъфәрнең **«Рух янында»** поэмасы (1916) структур яктан Рух һәм Кеше диалогы формасында төзелгән. Ул яшәп килгән мифны үзгәртү, ягъни демифологизация максатыннан язылган.

Мифологик катламда каберстандагы иске кабердән Рух тавышы ишетелү, аның моң-зарлары турында бәян ителә. Бу тавышны Кеше ишетә. Рух белән Кеше арасында милләт язмышы турында борчулы әңгәмә бирелә. Әсәр Кешенең көрәш рухы белән канатлануын, үз алдына максат билгеләвен тәгъбир итеп тәмамлана.

Символизмның төп категорияләреннән берсе – образның икепланлылыгы. Әлеге концепция символның эчтәлеген

гомумкабул ителгән контекстта, тәҗрибә һәм тоем белән бәйле аңлау яссылыгында карый[1]. «Рух янында» поэмасында да шулай: укучы, образның мифлардан билгеле булган беренчел мәгънәсен аңлаган хәлдә, аны милләт, кешелек, шәхес төшенчәләре белән бәйләп кабул итә, өстәмә эчтәлеген таба. Рух аллегорик образының мәгънәсе ике яссылыкта ачыла. Беренчедән, гомуми планда Рух татар милләтенең асылын, җанын, рухын гәүдәләндерә. Икенчедән яктан, ул милләтнең бер вәкиле булган Кешенең үз күңеленә, эчке дөньясына, намусына, вөҗданына мөрәҗәгате булып та аңлашыла. Шул рәвешле, поэманың структурасын тәэмин иткән диалог эчке монолог белән кушылып китә.

Рухның яшәү урыны – иске каберстан. *«Таң алды, каберстанда иске кабер, яргаланган зур кабер ташы, / байтак кыйсьме вак-вак кисәкләргә парчаланган»[2],* – дип сурәтли бу зиратны А. Җәгъфәр. Әлеге юллар татар милләтенә ишарәли төсле: яргаланган, онытылган кабер ташы кайчандыр данлы, шанлы булып та, хәзер кадере калмаган таркау милләтнең үткән тарихын гәүдәләндерә. Рухның бар борчуы, хәсрәте дә нәкъ менә милләт турындагы авыр уйланулар белән бәйле: *Яшәдем дөньяда чакта да мин халкым өчен егълап, / Хәзер дә ятам гүрдә аларның шау-шуын тыңлап. / Алар, белмим, яши алырмы икән дөньяда халык төсле? / Беләлмим шул, аларга дөньяда барча халык үчле. / Кем алган соң алардан иске-бабайлар рухын? Белмим. / Элекке кан тамырларында калмаган микән, дим мин. / Кая дөньяда тетрәткән татар нәселе җир өстендә? / Яшиме-юкмы инде алар инде бу көндә?[3]*

Рухның хәсрәтле сүзләре турыдан-туры җәмгыятькә бәя бирү белән бәйле тәнкыйди фикерләргә барып тоташа.

---

[1] *Обломиевский Д.Д.* Французский символизм. – М.: Наука, 1973. – С. 102.

[2] *Җәгъфәр А.* Рух янында // Аң. – 1916. – № 10. – Б. 162.

[3] Шунда ук. – Б. 162.

Автор милләтнең хәзерге яшәешен тәнкыйтьли, аның фикеренчә, татар халкының аяныч халәте, тарих сәхнәсеннән төшеп баруы, иң беренче чиратта, башка халыкка кол булып яшәве белән бәйле. Халыкның үз сүзен әйтергә мөмкинлеге юк, аның куллары гына түгел, уйлары да богаулы. Татар милләте башка халыкның мәнфәгатьләрен кайгыртып, аларның таләпләренә җавап биреп яшәргә мәҗбүр. Илдә хакыйкатьнең булмавы аеруча аянычлы нәтиҗәләргә китерә: *Сиңа «ул» бер караңгы төнне «бу яп-якты көн» дисә, / «Дөрест», дип чынламасаң, билгеле, ул башыңны кисә...*[1]

Әсәрнең беренче өлешендә халыкның киләчәге яхшы булачагына өмет юк дәрәҗәсендә: *Шулай менә бу ташлар бу җирдә тордылар байтак, / Ни хәтле каты булсалар да, тетелделәр вак-вак. / Табигать бәрми-сукмый ваклагачтын инде ташларны, / Тагын туфракка әйләндерер ул, билгеле, анларны. / Шулай ук бу халык та әйләнер бер иске хәлләргә. / Тагын саф, чын каны кайтыр кибеп беткән бәдәннәргә...*[2] Исәннәр галәменнән хәбәр алып килгән Кеше дә Рухның ачынуларына дәва бирә алырлык сүз әйтми. Милләтнең хәзерге хәле Рух күз алдына китергәннәрдән дә авыррак.

Кеше образы милләт бәхете өчен көрәшүче хөр улларны гәүдәләндерә, әмма аның да өмете киселгән, көрәшергә хәле калмаган, ул фани дөнья мәшәкатьләреннән котылу алып килгән әҗәлне бәхет итеп тану дәрәҗәсенә җиткән: *Бәхетле җан... Мине дә бергә ал үзең белән зинһар! / Торалмыйм мин дә артык, миңа да бу дөнья бик тар. / Бу дөньядан китү юлын мин эзлим күптән үк инде. / Минем түземле, батыр җанны дөнья күптән үк җиңде*[3].

Поэмада сурәтләнгән дөнья өмет / өметсезлек кысаларында тасвирлана. Кеше хыялларының буш булып чыгуын,

---

[1] *Җәгъфәр А.* Рух янында // Аң. – 1916. – № 10. – Б. 162.
[2] Шунда ук. – Б. 162.
[3] Шунда ук. – Б. 163.

өметләренең тормышка ашмаячагын уйлап борчыла, хәсрәтләнә. Анның тырышлыгы милләткә каршы кара көчләр аркасында юкка чыгып бара. Тирә-якта икейөзлелек, намуссызлык хөкем сөрә, дөньядагы кыйммәтләр бөтенләй үзгәргән: дус дип йөргән кешеләр бар да явыз җанлы булып чыга, бер диндәге, бер кандагы халык бер-берсе белән дошманлашып көн күрә, ә үз кан-кардәшенә кул күтәргән кешелекнең киләчәге намуслы юлга илтми: *Бары бер дин вә бер кан булсалар да үзләшмиләр, / Берен-берсе ашый, һич тә беренберсе күралмыйлар. / Бу тоткан юллары алып бара иң-иң начар җиргә... / Үз мәсләген ташлау – кяферлек могтәбәр иргә...*[1] Дөреслекне, хакыйкатьне яклаучы, халыкның хаталарын кычкырып әйтергә курыкмаучылар – аларның иң төп дошманнары. Кешенең шул сәбәпле хыял канатлары сынган, ул Алладан үлем турында гына ялварырлык халәттә.

Әлеге поэмада язучы тарафыннан катлаулы проблема күтәрелә. Татар милләте юкка чыгу алдында, ди ул. Иң аянычлысы: уртак тарихлы, бер тамырлы кардәш халык берберсе белән дошманлашып гомер итә, ә бердәм булмаган таркау халыкны буйсындыру, юкка чыгару – башкалар өчен бик җиңел эш. Әмма поэманың ахыры өметле рухта тәмамлана: Рух Кешене халык гаме белән, милләт язмышы өчен борчылып яшәргә чакыра, анның тырышлыгын күрми калмаслар, халык гамьсезлек йокысыннан уяныр, дигән өмет алга чыгарыла: *Кереш халыкка хезмәткә! Яңадан эшеңне җайлап. / Синең үлмәс йөрәкле бер батыр адәмлегең күргәч, / Сиңа аяк чалучылар да үз хәлләрене белгәч, / Аларның, билгеле, какшар каты таштай күңелләре, / Чәчәк атар, тамырланыр собатыңның нур гөлләре*[2].

Автор үткәргән төп идея түбәндәгедән гыйбарәт: милләтнең хәзергесе аяныч, таркаулык, бердәмлек булмау аны

[1] *Җәгъфәр А.* Рух янында // Аң. – 1916. – № 10. – Б. 163.
[2] Шунда ук. – Б. 163.

әкренләп какшата, тамырын корыта, шулай да өметсезлеккә бирелергә ярамый, халыкны азатлык өчен көрәшә алучы хөр фикерле, яшәү максатын халык гаме белән бәйләүче кешеләр саклап кала ала. Поэманың соңгы юлларында Кешенең үз алдына куйган максаты шуңа дәлил булып яңгырый: *Раббым, явызларның шармыннан (оятыннан) сакла, рухым сүндермә! / Асыл максатка җитмичә, тәнемне җиргә күмдермә!*[1]

Шул рәвешле, югарыда анализланган үрнәкләрдән күренгәнчә, поэмаларда ислам мифологиясеннән килеп кергән образлар, нигездә, милләт яшәешенә, гомумиләшеп, кешелек тормышына бәя бирүгә юнәлтелә. Әсәрләрнең күбесе демифологизация – яшәп килүче мифны кире кагу, юкка чыгару юлы белән иҗат ителгән.

XX йөз башы поэзиясендә, аерым алганда лиро-эпик төрдә, төрки-татар ышануларына бәйле мифологик образлар да еш кулланыла. Шундыйлардан берсе – Су анасы образы – татар әдәбиятына Г. Тукай шигыре белән бергә килеп керә. 1908 елда язылган әсәрендә шагыйрь төрки-татар ышанулары белән бәйле мифны яңадан торгызып, һич үзгәртүсез диярлек тасвирлап бирә. Әсәрдә әлеге образ риваятьләрдән билгеле булган сыйфатларын саклый, явыз зат буларак сурәтләнә. Тукай тарафыннан әдәби әйләнешкә кертеп җибәрелгән Су анасы образы аннан соң иҗат иткән авторларның әсәрләрендә дә киң кулланыла.

Мәсәлән, Г. Сөнгатинең **«Су анасы»** балладасы (1915) А. Дружининның «Русалка»сына ияреп язылган. Биредә инде укучы мифологизация күренеше белән очраша: Г. Сөнгати, Су анасы белән бәйле риваятьләргә таянып, яңа миф иҗат итә.

Поэмада мифологик һәм романтик катламнар үзара тыгыз үрелеп бара. Әсәр күңелсез уйларга бирелгән егетнең, Су анасына гашыйк булып, тормышыннан ямь табуын

[1] *Җәгъфәр А.* Рух янында // Аң. – 1916. – № 10. – Б. 162.

сөйләү белән башланып китә. Егетнең күңел халәте үзгәрештә бирелә. Башта ул рухы төшеп, күңелсезлектән иза чиккән итеп сурәтләнә: *Минем рухым чиксез төшкән иде, / Тезмә-тезмә килгән кайгыдан. / Йөрәк, рәнҗеп, ачы сызлый иде, / Болганайде ялкын кан белән... / Минем рухым томан чолгап алган, / Хөкем итә тәмсез хыяллар*[1]. Егет мәхәббәтен табудан өмет өзгән. Пакь сөюләр инде узган, бәхет кошы очып киткән төсле. Ләкин Су анасын күрү белән, ул аңа гашыйк була һәм аның эчке кичерешләре кискен үзгәрә: *Сандугач та сайрап җибәрде. / Исеп әкрен генә җәйге саф җил, / Күләгәләр әкрен тирбәлде...*[2] Шул вакытта әсәргә романтик детальләр килеп керә. Мәсәлән, мәхәббәт белән бәйле очу мотивы шундыйлардан: *Очты күңлем күккә, гаршеләргә, / Үтте йолдызларның эченнән, / Очты күңлем, әмма айрылмады / Аның сихри матур төсеннән...*[3] Мәхәббәтен табу белән, егетнең киләчәккә өмете дә арта, ә өмет исә якты таң гыйбарәсе аша бирелә: *Гөлләр, ал чәчәкләр тәбрик итә, / Сандугачлар сайрап хәл сорый*[4].

Гомумән, символист язучылар тарафыннан әфләтүн мәхәббәтенә зур урын бирелә. Рус символисты Вл. Соловьёв фикеренчә, ир кеше хатын-кызга булган мәхәббәте аша гына үз-үзен яратуын чикли ала. Мәхәббәтнең чын асылы – идеаль, абсолют шәхес барлыкка китерү һәм шуның аркылы «яшәешнең бөек сере»нә төшенү, Яхшылык һәм Матурлык берлегенә ирешү[5]. Әмма бу әсәр тукымасында әлеге идея бөтенләй башка яссылыкта ачыла. Егетнең мәхәббәте кыска гомерле булып чыга, Су анасы сөюен башкага тәкъдим итә. Ул, гомумән, ярата белми. Егетнең бар тормышы газапка

---

[1] *Сөнгати Г.* Су анасы // Аң. – 1915. – № 15–16. – Б. 260.
[2] Шунда ук. – Б. 261.
[3] Шунда ук. – Б. 261.
[4] Шунда ук. – Б. 261.
[5] *Колобаева Е.В.* Русский символизм. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 2000. – С. 157.

әйләнә, уйлары Су анасы белән генә бәйле була. Күл буенда кичергән бәхетле минутлары исә төш кебек кенә тоела башлый. Егетнең күңелендә туган ачы хисләр, мәхәббәтен югалту газабы буран метафорасы ярдәмендә тасвирлана: *Хаятымда тормыш бураны... / Катты минем күңлем шул бураннан*[1].

Су анасы бу әсәрдә мифологик су кызы булып аңлашыла. Русалка – европа мифологиясендә балык койрыклы, кыз башлы, кыз тәнле уйдырма зат. Каты хисле, салкын җанлы булуы белән диңгездә корабларны адаштырңы хакында легендаларда сөйләнелә[2]. Татар хикәятләрендә Су анасы бик нык кешегә охшатып сурәтләнә. Ул кешеләргә су читендә чәчен тарап утырган хәлдә очрый. Кинәт, көтмәгәндә, янына кеше килеп чыкса, ул тиз генә суга кереп китә, хәтта алтын тарагын алырга да оныта. Тарагын алып киткән кешене бик тиз эзләп таба. Тарагын алып киткән кешене җәфалап интектерә, таракны кабат урынына илтеп куйганчы, аның ишеген, тәрәзәсен шакудан туктамый... Татар риваятьләрендә Су анасы явыз затлардан санала. Ул балаларны, йөкле хатыннарны алырга мөмкин, еш кына үзенә корбан бирүләрен таләп итә[3]. Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, әлеге поэмада Су анасы мифологик образы үзенең риваятьләрдән килгән үзенчәлекләрен саклый. Ул кеше күзенә төнлә генә күренә, кыяфәте дә хикәятләрдә сурәтләнгәнгә туры килә. Әмма әсәргә ул – егеткә, кешелеккә бәя бирү максаты белән килеп керә. Милли эчтәлеккә төрелгән әсәр, билгеле форманы үзгәртеп, шартлылыкка нигезләнгән субъектив катламны калкыта. Ул катлам яшәешкә бәя бирү белән бәйле һәм тәнкыйди характерда. Автор шул чор яшәешен тасвирлап,

[1] *Сөнгати Г.* Су анасы // Аң. – 1915. – № 15–16. – Б. 262–263.

[2] Эпик шигърият: ХХ йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 452.

[3] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. –1996. – 1 т. – Б. 131–132.

аңа тискәре бәя бирә: *Күптән узды инде матур язым, / Былбылларым күптән очтылар. / Күптән кояшларым саф күгемнән / Ерак тауга китеп постылар... / Алып китте барсын тормышымның / Сахрасыннан искән бураннар. / Илтеп чәчте барсын җәһәннәмгә, / Күптән анда көл дә булганнар*[1].

Кешеләрнең хыяллары сүнгән, «матур яз» метафорасы белән бирелгән бәхетле чорлары инде күптән юкка чыккан. Халык үзенең хакыйкать, дөреслек турындагы фикерләрен күңел түренә яшерергә мәҗбүр: *Инде күзли минем һәр адымымны / Ямьсез көзнең залим төннәре. / Күптән минем арттан ялтырыйлар / Иблис күзе-кызыл күзләре...*[2] Бу өзектәге ямьсез көз, залим төн метафорик образлары яшәешкә бәя бирү өчен кулланыла. Шул рәвешле, автор тормышның авырлыгына, караңгылыгына, залимлегенә ишарә итә. Һәр кешенең артыннан канга туймас Иблис күзе – сәясәтнең, яшәү явызлыгының шымчылык итүе ямьсез чынбарлыкка хәсрәтләнү хисенең дәрәҗәсен тагын да арттыра.

Су анасы, семиотик билге, символ дәрәҗәсендә кабул ителеп, кешеләрнең, тормыш авырлыгыннан, ямьсезлектән юану табу өчен, саф мәхәббәт турында хыялларын гәүдәләндерә. Ул матур, әмма салкын. Әйтерсең лә, автор бу яшәештә матурлыкка, мәхәббәткә урын юк, дип ясларга омтыла.

Габдулла Харисның **«Өрәк»** поэмасы (1915) – реалистик, мифологик һәм символик катламнарның синтезы төсендә иҗат ителгән әсәр. Ул җитди антижанрга мисал булып тора.

Реалистик катлам җәмгыятькә бәя бирү белән бәйле һәм лирик геройның шәһәрдән авылга кайту юлын үз эченә ала. Автор биредә, табигатьтәге гармонияне сурәтләп, авыл яшәешен шәһәр яшәешенә каршы куя. Шәһәр / авыл оппозициясе романтизмдагы дихатомия принцибы белән бәйле. Шәһәрне лирик герой зиндан белән чагыштыра, анда кешеләр канун-

---

[1] *Сөнгати Г.* Су анасы // Аң. – 1915. – № 15–16. – Б. 260.

[2] Шунда ук. – Б. 260.

нарга буйсынып гомер итә дип билгеләнә. Шул рәвешле, шәһәр тормышын – кешелекнең чынбарлыкта яшәеше, ә авылны ирек, хөрлек хөкем сөргән идеаль яшәеш дип карарга мөмкин: *Юк офыкта һич болытлар, су кеби киң күк аяз, / Анда сайрый тирбәлеп торган матур, моңлы аваз. / Нәкъ яшел диңгез кеби кырлар, болыннар һәм ялан, / Ул киенгән төрле төстәге чәчәкләрдән алан*[1].

Лирик герой яллаган атның хуҗасы әдәбиятта киң кулланылган карт архетибы булып төгәлләшә. Ул лирик геройга чынбарлык турында сөйли, аңа дөреслекне ачарга ярдәм итә. Аның өрәк турында сөйләгән хикәяте мифологик катламның нигезендә ята.

Өрәк – Идел буе, Урал төркиләрендә киң таралган мифик персонаж. Өрәк үтерелгән кешенең каны агызылган җирдә яисә көчләп үтерелгән кешенең кабер өстендә күренә. Көчләп үтерелгән кешенең рухы әнә шулай үзенә тынычлык таба алмыйча йөри. Өрәк кешеләргә турыдан-туры зыян салмый. Әмма ул төннәрен кеше каршысына килеп чыга, яисә артыннан ияреп барып, аның котын ала[2]. Бу әсәрдә дә өрәк картка төнлә күренә. Карт Казанга ялгызы гына чыгып китә. Аның юлга бер дә күңеле тартмый, хатыны, балалары да елашып озатып кала, әмма бармыйча булдыра алмый, чөнки заманалар начар, яшәү өчен һәркем үзе булдыра алганча тырыша: *Мин алардан бер сәгать тә айрылып тормас идем, / Тик менә ел әйләнерлек булса иде кершем минем. / Булмый дөньяны куып бик, кул шуңа иркен түгел, / Эшләмичә көн күрү ул һич миңа мөмкин түгел. / Әллә кемнәрдәй кеше хакын ашауны мин сөймим, / Акчалы комсыз юаннарга гомер дә баш имим*[3].

[1] *Харис Г.* Өрәк // Альманах. – Казан, 1915. – Б. 31.

[2] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. –1999. – 2 т. – Б. 135.

[3] *Харис Г.* Өрәк // Альманах. – Казан, 1915. – Б. 33.

Карт сөйләгәннәрдән караңгы төннең метафора булып килүе аңлашыла. Ул – чынбарлыкның ямьсезлегенә, һәр адымда кешене куркыныч сагалавына, билгесезлек изалавына ишарә: *Ат бара әкрен генә бик, ниндидер юл белән, / Майламагангадыр, арба шыгырдый ком белән*[1]. Биредә арба шыгырдавы киләчәк авырлыклар, бәлаләр турында кисәтү булып яңгырый.

Мифологиядә өрәкнең кешеләрне юлдан адаштыруы хакында да хәбәрләр күп. Аның да, кешеләр кебек, арбачанага утырып йөрисе килә, имеш. Ул юлчы кыяфәтенә керә дә, ялгыз арбада утырып барган кешене туктатып, утыртып баруын үтенә[2]. Габдулла Харис әсәрендә дә өрәк карт артыннан иярә. Өрәкне ул түбәндәгечә сурәтли: *Баштанаяк ак кәфен берлән төренгән ул үзе, / Тик ачык калган аның чиктән тыш ямьсез йөзе. / Без кеби күзләр, борын җәйпәк, яңаклар ач аның, / Зур авыздан ыржаеп күрнеп тора тешләр тагын. / Кашлары, керфекләре юк, мыегы һәм сыңар канат, / Мин кинәт, арбамда күргәч тә аны, каттым карап. / Кизләнеп беткән сакаллы, зурлыгы – мәсле көрәк*[3]. Бу юллардан өрәкнең символик образ булуы ачыклана, ул җир тормышындагы ямьсезлекне гәүдәләндерә. *Уңда-сулда, артта-алда шул рәвеш күрдем аны, / Күккә баксам, баш очымда күз йомып күрдем тагы*[4], дип, автор тормыш авырлыгыннан, яшәү ямьсезлегеннән чыгу юлы булуга ышанычы бетүен белдерә, тормыш авырлыгының кешелекне тәмам басуы турында сөйли. Аны һәрьяклап мохтаҗлык, юклык, хәсрәт чолгап алган, киләчәккә өмет сүнгән.

Карт, күпме тырышса да, өрәкне куып җибәрә алмый. Ягъни ул, ничаклы тырышса да, мохтаҗлыктан котылу

[1] *Харис Г.* Өрәк // Альманах. – Казан, 1915. – Б. 33.

[2] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. –1999. – 2 т. – Б. 136.

[3] *Харис Г.* Өрәк // Альманах. – Казан, 1915. – Б. 34–35.

[4] Шунда ук. – Б. 35.

юлын тапмый, һаман газапланып җан асрарга мәҗбүр. Мифологиядә һәлак ителгән кеше җанының өрәк булып күренүе турында алда әйтелде инде. Бу әсәрдә дә, әйтерсең лә, көчләп юк ителгән ирек, хөр тормыш, хакыйкать үзенә тынычлык таба алмыйча, кешеләрнең күңелен уятырга омтылып сыкрап йөри.

Төрки-татар мифологиясендә, өрәктән котылу өчен, аны бик каты сүгәргә, тиргәргә кушыла. Инде алай да котылып булмаса, атны тиз генә тугарып, аны тискәрегә җигәргә кирәк. Ут яки берәр карт, бала-чага булып ияргән өрәк шунда ук юкка чыгачак[1]. Карт нәкъ шулай эшли дә, әмма бу әсәр кысаларында атны кире якка каратып җигү һәм кирегә алып китү башка мәгънәдә ачыла. Автор бу вакыйга аркылы төп идеяне үткәрә: кешеләр дөрес яшәми, бу яшәеш үзе үк кешелекне рухи яктан юкка чыгарачак, ачлык, мохтаҗлык, сугышлар халык иңенә күтәрә алмаслык йөк булып ята, тормышны тамырдан үзгәртү, сугышларны бетерү генә чынбарлыкны, яшәешне яхшыртугырга мөмкинлек бирәчәк.

Югарыда тикшерелгән әсәрләрдән күренгәнчә, бу чорда иҗат иткән әдипләрнең барысы да диярлек мифологик образларны үз әсәрләренә яшәешнең ямьсезлеген күрсәтү, заман авырлыгын ассызыклау өчен кертәләр. Аларның әсәрләре ачыну, хәсрәт хисләре белән сугарыла, гомумкабул ителгән формалар милли рух белән өретелә, милли эчтәлек ала, төн образының хронотопта төп урын биләве яшәеш ямьсезлеген көчәйтә. Әсәрләрнең күбесендә киләчәктә тормышның яхшырачагына өмет юк дәрәҗәсендә.

Имаметдин Шаммасиның **«Убыр»** (1914) лиро-эпик әсәре болардан беркадәр үзгәрәк характерда булуы белән аерылып тора. Убыр – дөнья мифологиясендә иң киң таралган түбән

[1] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. –1999. – 2 т. – Б. 136.

рухларның, явыз көчләрнең берсе[1]. Ул татар халык мифологиясендә ике төрле сурәтләнә. Бер төрлесе аерым зат, ия, рух сыйфатында мөстәкыйль гомер сөрә. Кеше рәвешендә күренгән бу Убырның кыяфәте аеруча куркыныч: башы – туп кебек түгәрәк ут, койрыгы нечкә, озын, яшелле-күкле-зәңгәрле утлы, ялкынлы төтен булып сузылган, кичен яки төннәрен ул еш кына җиргә тияр-тимәс ут йомгагы булып тәгәрәп йөри, я тубал кадәр ут булып, тирбәлеп торучан була. Икенче бер төрлесе кешенең үз эчендә гомер кичерә[2].

«Убыр» поэмасында без икенче төр Убыр белән очрашабыз. Мифологик катламда бер егеткә Убырның ияләшүе, төнлә янына килеп, таңга кадәр торуы турында сөйләнә. Сатирик рухта иҗат ителгән бу әсәрдә Убыр, риваятьләрдә сөйләнгәнчә, һич тә куркыныч түгел. Автор аны «матур» кыз сурәтендә бирә: *Алгы яктан ул кыз үзе бик матурдыр, / Гүя инде җәннәттән чыккан бер хурдыр, / Аның фәкать шушы җирләре килмәгән, / Аузы кыек, бер күзе юк, борны зурдыр. / Арт ягыннан карарлык та түгел аңар, / Асылгандыр иләк, чиләк, чабаталар, / Себеркеләр, иске ыштан балаклары, / Йозак, ачкыч – аның артында бар да бар*[3]. И. Шаммаси, шул рәвешле, киная алымын төп принцип итеп алып, Убырның сатирик сурәтен тудырып, демифологизация күренешенә мөрәҗәгать итә. Убыр кеше күңелендәге явызлык, ямьсезлек символы булып төгәлләшә. (Шул чор яшәешенең төп үзенчәлекләре дә – явызлык, ямьсезлек, хәерчелек). Кеше тормышның тышкы матурлыгына, алдавыч вәгъдәләренә ышанып яши бирә, ә чынлыкта җәмгыятьтә икейөзлелек патшалык итә. Автор кеше рухы моделен әнә шундый итеп күзаллый.

---

[1] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. –1999. – 2 т. – Б. 27.

[2] Шунда ук. – Б. 31.

[3] *Шаммаси И.* Убыр // Аң. – 1914. – № 5. – Б. 101–102.

Шулай итеп, XX йөз башы татар сүз сәнгатендә мифологик образларга мөрәҗәгать иткән күпсанлы поэмалар языла. Мифологик шәхесләр ике төр әсәрләрдә кулланыла: романтик әсәрләрдә – билгеле бер фикер үткәрү өчен кертелгән образлар сыйфатында, символик иҗатта – төп төшенчә, семиотик билге буларак. Нигездә, авторлар ислам мифологиясе белән бәйле образларны үз әсәрләренең сурәтләү объекты итәләр, ә инде Г. Сөнгати, И. Шаммаси, А. Җәгъфәр кебек шагыйрьләр төрки-татар ышануларыннан ук килгән Су анасы, Убыр, Өрәк кебек образларны да сурәтлиләр.

Галимнәр билгеләвенчә, мифның әдәбиятта чагылышы, бер яктан, традицион мифологик образ һәм сюжетлар белән «уен» рәвешен алса, икенче яктан, авторның яшәешне күзаллавына бәйле төстә мифның үзгәртеп корылуы һәм яңа мифологик реальлекнең тууы рәвешендә бара. Бу яңа реальлек үзендә борынгы миф, борынгы аң-фикерләүнең томанлы хәрәкәте турында «истәлек»ләрне саклый[1]. Беренче очракта сурәтләнгән вакыйгалар һәм персонажлар үзләренең индивидуальлеген югалталар һәм борынгы мифларда кабул ителгән яшәеш, алдан билгеле схеманың мәңге кабатлана торган бер варианты буларак кына яши башлыйлар. Икенчесендә язучы үзенең әсәрендә үзе урнаштырган кагыйдәләр буенча корылган уйланма чынбарлык тудыра[2]. Без мифологик образлар бирелеше ноктасыннан тикшергән символик әсәрләрнең барысы да икенче юнәлешкә нигезләнеп иҗат ителгән. Аларда дини һәм мәҗүси мифлар белән бәйле образлар автор тәкъдим иткән структурага буйсындырыла, әдипләр үткәргән идея-фикерләргә мөнәсәбәтле кулланыла.

[1] *Максимов Д.Е.* О мифопоэтическом начале в лирике Блока // Уч. зап. Тартус. ун-та. Вып. 459. Творчество А.А. Блока и русская литература XX века. Блоковский сборник III. – Тарту, 1979. – С. 7.

[2] *Дорошевич А.* Миф в литературе XX века // Вопросы литературы. – 1970. – № 2. – С. 122.

Мифологик шәхесләрне сурәтләгән әсәрләр, нигездә, кешелек яшәешенә, кеше күңеленә бәя бирү йөзеннән иҗат ителгән, бу образлар күп очракта явызлык, авырлык, ямьсезлек символлары булып тәгәлләшә. Фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, гомумбилгеле мифлар һәм легендалар яңа мәдәни-тарихи контекстта заманлаштыруга дучар ителә һәм халыкның милли психологиясе таләпләренә яраклаштырыла. Әлеге процесста миф хронотобы белән укучы яшәгән чор арасында чикләр җуела. Тәгәлләнмәгән бүгенге һәм ябык, тотрыклы кыйммәтләре формалашкан үткәннең берлеге дөньяның вакыт ягыннан катлаулы (милли яки гомумкешелек) моделен барлыкка китерә. Гадәттә, контекстта бу вакыт киләчәккә таба омтылган була[1]. Без югарыда карап киткән әсәрләрдә дә әлеге үзенчәлек ачык чагылыш таба. Гомумбилгеле мифларга мөрәҗәгать итеп, татар шагыйрьләре чор белән кисешү ноктасын табалар, мифологик геройларны заманга хас булган сыйфатлар белән баеталар.

Татар әдәбияты тарихында символизмның башкачарак йогынтысы да күзгә ташлана: кайбер әсәрләрдә аерым бер күренеш кенә символ булып калмый, ә тулаем бер миф, риваять символ булып санала. Еракта калган вакытка мөрәҗәгать итеп, аны хәзерге заман белән кисештерү аркылы мәңгелек охшашлыклар һәм символлар туа. Татар әдәбиятында билгеле булган Айсылу, Зөһрә кыз, Сөембикә, Алтынчәч, Чыңгыз, Идегәй, Чура батыр, Сатыш һ.б. тарихи-мифологик шәхесләр әсәрләр үзәгенә куела һәм нәкъ менә халыкны үз артыннан ияртерлек яңа идеал – нәби кебек гәүдәләндерелә. Н. Думавиның **«Шәрык даһие»** (1915) поэмасы шушы тенденциягә нигезләнеп иҗат ителгән. Поэманың үзәгендә Чыңгыз образы тора. Автор аны әкият каһарманнарына тар-

[1] *Нямцу А.Е.* Миф и легенды в мировой литературе: Теоретические и историко-литературные аспекты традиционализации. Ч. 1. – Черновцы: Черновицкий госуниверситет, 1992. – С. 9–11.

тым итеп сурәтләгән (ул гадәттән тыш акыллы, көчле: *Таш маңгае, күкрәк тимер, күзләре зур, / Йөзендә балкый аның котлы нур. / Дәрт бөтен, гайрәт алмаз, корычтан кул, / Кем белән алышса да белмидер хур*[1]) әлеге шәхес, әсәрдәге үзәк төшенчә ролен алып, символ дәрәҗәсенә күтәрелә һәм акыл белән көчне гәүдәләндерә башлый. Поэманың башында ук сурәтләнгән хан туу вакыйгасы табигать стихияләренең дә аңа буйсынуын аның, алдында баш июен җиткерә һәм Чыңгыз турындагы мифны Ницше өйрәтүләре белән бәйләп куя. Д. Заһидуллина хезмәтендә «Ницшеның “гадәттән тыш кеше” хакындагы тәгълиматы төрлечә шәрехләнә, ләкин бер аңланылыш варианты – илаһи кеше кебек интерпретацияләү мөселманнарның дини-суфичыл тәгълимат буенча таныш камил инсан концепциясенә аваздаш була»[2], диелә. Рус символистлары, философ-идеалистлары тарафыннан да «гадәттән тыш кеше» әхлакый идеал кебек күзаллана[3]. А. Белый билгеләвенчә, Ницше өйрәтүләре Европа цивилизациясе күрмәгән яңа дари, яңа Кеше образын тудыра[4]. Бу ярыммифик шәхес рус символистларын, модернистларын шул ягы белән җәлеп итә дә: «сверхчеловек» кешедәге яшәү һәм иҗат көчен берләштергән, символлаштырган рухи идеал, үрнәк тип булып кабул ителә[5]. Әлеге поэмадагы Чыңгыз да – дөньяга шаһ булырга килгән, кояш белән сөйләшергә хокуклы зат, гадәттән тыш кеше, ярымилаһи зат (богочеловек)[6]. Бу фикер

---

[1] *Думави Н.* Шәрык даһие // Аң. – 1915. – № 7. – Б. 130.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 173.

[3] *Синеокая Ю.В.* Рубеж веков: русская судьба сверхчеловека Ницше // Ф. Ницше и философия в России. – СПб., 1999. – С. 58.

[4] *Белый А.* Символизм как миропонимание. – М.: Республика, 1994. – С. 178.

[5] *Гафиятуллина Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә Тукай. – Казан: Матбугат йорты, 2002. – Б. 27.

[6] *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 177.

әсәрдәге тагын бер шартлы образ – кояш символы ярдәмендә ачыклана. Кояшка табыну, үзеңне кояш баласы итеп тою тенденциясе XX гасыр башы рус шигъриятендә һәм фәлсәфәсендә дә очрый[1]. Әдәбиятта әлеге образның хакыйкатьне белдергән традицион мәгънәсе билгеле. Шул ук вакытта рус әдәбиятында аның ирек мәгънәсен җиткерүе дә мәгълүм[2]. «Шәрык даһие» поэмасында әлеге символга власть, хакимлек төсмере дә өстәлә, һәм ул Чыңгыз образын ачуга ярдәм итә. Беренчедән, кояш Чыңгызның бөеклегенә ишарә итсә, икенчедән, аның яшәү максатын ачыклый: акыл ярдәмендә яшәеш асылына төшенү. Шул рәвешле, Чыңгызның илаһилыгы ассызыклана, чиксез хакимият иясе булуы ачыклана. Гомумән, поэма дәвамында Чыңгыз бары тик кояш белән генә аралаша, әмма, автор фикеренчә, беркемнең дә хакимлеге мәңгелек һәм чиксез түгел: *Дөнья зур, фәкать, Чыңгыз, мин дә анда / Падишаһлык кыла алмыймын бер заманда. / Күрәмсең, алмаш-тилмәш хөкем итәм / Бер анда, җир астында, бер монда*[3]. Кояш җиһанның төрле тарафын чираттан яктырткан кебек, Чыңгыз да бөтен дөнья белән идарә итә алмый. Автор идеясе дә шушы фикерне үстерә: абсолют хакимияткә омтылу кешелек кыйммәтләрен җуюга китерә.

Күренгәнчә, Чыңгыз образын сурәтләүдә ялгызлык категориясе алгы планга чыгарыла: ул башкалардан аерып куела, алай гына да түгел, Чыңгыз үзе ялгызлыкка омтыла. Фәлсәфи фикерләүдә ялгызлык төшенчәсе әһәмиятле категорияләрдән санала, әдәбиятка аның ирек белән бәйле модификациясе үтеп керә: лирик герой рухи тырышлык нәтиҗәсендә

---

[1] *Мокина Н.В.* Русская поэзия Серебряного века: концепция личности и смысла жизни в динамике художественных мотивов и образов: дис. ... д-ра филол. наук. – Саратов, 2003. – С. 364.

[2] *Долгополов Л.М.* Горький и проблема «детей солнца» (1900-е годы) // Долгополов Л. М. На рубеже веков. О русской литературе конца XIX – начала XX века. – Л., 1985. – С. 63–78.

[3] *Думави Н.* Шәрык даһие // Аң. – 1915. – № 8. – Б. 151.

ялгызлыкка ирешә, һәм ул ирекkә, рухи яңарышка ирешү белән тәңгәл куела[1]. «Шәрык даһие» поэмасы да герой ялгызлыгын рухи азатлык, көч белән турыдан-туры бәйләп карый, шул ук вакытта бу фикер әкиятләрдән килгән мотивлар белән дә ныгытыла: Чыңгыз берүзе Горбәт, Ачлык батырлар белән көрәшкә чыга һәм аларны җиңә. Димәк, Н. Думавиның әлеге әсәре, символизм иҗат агымының йогынтысын тойган хәлдә иҗат ителеп, әкияти мотивлар белән баетыла һәм тирән эчтәлекле фәлсәфи әсәргә әверелә.

Гомумән, XX йөз башы татар сүз сәнгатендә зур урын алып торган символизм лиро-эпикада үзенчәлекле чагылыш таба. Турыдан-туры символик характерда булган үрнәкләр сирәк очраса да, аерым образларны, мифларны, риваятьләрне, тарихи образларны символ дәрәҗәсендә сурәтләү поэмаларны милли яшәеш, чор, җәмгыять, халык турындагы уйлануларны җиткерү мәйданына әверелдерә.

## 2.2. XX йөз башы татар поэмаларында сызлану фәлсәфәсе

XX йөз башында татар әдәбиятында, шул исәптән лиро-эпикада да, кискен индивидуализм һәм төшенкелеккә бирелү берлеген хасил иткән экзистенциализм агымы урын ала.

Экзистенциализм фәлсәфәсе катлаулылыгы һәм яңалыгы белән галимнәрне һәрвакыт үзенә тартып тора. Әдәбият белемендә, фәлсәфәдә экзистенциализм агымына карата фикер төрлелеге яшәп килә. Кайбер галимнәр аны башка агымнар белән генә бәйләнгән дип саныйлар, кешенең яшәү мәгънәсен, сайлау мөмкинлеген, ирек чикләрен чагылдыру омтылышы дип беләләр. Башкалар экзистенциализмның атеистик агым булуын раслыйлар һәм хаосны, мәгънәсезлекне, күңел төшенкелеген, чарасызлыкны, Алланың үлүен аның

[1] *Гречаник И.В.* Художественная концепция бытия в русской лирике первой трети XX в.: дис. ... д-ра филол. наук. – М., 2004. – С. 117.

төп эчтәлеге итеп күрсәтәләр[1]. Әмма фәлсәфәнең бу рәвешле шәрехләнүе татар әдәбияты өчен ят. Үз үсешендә һәрдаим бөек затка табынган сүз сәнгате, киресенчә, дөнья ямьсезлеграннән ышыклану эзләп, Илаһка мөрәҗәгать итә.

Экзистенциализмны «кеше фәлсәфәсе» дип карау да яшәп килә. Экзистенциализм бары тик кара төсне генә үзенеке итеп саный. Газаплану тормышның төп хакыйкате кебек кабул ителә. Кешегә бары тик курку, мәшәкатьләнү һәм башка тискәре кичерешләр хас. Шуның аркылы «яшәү – ул үлү» дигән фикер уздырыла. Әлбәттә, кешелекнең газаплanulары һәм үлем фәлсәфәнең төп темасына әверелә, шуңа күрә дә экзистенциализм кешенең тискәре хискичерешләрен өйрәнүгә йөз тота. Үзенең табигате белән һәр кеше – экзистенциалист. Башта кеше бу концепцияне аңлап җиткерә алмый, ул бары тик «экзистенциалист мин»ен тойгач кына моңа ышана башлый[2].

Кешенең яшәеше һәм тормыш мәгънәсе экзистенциализмның төп өйрәнү объекты булып тора. Кайбер фәлсәфәчеләр кешенең эчке дөньясын тикшерүне төп предмет һәм максат итеп куялар, һәм бу кешеләр җәмгыятьтән тыш тикшерелә. Тормышның мәгънәсезлеге, фәкыйрьлек, аннан чыгу мөмкин түгеллеген күрсәтү, чикләнү – экзистенциализмга хас факторлар – чарасызлыкка китерә[3]. Кеше гомере буена бөек рух кыйммәтләре һәм ямьсез материаль тирәлек арасында талпына, сызлана, тормышының фаҗигалелеген аңлый[4]. Экзистенциализм фәлсәфәсен фәнни яктан өйрәнгән төрле хезмәтләрдә аның төп сыйфатлары төсендә түбәндәгеләр аерып

[1] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 28.

[2] Современный экзистенциализм. Крит. очерки. – М., 1966. – С. 12–14.

[3] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 30.

[4] Шунда ук. – Б. 30.

чыгарыла: җәмгыятьтән качу, үзеңнең яшәешеңне канәгатьләндерү чараларын эзләү, тормышның мәгънәсезлеген тоеп яшәү, кеше омтылышларының мәгънәсезлегенә төшенү һ.б.[1]

Кеше яшәешен ике баскычка – эссенция һәм экзистенциягә бүлеп карау әлеге фәлсәфәнең асылын билгели. Беренче баскычта кеше туа, мәхәббәт хисләре кичерә. Экзистенция исә кешенең үз асылын, шәхси тормыш максатын ачыкларга омтыла башлавы, хакыйкатьне, яшәү мәгънәсен эзләве, ләкин таба алмавы белән бәйле. Аның яшәүдә гаме калмый, үлем турында уй бөтен барлыгын били. Яшәү белән үлем арасы бары бер мизгел булуы ачыклана, һәм үлем бердәнбер хакыйкать дип кабул ителә.

Яшәешнең мәгънәсезлеге, максатсызлыгы, кешенең ялгызлык һәм көчсезлек хакындагы фикерләр XX йөз башы татар җәмгыятендә һәм әдәбиятында да чагылыш таба. Чарасызлык, үлем, җәза, ялгыш кебек төшенчәләр милләт, халык язмышы турындагы гамьнәрне бер ноктага җыя һәм әдәбиятта төп мотивларның берсенә әверелә. Сызлану фәлсәфәсе ике гасыр чигендә поэзиягә дә үтеп керә, шул чорда иҗат ителгән бер төркем поэмаларны экзистенцилизм фәлсәфәсе берләштерә. Бу өлкәдә Н. Исәнбәт, С. Сүнчәләй, Ф. Бурнаш, Б. Мирзанов, Ф. Ибраһимов кебек авторларның эзләнүләре игътибарга лаек.

Экзистенциализм фәлсәфәсе, яшәешнең фаҗигалелеген аңлау аның үлем куркынычы астында яшәүне тоюдан башлана, дип раслый. Яшәешне, кеше тормышын мәгънәсез, абсурд дип белдергәндә, күп кенә язучылар моны кеше гомеренең үлем белән тәгәлләнүенә бәйләп карыйлар. XX гасыр башы татар әдәбиятында үлемне куркыныч, фаҗига дип аңлаудан аның кешене яшәү газабыннан азат итү мөмкинлеген тануга кадәр ара узыла, кайбер әсәрләрдә әҗәл

[1] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 5.

яшәүгә нокта куючы булса, кайсыларында аның дәвамы ролен уйный. Кайбер авторлар үлемне тормыш аһ-зарыннан котылу мөмкинлеге итеп карый1. Ф. Бурнашның **«Коркыт»** (1916) поэмасында да үлем категориясе әсәр сюжетын бер төенгә җыючы төшенчә буларак калка, үлемнең котылгысызлыгын раслау поэманың төп идеясен билгели. Поэманың төп герое булган Коркыт – Алтай якларында яшәгән бер кеше. Коркытның эссенция баскычында яшәеше традицион рухта: ул булганына канәгать булып, артык хафаланмыйча тыныч кына гомер кичерә. Әлеге момент Коркытны табигый кеше тәгълиматы белән дә бәйләп куя. Экзистенция баскычына күчеш геройга үлем киләчәге турында хәбәр мәгълүм булу белән тәгаенләнә. Әлеге баскычны җентекле сурәтләүне максат иткән сюжет кабатланган вакыйгаларны үз эченә ала: үлемнән качып, Коркыт көнбатышка, көньякка, төньякка йөгерә, әмма һәр тарафта аны кабер казучылар көтеп тора. Димәк, әлеге поэманың композицион асылын тәшкил иткән кабатлау алымы яшәү һәм үлем белән бәйле фәлсәфәне үткәрүдә төп роль уйный.

Шул рәвешле, һәр яшәешнең табигый чиге үлем булуы турындагы фикер әсәрдә кызыл җеп булып сузыла һәм Коркыт тарафыннан турыдан-туры раслана: *Кайтыйм элек әйткән сүземнән, / Хәзер белдем: котылмак юк үлемнән. / Кирәксә, көнбатышка кач, кирәксә, / Йөгер, кач, көнбатыш якларга яисә / Очалсаң, оч, чумалсаң, чум суларга/ Түгел мөмкин сиңа артык суларга. / Әҗәлдән һичбер кемгә юк котылмак, / Кирәк кайда качалсаң, тик тотылмак*[2]. Димәк, поэмада үлемнең котылгысызлыгы хакыйкать рәвешендә кабул ителә һәм үлемнән качып булмый, дигән фикер үзәк идеягә әверелә.

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 114.

[2] *Бурнаш Ф.* Коркыт // Аң. – 1916. – № 18. – Б. 281.

Экзистенциалистлар кеше яшәешенең мәгънәсен хакыйкатькә омтылып яшәүдә күрәләр, ә хакыйкать дип шәхеснең Аллага яки абсолют идеягә омытылуын, үз-үзен рухи камилләштереп, рухи тынычлыкка ирешүен атыйлар, ләкин кеше бу дөньяда хакыйкатькә ирешергә ашыкмый, рухи камиллектән бигрәк, тән ләззәтен кайгыртып яши бирә. Нәкъ менә тән рәхәте артыннан куып яшәү хакыйкатькә ирешергә комачаулый, гөнаһка батуга, кеше тормышының мәгънәсезлегенә китерә. Бу тормышта кешенең рухи халәте курку, шом, ялгызлык, вөҗдан газабы белән билгеләнә. Экзистенциалистлар, тормыш кешегә каршы куелган, дип исәплиләр, кешене язмыш колы итеп карыйлар, үз тормышының мәгънәсез булуын төшенгәннән соң, кеше җан тынычлыгын югалта, дип саныйлар[1]. Мондый тенденция Н. Исәнбәтнең сызлану фәлсәфәсен үзәккә алган **«Качкын»** (1916) һәм **«Сукбай»** (1916) поэмаларындада күзәтелә. Беренче әсәрдә кеше яшәешенең мәгънәсезлеген раслау алгы планга чыгарыла, һәм ул кешенең үз тормышын үзе мәгънәсез итүе хакындагы фикер белән үрелеп китә. Поэманың хронотобы үткән һәм бүгенгенең катлаулы кушылмасын тәшкил итә. Үткән белән бәйле эссенция һәм хәзергене билгеләгән экзистенция баскычларын герой укучы күз алдында үтә. Шопэнгауэрның «Мир как воля и представление» дигән хезмәтендә түбәндәге фәлсәфи фикер китерелә: тормышның, гомумән, максаты юк, ул – максатсыз, бары тик сукыр импульс кына, шуңа күрә кеше җанына тынычлык таба алмый, ул һәрвакыт нәрсәдәндер канәгать түгел, усал, тынычсыз. Аның өчен тормыш ул – вак мәшәкатьләр кушылмасы, кеше, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, гомере буе чаба, якында гына тоелган

---

[1] Основы литературоведения: Учебное пособие для филологических факультетов пед. ун-тов / Мещеряков В.П., Козлов А.С., Кубарева Н.П., Сербул М.Н.; под общ. ред. В.П. Мещерякова. – М.: Московский Лицей, 2000. – С. 279.

бәхетенә һич ирешә алмый. Кеше тормыш мәшәкатьләреннән сыгыла, үлем куркынычы астында яши. Шопэнгауэр фикеренчә, кайгы-хәсрәтләрдән газаплануларны җиңеләйтүнең бер чарасы – кешенең газапларын уртаклашу (хәленә керү), чит кешенең кайгы-хәсрәтен уртаклашып, үз хәсрәтеңне онытып тору һәм язмыш белән килешү[1]. Качкынның да эссенция дәвере явызлык, усаллык, үз мәнфәгатьләрен кайгырту белән бәйле: *Ул электә каушамый һәм тетрәми торган иде... / Бу таныш урман аңа бер өй кебек булган иде. / Ул электә, яшь, чибәр чагында, җен кебек көчле иде, / Тешләре чыккан, котырган юлбарыс төсле иде... / Бер кызу ут очкыныдай, ул йөгерде җылтырап... / Ул кылыч тоткач та, юлчы бирде ак җан тинтерәп. / Ул шул эшләрдән табып тәм, кайгыны һич белмәде. / Баш кисәргә көн саен тик юл йөрүче эзләде*[2]. Болар инде бар да үткәндә калган. Качкынның тормышы максатсыз узган, яшәеше кешеләргә хәсрәт һәм явызлык кына китергән. Укучы каршына көчсезләнгән, хәлдән тайган, үлем көткән герой килеп баса. Ул – үзенең файдасыз һәм максатсыз гомер кичерүен аңлап, төшенкелеккә бирелгән, яшәү мәгънәсен югалткан бер кеше: *Каушаган, көчсез буынлы тезләре тетри иде... / Ул калайланган, коточкыч, эчкә баткан күзләре. / Ак киезләнгән сакаллы, шыр сөяктән йөзләре...*[3] Качкынның гомере тән ләззәтенә буйсынып үткән, матди кыйммәтләрне өстен күрү аның рухи дөньясын тарайткан, намусын юкка чыгарган. Шуларны аңлау хәленә герой чиктәш мизгелдә килә (чиктәш изгел кешенең гомер чигендә үз яшәешенең мәгънәсен төшенүе белән характерлана[4], бу вакытта кеше гомернең чиклелеген,

---

[1] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 31-32.

[2] *Исәнбәт Н.* Качкын // Аң. – 1916. – № 9. – Б. 152.

[3] Шунда ук. – Б. 152.

[4] *Больнов Отто Ф.* Философия экзистенциализма. – М.: Лань, 1999. – С. 67.

аны тотып калып булмаячагын, бетүнең котылгысызлыгын аңлый[1]), ул мизгел Үлемне күрү белән алшартлана. Кеше кыяфәтендә сурәтләнгән үлем дөньяда күпне күргән, явызлык, кансызлыкка иялəнгән Качкынны да тетрәндереп куя: *Шул чагын күзгә күренгән төсле булды бер кеше. / Ул кеше көлде – коточкыч ыржаеп чыкты теше! / Ул чыгып торган ияк, маңгай-юнылган таш кебек... / Зур күсе койрыклары сызылып утырган кош булып!* [2] Укмашып-тузгып, киезләнеп беткән чәчләр, көянтә кебек кәкре иңбашлар, пычактай үткен тешләр, чокырайган йөзләр, мәңге сүнмәс сукырайган күзләр – шундый эпитетлар һәм чагыштырулар ярдәмендә автор үлем портретын биргән. Әлеге портрет Качкынның рухи дөньясының тарлыгы белән дә аңлатыла: сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә язмышын начарлык, явызлык колы булып үткәргән кешенең үлеме дә ямьсез булуына ишарә ясала. Качкын үзенең үлемнән качып котыла алмаячагын аңлый, язмышына буйсына, әмма бу аңа җиңеллек китерми. Үлем белән күзгә-күз очрашудан туган чиктәш мизгел аның яшәеш кыйммәтләрен яңадан барлавы һәм үзенең беркемгә кирәк булмавы, гомеренең мәгънәсез үтүе турындагы уйга килүе белән бәйле: *Инде ул карт, инде ул көчсез, озак тормас, үләр... / Ул үләр!. . Үлгәч аны салкын кабергә кем күмәр?.. / Ул үләр!.. Тик кипкән иренен кем юешләр, кеме үбәр?.. / Кем ул үлгәч кайгырыр һәм кем ул үлгәч яшь түгәр?* [3]

Экзистенциалистларның кайберләре яшәүнең мәгънәсе турындагы сорауга тормыш мәгънәсез һәм аның сихерле түгәрәгеннән чыгып булмый, дип җавап бирүне алга сөрәләр[4]. Шопенгауэр яшәүнең, гомумән, бернинди дә максаты юк, ул аның бернинди максатка да буйсынмаган аңсыз

---

[1] *Сартр Ж.-П.* Ситуации: Сборник. – М.: Ладомир, 1998. – С. 66.

[2] *Исәнбәт Н.* Качкын // Аң. – 1916. – № 9. – Б. 152.

[3] Шунда ук. – Б. 152.

[4] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 6.

хәрәкәт дигән фикерне җиткерә[1]. Качкынның тормышы әлеге идея кысаларында карала ала. Максатсыз үткән тормыш, гомуми хәрәкәткә буйсыну, язмыш агымына бирешү аның яшәешен мәгънәсез һәм буш иткән.

Шул рәвешле, автор кеше яшәешенең мәгънәсен, асылын эзли. Качкынның соңгы көннәрен сурәтләү аша, ул кешелекнең, тән ләззәтләренә бирелеп, максатсыз яшәвен кире кага. Н. Исәнбәт тарафыннан кешенең үз гамәлләре өчен җавап бирүе турындагы фикерне үстерә һәм иң соңгы җавапның үлем булуы искәртә. Аннан беркем дә качып котыла алмый, дип белдерә.

Әлеге фикер **«Сукбай»** поэмасында да үстерелә һәм тирәнәйтелә. Поэмада төп сюжет сызыгы «ялгыз кеше» концепциясе кысаларында гәүдәләнгән Сукбай белән бәйле. Билгеле булганча, «ялгыз кеше трагедиясе» мәгънәсендә аңланган сызлану фәлсәфәсе рационализмга, акыл көченә шикләнеп караудан башлана, шикләнү чарасызлыкка китерә. Чарасызлыкның сәбәбе, әлеге өйрәтүнең башында торган галимнәр фикеренчә, яшәешнең камил булмавыннан, кешенең үзен чиксезлек, галәм каршында артык кечкенә, Аллаһының бөеклеге янында бик түбән сизүеннән килеп чыга[2]. Сукбайның ялгызлыгы яшәешен яңадан бер кат күздән кичерү белән бәйле экзистенция баскычында ачыклана, тирәнәйтелә. Ретроспекция алымы ярдәмендә торгызылган үткән Бөркет Әхмәтнең (сукбайның исеме шулай булган) эссенция баскычында кичергән хәл-әхвәлләрен бәян итә: ул бәхеткә омтылган, язмыштан мәрхәмәт көткән. Поэманың бу үзенчәлеген Н. Ханзафаров та билгеләп үтә. Аның фикеренчә, Н. Исәнбәтнең революциягә кадәр иҗат ителгән беренче поэмаларында саф мәхәббәт, табигый матурлык,

[1] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 31.

[2] *Заһидуллина Д. Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 80.

җан җылысы эзләү темалары романтик, экспрессив дулкыннарда ачыла, «Бозылган вәгъдә», «Качкын» һәм Сукбай» поэмаларын шушы сыйфат берләштерә[1].

Экзистенциаль фәлсәфә белән турыдан-туры бәйле өмет категориясе бу поэмада да үзәк урынны били: Сукбайның бар гомере бәхет өмет итеп узган. Ницше үзенең хезмәтендә болай дип яза: «Без белергә бурычлы: һәрбер барлыкка килүче әйбер газапланырга һәм юкка чыгарга әзер торырга тиеш»[2]. Кешенең тормышка ышанычын бары тик иллюзия генә коткара ала. Иллюзия юкка чыгарыла икән, кеше үз яшәешенең мәгънәсезлегенә төшенә дигән сүз. Кеше үзенең кем булуын белми һәм аны танып белү омытылышы белән яна. Җимерелгән дөньяда яшәп, ул яхшырак дөньяга юл ачмакчы була[3]. Сукбайны яшәү ямьсезлегеннән коткарырга мөмкин булган иллюзия исә читтә бәхет табу өмете белән тәңгәл килә.

Хакыйкатькә ирешү буларак төгәлләшкән елау мизгелендә картның яшәү мәгънәсенә төшенүе ачык, ә яшәү мәгънәсе аның өчен балачак идиллиясе, туган як, рухи гармония белән бәйле: *Кайда ул картның гөл кебек яшь чаклары? / Нишләгән ул нурлы йөзләр, нишләгән ай кашлары? / Ул балачаклар, көләчлекләр, көлүләр көчләнеп? / Ул кадер кичке елаулар, яшь-ару җан нечкәреп! / Көндезен, кармак салып күлдән балыклар аулавы, / Су керүләр, анда дулкыннар көлү һәм шаулавы*[4]. Кешенең иң олы бәхете сабый чагындагы кичерешләр белән бәйле, киләчәге исә туган җирендә генә якты. Сукбай боларны аңлау ноктасына килә, әмма инде соң:

---

[1] *Ханзафаров Н.* Ил белән бергә // Исәнбәт Н. Әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 1 т: Шигырьләр, поэмалар, драматик поэмалар. – Б. 6.

[2] *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – С. 31–32.

[3] Шунда ук. – Б. 38–39.

[4] *Исәнбәт Н.* Сукбай // Аң. – 1916. – № 19–20. – Б. 294–295.

*Аһ, алар үткән, үтеп киткән... Китеп иңгән кояш! / Ул кояш иңгән ягыннан әйләнеп чыкмас, тумас!*[1]

Әсәрдә яшәешнең ике чиген – яшәү һәм үлемне тоташтыручы юл образы үткән һәм бүгенгене бәйләү ноктасы да булып тора һәм геройның яшәү мәгънәсенә төшенү урынына әверелә. Хакыйкать мәгънәсендә килгән шымлы тынлык та Сукбай төшенгән ачы дөреслекне җиткерүгә ярдәм итә. Бу хакыйкать гомернең заяга үтүе, өмет-хыялларның бушлыгы һәм бәхетнең булмаячагына төшенү белән бәйле, кайчандыр Сукбайның балачагы үткән буш йорттагы шомлы тынлык бу идеяне көчәйтә, аның туган авылына урау юллар үтеп кайтуы анасыннан, тезләнеп, кичерүен үтенү теләге белән мотивлашкан, һәм әлеге ноктада юл хронотобы мәдәнияттәге мәңгелек кайту мифологемасы белән кисешә.

Поэманың сәнгатьчә эшләнеше дә кызыклы. Сукбайның күңел каршылыгын тасвирлауда тормышның авырлыгы, ямьсезлеге тәэсирендә туган өметсезлек, билгесезлек, төшенкелек хисләре өстенлек итә һәм аларны җиткерүдә автор тынлык, караңгы, кабер, моңлык, куркыныч кебек ачкыч сүзләр һәм убырлы карчык, Хозыр-Ильяс, өрәк, албасты кебек мифик образларга мөрәҗәгать итә. Риторик сораулар һәм эндәшләр аша автор сукбай яшәешенең мәгънәсезлеген тагын да тирәнәйтә: *Нинди карт бу? Монда нишли? Әллә бер-бер җенме бу? / Йә кешеләрдән ераклашкан берәр сөргенме бу? / Ул җүләрме, ник йөри соң ямьсез айлы төнне ул? / Әллә урманнан килеп чыккан берәр качкынмы ул?*[2]

Шул рәвешле, сызлану фәлсәфәсе йогынтысында иҗат ителгән әсәрдә яшәү мәгънәсе нәсел җепләрен саклау, ил, халык, милләт язмышы белән бәйле булуда табыла, ягъни яшәү һәм үлем каршылыгы үзенчәлекле чишелә: туган илеңдә, халык өметен аклап гомер кичерү – яшәүнең асылы

---

[1] *Исәнбәт Н.* Сукбай // Аң. – 1916. – № 19–20. – Б. 295.

[2] Шунда ук. – Б. 295.

дип билгеләнсә, читтә каңгырып йөрү, өмет бетү – үлем белән тиңләштерелә.

Г. Шәрифинең **«Теләнче»** (1917) поэмасында да төп герой – экзистенция баскычын үтүче кеше. Аның бүгенге яшәеше бик ямьсез һәм газаплы, риторик сораулар белән автор теләнченең үткәне һәм бүгенгесе турында уйлана: *Кая данлыклы вакыты?.. Аһ, бәхетсез җан!.. Аның башына / Килеп кунган... бәхет, дәүләт кошы кайда очкан!.. / Теләнчелеккә көн калган... / Әнә ул капчыгын аскан... / Әнә бер кулына ул хөрмә талыннан бер таяк тоткан!..*[1]

Кайчандыр меңнәрчә кешенең язмышын хәл иткән, бөеклек, байлык, муллык, хакимлеккә ия булган шәхес бүген эссе чүлдә «соранып, ялварып, ялынып» йөри. Н. Исәнбәттән аермалы буларак, Г. Шәрифи теләнченең мондый хәлгә төшүендә аның үзен гаепләми, әсәрдә язмыш тормыш агышын билгеләүче категория буларак күрсәтә. Кеше яшәеше исә язмыш кануннарына буйсындырылган. Поэманың беренче юлларында ук инде кеше яшәеше бәхет – бәхетсезлек, өмет – чарасызлык, байлык – хәерчелек чикләрендә карала һәм һәркемнең эш-гамәлләре тәкъдир белән мотивлаштырыла: Б*у тәкъдир, һай, бу язмыш... Бәдбәхет... Ул изми кемнәрне?. . / Аермый канлы яшьләр түктереп кемнәрне бәхетеннән? / Кичә гамьсез, сарайларда тыныч яткан әмирләрне / Бүген тартып ала, айра... Мөлек, таҗ һәм дә тәхтеннән*[2]. Димәк, әсәрдә фатализм белән бәйле экзистенциаль фәлсәфә ислам идеологиясеннән үк килгән тәкъдир, һәр гамәлнең алдан язылганлыгы хакындагы тәгълиматка барып тоташа. Автор идеясе кешенең язмыш алдында көчсезлеген раслаган экзистенциаль мотив тирәсендә оеша һәм һәркемнең аның каршында тигезлеге турындагы уй белән тулылана.

---

[1] *Шәрифи Г.* Теләнче // Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 395.

[2] Шунда ук. – Б. 394.

Әсәр ахырында язмыш хакындагы юллар яңадан кабатлана, шул рәвешле, поэманың каймалы композиция алымы белән баетылган булуы фәлсәфәне тагын да тирәнәйтә.

С. Сүнчәләйнең **«Сүнгән җан»** (1913 елда басылган) поэмасында да үлем категориясе үзәккә куела. Поэма авыру ананың үлеме һәм аның кызының михнәт чигеп яшәве турында. Әсәрнең башлам өлешендә үк фаҗигане искәрткән тынлык образы килеп керә: *Тышта күптән кайгылы ахшам яна, / Өй эче тып-тын, караңгы, куркыныч*[1]. Шушы караңгы, куркыныч өйдә ана үлем көтеп ята, әмма, аның сүзләреннән аңлашылганча, үлем яшәү авырлыгыннан котылу чарасы булып тәгаллләшә: *Мин хәзер инде үләр хәлгә җитәм. / Мин бәхетледер...*[2] Ананың үләр алдыннан күргән саташулы төше кызының киләчәгенә ишарә итүче метафора булып аңлашыла, бу төш – яшь кыз баланың вәхшиләрчә үтерелүе турында. Үлемне гөнаһлы яшәештән арыну дип аңлаткан поэмада экзистенция баскычын нәфескә бирелгән кыз үтәргә тиешлеге аңлашыла. С. Сүнчәләй бу поэмасында кеше язмышын еш кына башкаларның хәл итүен искәртә: *Вәхши ерткычлар – адәмнәр яшь кенә – / Кызны азгынлык юлына керттеләр. / Алланың сөйгән-яраткан кечкенә / Мәхлукын терелəй тәмугка төрттеләр. <...> / Ул хәзер инде үлек; юк ак көне*[3].

Шулай итеп, кызның анасы вафатыннан соңгы яшәеше үлемгә тиңләштерелә. Кешеләрнең ерткыч вәхшиләргә охшатылуы исә авторның чынбарлыкка, җәмгыятькә, гомумән, яшәешкә мөнәсәбәте булып аңлашыла. Автор фикеренчә, бу яшәештә кеше кадере юк, кемнеңдер бәхетсезлеге башкаларны борчымый, битарафлык – җәмгыятьнең даими

---

[1] *Сүнчәләй С.* Сүнгән җан // Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре. – Казан, 1913. – Б. 78.

[2] Шунда ук. – Б. 80.

[3] Шунда ук. – Б. 85.

халәте. Бу фикер кабатлау композицион принцибы белән дә ныгытыла: ананың үлеменә битараф калган кешелек *(Төн дә үтте. Иртәсен гүргә аны / Илттеләр һәм күмделәр буш зат кебек. / Кайгысыз, соңгы сулышта дөньяны / Куйды, гүя дөньяга ул ят кебек*[1]*)* аянычлы язмышлы кызны да кызганмый *(Бетте... Юк. Кем дә аны кызганмый да, / Кызганып берни итеп тә булмыйдыр. / Күрсә дә һичкем аны сызланмый да, / Сызлану берлән газап онтылмыйдыр*[2]*)*. Димәк, әсәрдә экзистенциаль фәлсәфә кешенең кадере булмау, җиһанга ят булуы хакындагы уйланулар рәвешендә тәкъдим ителә, бу фикернең ана һәм кыз язмышы мисалында сурәтләнүе мондый хәлнең мәңгелек булуына ишарә ясый. Кызның тормышка аяк басуыннан алып үлеменә кадәр араны иңләгән хронотоп аның шушы хакыйкатьне бик соңлап аңлавын искәртә.

Шул рәвешле, С. Сүнчәләй яшәү – үлем фәлсәфәсен үзенчәлекле чишә һәм яшәү – ул үлем, дигән идеягә алып килә. Кешеләр тарафыннан бозылган, әхлаксызлыкка этәрелгән кызның үлеме исә кешеләрнең бер-берсенә карата миһербансыз, шәфкатьсез булулары турындагы фикерне үткәрергә мөмкинлек бирә.

Шундый ук фикерләр Бәхтияр Мирзановның **«Сулган чәчәк»** (1917) поэмасында да сурәтләнә. Төп сюжет сызыгы чәчәк белән бәйләнгән. Аның тормышы ике өлешкә бүлеп сурәтләнә: матурлык тулы яз эссенция баскычын билгеләсә, үлемгә китергән экзистенцияне көз хронотобы ачыклый. Яшәешенең эссенция баскычында чәчәк үсә, матурлык тарата, кешеләрнең хөрмәтен казана: *Яшь күңелләр аңарга тез чүгәр өчен, / Матур кызлар бер яфрагын өзәр өчен. / Чуар-чуар күбәләк, бал кортлары да / Зар иде ул чәчәкне бер*

---

[1] *Сүнчәләй С.* Сүнгән җан // Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре. – Казан, 1913. – Б. 83.

[2] Шунда ук. – Б. 84.

*үбәр өчен*[1]. Чәчәкнең үлеме исә язлар үтү, күзләр җитү белән бәйле. Шул рәвешле, символик яссылыкта яз – яшәү, көз үлем булып тәгәлләшә. Гөлнең, ахыр чиктә, чыгарып ташлануы кешеләрнең матурлыкны үз куллары белән юк итүләре хакындагы уйлануларга этәрә. Өзелгән чәчәкнең елавы хакыйкатькә төшенү белән тәңгәл, ә хакыйкать яшәешнең мәгънәсезлеге, кешеләрнең каты бәгырьле булуы белән бәйле. Чәчәкнең символик яссылыкта татар кызларына ишарә итүе ачык: *Кызлар да бит риза була җәбран, каһран, / Никах белән башын бәйләп итсәк туен*[2]. Шул рәвешле, автор чор яшәешенә бәя бирә, экзистенциаль җирлекле поэманы милли мәсьәләләр күтәрү мәйданына әверелдерә. Риторик сораулар һәм эндәшләр аша гөл яшәешенең мәгънәсезлеге, кеше гомеренең чикләнгәнлеге, үлем алдында көчсезлеге кебек экзистенциаль фикерләр җиткерелә.

Шул ук авторның **«Әнкәм кабере янында»** (1916) поэмасында да, лирик геройның, әнисе рухына юнәлдерелгән монологы аша, үзенең язмыш алдында үзенең көчсезлеген тануы җиткерелә. Тормышының бетүгә баруын аңлаган лирик геройның бердәнбер юанычы – әнкәсе каберенә баш ию.

Әсәрдә экзистенциаль нигез ике яссылыкта табыла. Бердән, ананың туфракка әйләнгүе хакындагы сүзләр үлемнең һәр кешегә киләчәгенә, яшәешнең бетүгә юнәлгәнлеге табигый факт икәнлегенә ишарәли. Икенчедән, лирик геройның үз тормышын, йөрәген кабер белән чагыштыруы яшәешнең мәгънәсезлеге, ямьсезлеге хакындагы уйлануларга этәрә: *Туңды күңел, йөрәк тын, кабердәй, / Чөнки язмыш салды карларын*[3].

Әлеге поэмада да экзистенциаль фәлсәфә ялгыз кеше трагедиясе рәвешен ала. Лирик геройның төп юлдашы –

---

[1] *Мирзанов Б.* Сулган чәчәк // Сөембикә. – 1917. – № 7. – Б. 97.
[2] Шунда ук. – Б. 98.
[3] *Мирзанов Б.* Әнкәм кабере янында // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 206.

ялгызлык: *Азмы яттым ялгыз, азмы булды... / Күздән аккан канлы яшьләрем?!*[1] Ялгызлыкны шагыйрь халыкка хезмәт итү мотивы белән дә бәйләп куя һәм, шул рәвешле, әсәргә иҗтимагый яңгыраш та өстәлә: *Ил күгендә ялгыз йолдыз кебек / Яныйм дисәм, бераз ялтырап. / Яныр булмый ачы җил каһәреннән / Сүнәр төсле торам калтырап*[2]. Әдәбиятта фаталистик тенденция белән бәйле җил образы[3] геройның язмыш каршында көчсезлеген раслауга хезмәт итә. Поэма дәвамында кешене өмет яшәтү турындагы фикер үстерелә килә һәм үлем – өмет бетү дигән идея булып формалаша: *Булмас, ахры! Язмыш күрде үксез, / Бетте өмет алда – мин үләм... / Мин үләм, бу кара йөзле дөньядан / Югалам мәңге, мин сүнәм!!!*[4]

Сызлану фәлсәфәсе тәгълиматын сәнгати үстерү җәһәтеннән Фәрит Ибраһимов иҗаты да аерылып тора. Аның берничә поэмасы яшәешнең абсурдлыгы, мәгънәсезлеге, тормышның рухи ярлылыгы турындагы фикерләрне берләштергән, кешенең курку, шом, ялгызлык белән бәйле халәтен чагылдырган экзистенциаль әсәрләр булып каралырга хаклы. Әдипнең **«Төш»** (1915) поэмасы гомер агышын тасвирлаган лирик башлам белән ачыла. Пейзаж караңгы төн үтеп, ай батуны һәм ал таң атуын сурәтли. Таң ату белән, табигатьтә гадәти яшәеш башлана: *Кузгалдылар кошлар, сандугачлар, / Сайрый инде әнә бер тургай! / Әнә исә әкрен иртәнге җил, / Җилпердәтеп агач яфрагын, / Тезелгәннәр әнә күгәрченнәр, / Каплаганнар мәчет михрабын*[5]. Шушы иртәнге тынлыкта азан тавышы яңгырый: *Таң һавасын ярып өзелеп-өзелеп / Яңгырый әкрен генә моң азан, / Нечкәртәләр*

---

[1] *Мирзанов Б.* Әнкәм кабере янында // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 206.

[2] Шунда ук. – Б. 206.

[3] *Быстров В. Н.* Идея преображения мира у русских символистов (Д. Мережковский, А. Белый, А. Блок): дис. ... д-ра филол. наук. – СПб., 2004. – С. 340.

[4] *Мирзанов Б.* Әнкәм кабере янында // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 207.

[5] *Ибраһимов Ф.* Төш // Аң. – 1915. – № 17. – Б. 291.

*моңнар күңелләрне, / Үткәрә башны дөньядан...*[1] Бу юллар, тагын кабатланып, башлам өлешен тәмамлап куя. Димәк, азан тавышының, гади сурәтләү чарасы гына булмыйча, метафорик сурәт дәрәҗәсенә күтәрелүе ачыклана. Символик укылышта моңлы азан тавышы үткән заманнар турындагы хәтер булып аңлашыла: *Төрле төстә матур моңлы тавыш / Үткән заманнарны уйлата*[2]. Бу исә укучыны поэманың төп эчтәлеген аңлауга әзерли, идеяне җиткерү чарасына әверелә. Шулай итеп, пейзаж элементы яшәештәге гармонияне тасвирлау өчен кертелә. Көннең төн белән аерылу моменты – таң вакыты – гомер агышы турындагы уйлануларга китерә.

Ф. Ибраһимов үзенең бу поэмасында модернистик әдәбиятка хас төш мотивын әсәрне кабул итү-аңлауга ачкыч итеп китерә. Тормыш – төш концепциясе, сәнгатьчә үстерелеп, кеше гомеренең яшәү белән үлем арасында бер мизгел генә булуын раслаучы хакыйкатькә әверелә. Хәзрәт күргән төш нәкъ менә гомер, яшәеш, көнитеш, җирдәге яшәү хакында: карт үзенең бакчасындагы чишмә янында утыруын күрә. Кинәт чишмәдән юл ачылып, аннан бер нурлы йөзле сабый чыга һәм, бик тиз картка әйләнеп, вафат та була. Бу – шартлы сурәт, әлеге төш һәр кешенең гомер юлын символлаштырып килә. Шул рәвешле, кеше гомеренең мизгел генә булуы турындагы тәгълимат яшешнең табигый чиге үлем икәнлеген раслау белән кушыла. Модернистик әдәбиятта төп мотивларның берсе булган юл мотивы биредә гомер юлы, яшәү – үлем арасы кебек төгәлләшә. Әлеге төш хәзрәт өчен чиктәш моментка әверелә һәм аның яшәешен экзистенция баскычына китереп җиткерә: ул үзенең гомерен күздән кичерә, балачагын, яшьлеген хәтеренә төшерә. Автор хәзрәтнең эссенция дәверен гамьсез идиллик тормыш рәвешендә тәкъдим итә: ул – яшьлек белән бәйле. Димәк, әсәрдә

[1] *Ибраһимов Ф.* Төш // Аң. – 1915. – № 17. – Б. 291.
[2] Шунда ук. – Б. 291.

картлык килү – үлем якынаю, тормыш мәгънәсе югалу белән характерлана һәм, үлемнең табигыйлеген таныган хәлдә, аны кабатланып килгән нурлы эпитеты белән тасвирланган яшәеш мәгънәле итә, дигән фикер үткәрелә. Хәзрәтнең үлемне табигый, кабул итүе дини фәлсәфә кысаларында карала: ул гомере төгәлләнгәнгә кайгырмый, ә Аллаһ каршына барачагын уйлый, гыйбадәтенең кабул булуын сорый. Поэма ахырында, каймалы композиция алгы планга чыгып, гомер агышы, табигатьтә, яшәештә бар нәрсәнең бер-берсен алыштырып килүе һәм киткәннәрнең онытылуы турындагы идея яңадан кабаталана: *Көннәр үтә, айлар, еллар үтә / Арта һаман үткән көн саны, / Адәм углы һаман көнен күрә, / Кимемидер һич беркем саны. / Мулла бабай гына дөньяда юк, / Җир астында күптән күмелгән. / Көннәр үткән, айлар, еллар үткән, / Чыккан инде хәзрәт күңелдән*[1]. Шул рәвешле, кеше гомеренең чикләнгәнлеге, бар нәрсәнең бетүгә юнәлгән булуы, җиһанда вакыт агышының мәңгелеге кебек экзистенциаль мотивлар әсәрнең үзәгенә куела.

Ф. Ибраһимовның **«Гармун тавышы»** (1915) поэмасында, көчле позиция алып, әсәр исеменә чыгарылган гармун тавышына бәйле дүрт геройның хис-кичерешләре сурәтләнә, һәм әлеге геройларның язмышында экзистенциаль тенденция табыла.

Беренче тарих – Әхмәд бабай турында. Әлеге картның эссенция баскычында кичергәннәре кыенлык, авырлык, мохтаҗлыктан гына гыйбарәт, әмма карт күңелендә яшьлеген сагыну һаман яши, димәк, нинди генә булса да, үткәннең матурлыгы бәхәссез, кеше өчен яшьлеге кире кайтмас якты хатирә булып кала, дигән фикер ассызыклана. Картның хәзергесе өметсез, ул караңгылык, кабер белән тәңгәлләштерелә, аның күңелендә киләчәккә ышаныч сүнгән. Сызлану фәлсәфәсенә хас булганча, герой, тормыш авырлыкларыннан

[1] *Ибраһимов Ф.* Төш // Аң. – 1915. – № 17. – Б. 293.

юану сорап, Аллага сыена, үлгән соң булса да рәхәт яшәргә өметләнә: *«Монда рәхәт күрмәдем, и Алла!» – ди, – / «Рәхмәтең күп, анда утка салма!» – ди*[1].

Мәфтуха исемле тол хатынның да даими халәте өметсезлек. Экзистенция моментында ул рәхәт гомеренең мизгел төсле генә үтеп китү аңлау хәленә җитә: *Сизмәгән дә, барсы артта калганын*[2]. Кайгы-хәсрәт белән характерланучы бүгенгесе исә, киләчәккә тоташып, мәңге бетмәс кебек тоела: *Ак, матур уйлар яшен күк тиз бетә, / Ямьсез уйлар чиксез өелә, изрәтә*[3]. Шул рәвешле, матурлык, рәхәтлекнең бик тиз юкка чыга торган күренеш булып, кеше тормышында кайгыга, караңгылыкка күбрәк урын бирелү хакындагы фикер алга чыга.

Өченче тарих карт кешегә көчләп кияүгә бирелгән кыз турында. Әлеге өлештә автор «хәсрәт» сүзен еш куллана: *Гармун уйнады һаман хәсрәтле көй, / Яшь егетләр җырлый хәсрәт җырлары, / Уйната да җырлата хәсрәтләре, / Чөнки яшь чакларның актык еллары...*[4] Эссенция баскычында кайгы-хәсрәтсез гомер кичергән кыз гомеренең экзистенция мизгеленә максатсыз, киләчәксез, бәхетсез булып керә.

Шул рәвешле, бу өч геройның бердәнбер юанычы – үткәндә калган матурлык хакында уйлану. Димәк, кеше яшәешенең өметсезлеккә, ямьсезлеккә юнәлгәнлеге турындагы экзистенциаль мотив ачык чагылыш таба.

Дүртенче герой кичерешләрендә әлеге фикер милли яссылыкка күчерелеп, гомумкешелек дәрәҗәсендә кабул ителә. Яшь егетнең уйлары халыкның үткәне, данлы тарихның, бөек дәүләтләрнең юкка чыгуы, кешелекне инкыйраз көтү турында: *Дөнья тетрәткән бөек дәүләт сүнә, / Эш һаман*

---

[1] *Ибраһимов Ф.* Гармун тавышы // Аң. – 1915. – № 20. – Б. 322.
[2] Шунда ук. – Б. 323.
[3] Шунда ук. – Б. 323.
[4] Шунда ук. – Б. 323.

*артка бара, төпкә бата, / Зур арсланнар бетәләр, күмәләр*[1]. Бу укылышта экзистенциаль фәлсәфә, кеше язмышының бетүгә юнәлгәнлеге кысаларыннан чыгып, гомумкешелеккә киләчәк үлем турында уйланулар булып тәгалләшә.

Шул рәвешле, поэмада үзәк төшенчә булып торган гармун тавышы образы, аллегорик дәрәҗәдә кабул ителеп, дүрт шәхеснең экзистенция ноктасы булып тәгалләшә. Геройларның эссенция баскычында кичергәннәре җентекле сурәтләнеп, яшәешнең бары тик бер мизгел генә булуы хакында уйланулар туа. Аларның һәрберсенең елавы хакыйкатькә ирешү мәгънәсендә, ә хакыйкать бер генә: кешелек инкыйраздан курка, ул данлы дәүләтләрне дә юкка чыгарырга сәләтле. Һәр бүлек ахырында *«Баш ия һәм күзләреннән яшь коя»* юлларының кабатлануы экзистенциаль хәсрәтнең дәрәҗәсен көчәйтә.

Гомумән, сызлану фәлсәфәсен үзәккә куйган поэмаларда яшәү һәм үлем, өмет һәм өметсезлек, чарасызлык, яктылык һәм караңгылык кебек төшенчәләр каршылыгында кеше гомеренең чикләнгәнлеге, яшәешнең бетүгә юнәлгәнлеге, гомернең яшәү белән үлем арасында бер мизгел генә булуы хакында бәян ителә. Экзистенциаль әдәбиятка бу үзенчәлекләр, әлеге чорда иҗат ителгән әсәрләрдә милли яссылыкка күчерелеп, иҗтимагый яңгыраш ала һәм кешелек яшәешенең яшәү – үлем чикләрендә тирбәлүен аңларга ярдәм итә.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә, яңа формалар, яңа ысуллар эзләүгә бәйле рәвештә, модернистик агымнарга йөз тотып иҗат ителгән поэмалар аерым урын алып торалар. Татар сүз сәнгате өчен аеруча якын булган символизм һәм экзистенциализм лиро-эпикага да көчле йогынты ясый. XX гасыр башында әдәбиятта милли-мәдәни традицияләргә игътибарның артуы мифологик образлар, сюжет-мотивлар, мифопоэтик

[1] *Ибраһимов Ф.* Гармун тавышы // Аң. – 1915. – № 20. – Б. 324.

шәхесләр, архетипик образлар белән кызыксынуның көчәюен китерә. Шуның нәтиҗәсе буларак, милли поэзиядә мифологик образларны символ буларак гәүдәләндергән бер төркем лирик һәм лиро-эпик әсәрләр мәйданга килә. М. Гафури, Ш. Бабич, Г. Харис, Г. Сөнгати, Б. Мирзанов кебек әдипләрнең поэмаларында борынгы төрки ышанулар һәм ислам мифологиясе белән бәйле мифологик образлар сәнгатьчә эшкәртелә, гомумбилгеле мифлар тергезелә, үзгәртеп корыла. Миф хронотобы белән чынбарлык арасындагы чикләрнең җуелуы әлеге поэмаларга чор яшәешенә бәя бирү мөмкинлеге бирә. Рус әдәбияты аша татар сүз сәнгатенә дә Ницшеның «гадәттән тыш шәхес» турындагы тәгълиматы үтеп керә. Һәм ул лиро-эпиканы милләтне үз артыннан ияртерлек идеал – нәби образы белән баета. Чыңгыз әдәбиятта шундый образларның берсе буларак пәйда була.

XX йөз башында җәмгыятьтә хөкем сөргән рухи төшенкелек, алдагы көнгә ышаныч югалу, кан коюлы вакыйгалар милли сүз сәнгатендә сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсе билгеләре чыгылык табра сәбәп була. Ф. Ибраһимов, Б. Мирзанов, Н. Исәнбәт, С. Сүнчәләй кебек авторларның яшәү – үлем мәсьәләсен төп проблема кән поэмаларында кеше яшәешенең бер мизгел генә булуы, һәр нәрсәнең бетүгә юнәлгәнлеге хакында фәлсәфи уйланулар чагыла. Әсәрләрнең күпчелеге, аерым шәхесне сурәтләү кысаларыннан гына чыгып, экзистенциаль фикерләрне милләт белән бәйләп куя.

# ЙОМГАК

XX йөз башында татар сүз сәнгате тизләтелгән үсеш юлына чыга. Инкыйлаблар, сугыш, иҗтимагый-мәдәни тормыштагы алгарыш, халыкның милли үзаңы үсү һ. б. үзгәрешләр әдәбиятка да яңа сулыш өрә: гасырлар дәвамында татар милли сүз сәнгатенең асылын билгеләгән шәркый традицияләр белән рус һәм европа әдәбияты аша кергән үзенчәлекләрнең катлаулы синтезы барлыкка килә.

Бу чор татар әдәбияты поэма жанрының активлашуы белән дә характерлана. XX йөз башына кадәр татар поэмасы, нигездә, романтизм кысаларында үсә-үзгәрә, ә бу чорда әлеге жанр өч юнәлештә үсеп китә: мәгърифәтчелек реализмы кысаларыннан чыгып, тәнкыйди реализмга йөз белән борылган үрнәкләр барлыкка килә, традицион Шәрык һәм Гареб романтизмының катлаулы кушылмасы күзәтелә һәм, ниһаять, милли сүз сәнгате өчен яңа булган, әмма чор иҗтимагый-сәяси вазгыятен бик төгәл чагылдырырга мөмкинлек биргән модернистик поэмалар туа.

Татар әдәбияты XX гасырга мәгърифәтчелек әдәбияты буларак килеп керә, бу чорда да әлеге агым күтәргән күп кенә идеяләр татар җәмгыяте өчен бик тә актуаль булып кала. Шул ук вакытта бу идеяләр чынбарлыкка тәнкыйди караш белән дә баетыла. Әлеге фактор XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә күчеш рухында иҗат ителгән поэмалар тууын нигезли. Я. Мамишев, Х. Усадова, К. Хаммадов кебек әдипләрнең мәгърифәтчелек реализмына хас искелек / яңалык, наданлык / белемлелек оппозицияләрен үзәккә куйган лиро-эпик әсәрләре җәмгыятькә тәнкыйди караш белән

баетыла, милләтнең киләчәген билгеләүче төп фактор буларак мәгърифәтле, укымышлы яшәешне таный. Мондый рухта иҗат ителгән поэмаларның иҗтимагый яңгырашы арта, эш-гамәлләре иҗтимагый мотивлашкан образ тудыру алгы планга чыга. Әлбәттә, сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән бу поэмалар камиллектән ерак торалар, штамп рәвешендә кабатланган вакыйгалар, образлар системасы, идеянең әсәр тукымасында дидактик характерда турыдан-туры җиткерелүе аларны бер-берсенә бик охшаш итә. Шулар янәшәсендә З. Бәширинең идеяне шартлылыкка нигезләп җиткерергә омтылган «Поезд» поэмасы аерылып тора. Көчле позиция алып, әсәр исеменә чыгарылган поезд образы җәдиди җәмгыять символы булып тәгәлләшә һәм яңарыш белән бәйле идеяне җиткерү чарасына әверелә.

Җәмгыятьтәге билгеле бер күренешләрне кире кагу тенденциясенә нигезләнеп иҗат ителгән тәнкыйди поэмаларда кире кагу еш кына фаш итү, көлү формасын ала. Шушы үзенчәлеккә бәйле төстә бер төркем әдипләр сатирага йөз белән борылалар. Г. Гайнуллин-Чокалы, Давыл, Хәбиб Исхакый һәм, әлбәттә, Г. Тукай һәм Ш. Бабич кебек әдипләрнең сатирик иҗатында милләт язмышы, аның бүгенге артталыгы, битараф караңгылыгы һәм киләчәге өчен борчылу хисе җиткерелә. Алар, мәгърифәтчелек идеяләрен дәвам итеп, җәмгыятьнең аянычлы хәленә итеп наданлык, укымаганлык, мулла-ишан, байлар тарафыннан изелеп яшәү сәбәп булды дип санийлар. Шул ук вакытта сатирик поэмаларның иҗтимагый яңгырашы көчәя, җәмгыятькә тәнкыйди караш алгы планга чыга.

Романтик рухта иҗат ителгән поэмаларда да сыйфат үзгәрешләре ачык тәгаенләнә. Аларның, гасырлар дәвамында сакланып килгән шәркый традицияләрне саклаган хәлдә, Европа тибындагы романтизмга йөз белән борылуын күрербез. Ф. Бурнаш, Г. Рәхим, К. Юлдаш, Б. Мирзанов кебек авторларның шушы үзенчәлекне ачык чагылдырган

әсәрләре яшәешне үткән һәм бүген кысаларында сурәтлиләр. Үткәнгә мөнәсәбәтле матурлык, батырлык, тынычлык турындагы сагышлы уйланулар ямьсез, өметсез, караңгы яшәеш белән характерланган бүгенгегә тоташа.

XX йөз башы татар тезмә сүз сәнгатендә романтизм иҗат юнәлеше саф формада бик сирәк очрый. Нигездә, әдипләр романтик поэмаларын модернистик тенденцияләр белән баеталар. Яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең үзенчәлекле ачылуы, экзистенциаль мотивлар, язмыш категориясенең киң планда чагылуы, модернизмга хас булган аерым образ-символларның әсәр кысаларына кертелүе, архетипик образларга мөрәҗәгать итү поэмаларны сәнгати яктан баета.

Чор поэмаларында иҗтимагый аһәңнең беренче урынга чыгуы романтик иҗат үрнәкләрен дә характерлый. Шуңа мөнәсәбәтле, XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләргә карата идеяләр романтизмы дигән төшенчә кулланыла. Бу очракта романтизм иҗат методының реалистик үзенчәлекләр белән баетылганлыгы күздә тотыла. Әлеге агымга хас дөньяны үзгәртү, чынбарлыктан качу идеясе шагыйрьләргә чор вакыйгаларына, иҗтимагый-сәяси вазгыятькә үз бәяләр бирергә мөмкинлек тудыра. Шушы елларда милләтнең азатлык, ирек символы дәрәҗәсендә кабул ителгән тарихи шәхесләрне үзәккә алган поэмалар бер-бер артлы мәйданга килеп, милли тарих темасы алгы нәүбәткә чыга. Романтик әдипләрдән тарихи темага төрле яссылыкта Ф. Бурнаш, К. Юлдаш, Г. Шәрифи кебек авторлар мөрәҗәгать итә.

Гомумән, романтик поэмаларның барысы да диярлек милли эчтәлек белән баетыла. Алар, романтик геройның шәхси дөньясын гына түгел, гомумиләшеп, милләт язмышын сурәтләүне максат итеп куялар.

Татар сүз сәнгатенә килеп кергән модернистик тенденцияләр лиро-эпиканы да иңләп ала, символизм һәм экзистенциализм агымнары поэмаларга да үтеп керә.

Символик әсәрләрнең тулы бер катламы мифологик җирлекле. Күпчелегендә үзәк образ буларак ислам мифологиясенә бәйле Җен, Иблис, Хозыр, шулай ук төрки-татар ышануларына караган Су анасы, Убыр, Өрәк кебек мифологик образлар алынган Ш. Бабичның «Газазил», М. Гафуриның «Адәм вә Иблис», Г. Сөнгатинең «Хозыр», Г. Харисның «Өрәк» кебек әсәрләре дөнья әдәбиятындагы «антижанр» функцияләрен яңарта.

XX йөз башы шигърияте Ислам дине һәм борынгы ышанулар белән бәйле мифологик образларны татар укучысына символ югарылыгына күтәреп тәкъдим итә. Дини-мифологик образлар әдәбиятта тормыштагы авырлыкларга, ямьсезлеккә мөнәсәбәт белдерү яки юаныч эзләү чарасына әйләнә. Тикшерү барышында авторларның бу образларны милләт яшәешенә, гомумиләшеп, кешелек тормышына, кешелекнең яшәеш кануннарына бәя бирүгә, кеше күңелендәге явызлыкны исбатлауга, тормыш, җәмгыять кануннарын кире кагуга юнәлтүе күренде. Шуңа мөнәсәбәттә бу юнәлештәге поэмалар экзистенциаль мотивлар белән баетыла.

Ислам мифологиясенә йөз тоткан әсәрләр, нигездә, демифологизация – яшәп килүче мифны кире кагу, юкка чыгару юлы белән иҗат ителгән. Бу күренеш авторларга кешелек яшәешендәге явызлыкны илаһи югарылыкта хәл итәргә һәм аның дәрәҗәсен көчәйтергә ярдәм итә. М. Гафуриның «Адәм вә Иблис», Ш. Бабичның «Газазил», Г. Сөнгатинең «Хозыр» һ. б. поэмаларда әлеге үзенчәлекләр ачык чагылыш таба.

XX йөз башы поэзиясендә төрки-татар ышануларына бәйле мифологик образлар да кулланыла, ләкин алар күпчелекне тәшкил итми. Без тикшерү үзәгенә алган Г. Сөнгатинең «Су анасы», И. Шаммасиның «Убыр», Г. Харисның «Өрәк» кебек поэма-балладаларында төрки-татар ышануларына бәйле Су анасы, Убыр, Өрәк кебек мифологик образ-

лар яңартыла. Алар да символик яки аллегорик яссылыкта кешелек яшәешенә, кеше күңеленә бәя бирүне максат итә һәм экзистенциаль фәлсәфә үткәрә. Мифологик образлар үзләре дә күп очракта явызлык, авырлык, ямьсезлек символлары булып тәгалләшә. Өйрәнүләрдән күренгәнчә, бу образлар үзләренең борынгы мәгънәви калыбын саклый, шуңа бәйле төстә мифологизация күренеше алга чыга.

XX гасыр башы рухи тормышында төп урынны биләгән гомуми төшенкелек, алдагы көнгә ышаныч сүнү, иҗтимагый-сәяси ситуациянең киеренкелеге татар поэмаларында сызлану фәлсәфәсе чагылуга китерә. Чарасызлык, үлем, җәза, язмыш кебек төшенчәләр милләт, халык язмышы турындагы гамьнәрне бер ноктага җыя һәм әдәбиятта төп мотивларның берсенә әверелә. Бу өлкәдә Н. Исәнбәт, С. Сүнчәләй, Ф. Бурнаш, Б. Мирзанов, Ф. Ибраһимов кебек авторларның эзләнүләре игътибарга лаек.

Сызлану фәлсәфәсенең асылын тәшкил иткән яшәү / үлем каршылыгы поэмаларда кеше яшәешенең мизгел генә булуы, хакыйкатьнең юклыгы, шәхеснең язмыш колы булуына бәйле фаталистик идеяләрне үткәрергә җирлек әзерли. Татар шагыйрьләренең иҗатында еш кына яшәүнең бетүгә юнәлгәнлеге турындагы фикер милләт яшәеше белән бәйләп карала.

Гомумән, XX йөз башы татар поэмаларын әлеге жанр үсешендә яңа баскыч дип бәяләргә мөмкин. Шулар арасыннан романтик һәм модернистик поэмаларның күпчелекне тәшкил итүе әлеге жанрның, традицион фикерләү кысаларыннан үсеп, дөнья әдәбиятына йөз белән борылуы, әсәрләрне милләт белән бәйле идеяләрне үткәрү мәйданына әверелдерүе турында сөйли.

# БИБЛИОГРАФИЯ

## I. Чыганаклар


1. *Бабич Ш.* Газазил // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 205–227.
2. *Бабич Ш.* Кандала // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 201–205.
3. *Бәшири З.* Поезд // Зариф Бәшири шигырьләре. – Казан, 1927. – Б. 15–18.
4. *Бурнаш Ф.* Шәрык гөлләре. – Казан, 1918. – 96 б.
5. *Бурнаш Ф.* Авылда // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 122–124.
6. *Бурнаш Ф.* Коркыт // Аң. – 1916. – № 18. – Б. 280–281.
7. *Бурнаш Ф.* Казакъ кызы // Аң. – 1916. – № 22. – Б. 338–342.
8. *Бурнаш Ф.* Дулкыннар арасында // Аң. – 1916. – № 16–17. – Б. 258–263.
9. *Гайнуллин-Чокалы Г.* Биш мужик. – Казан, 1910. – 16 б.
10. *Гайнуллин-Чокалы Г.* Надан ата. – Казан, 1911.
11. *Гафури М.* Адәм вә Иблис. – Уфа, 1910. – 24 б.
12. *Гобәйди Д.* Башкорт кызы Маһинур // *Гобәйди Д.* Башкорт кызы Маһинур. Төлкенең яңа хәйләсе. – Казан, 1913. – Б. 2–36.
13. *Думави Н.* Шәрык даһие // Аң. – 1915. – № 7. – Б. 129–131; № 8. – Б. 149–151.
14. *Җәгъфәр А.* Рух янында // Аң. – 1916. – № 10. – Б. 162–163.
15. *Ибраһимов Ф.* Төш // Аң. – 1915. – № 17. – Б. 291–293.
16. *Ибраһимов Ф.* Гармун тавышы // Аң. – 1915. – № 20. – Б. 322–324.
17. *Исәнбәт Н.* Качкын // Аң. – 1916. – № 9. – Б. 151–157.
18. *Исәнбәт Н.* Сукбай // Аң. – 1916. – № 19–20. – Б. 294–296.
19. *Исхакый Х.* Шәкерт һәм хәзрәт вакыйгасы // *Исхакый Х.* Милләт бакчасы. – Казан, 1911. – Б. 25–37.
20. *Мамишев Я.* Моңлы хатын Бибигайшә. – Казан, 1911. – 18 б.
21. *Мамишев Я.* Көннекче карт // Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 211–219.
22. *Мирзанов Б.* Инкыйлаб // Аң. – 1915. – № 6. – Б. 100–104; № 7. – Б. 110–113.
23. *Мирзанов Б.* Җен туе // Аң. – 1915. – № 14. – Б. 242–245.
24. *Мирзанов Б.* Сулган чәчәк // Сөембикә. – 1917. – № 7. – Б. 97–100.
25. *Мирзанов Б.* Әнкәм кабере янында // Аң. – 1916. – № 13. – Б. 206–207.

26. Рәхим Г. Яу // Аң. – 1916. – № 24. – Б. 374–375.
27. Рәхим Г. Баллада // Аң. – 1915. – № 23–24. – Б. 394.
28. Рәшиди Г. Асрау кыз нәсыйхәте. – Казан, 1911. – 16 б.
29. Рәшиди Г. Ахмак хаҗи. – Казан, 1910. – 8 б.
30. Рәшиди Г. Бәхетсез карчык. – Казан, 1912. – 16 б.
31. Сәгыйдә Зәйнәп. Бикчәнтәй бабай // Шура. – 1915. – № 16.
32. *Сөнгати Г.* Хозыр // Аң. – 1915. – № 4. – Б. 69–72; № 5. – Б. 89–93; № 6. – Б. 109–110.
33. *Сөнгати Г.* Су анасы // Аң. – 1915. – № 15–16. – Б. 260–263.
34. *Сүнчәләй С.* Сүнгән җан // Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре. – Казан, 1913. – Б. 78–85.
35. *Тукай Г.* Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш // *Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда: академик басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908). – Б. 268–283.
36. *Усадова Х.* Залим тырнагында саф күңел. – Казан, 1912. – 20 б.
37. *Хаммадов К.* Күмелгән зәкяват // Кәшшаф Хаммадов шигырьләре. – Казан, 1914. – Б. 13–23.
38. *Харис Г.* Өрәк // Альманах. – Казан, 1915. – Б. 30
39. *Шаммаси И.* Убыр // Аң. – 1914. – № 5. – Б. 101–102.
40. *Шәрифи Г.* Теләнче // Эпик шигърият: XX йөз башы / Төз. Ф. З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – Б. 394–398.
41. *Юлдаш К.* Чура батыр // Аң. – 1916. – № 5. – Б. 75–76.

## II. Фәнни әдәбият

*а) татар телендә:*

42. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 238 б.
43. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
44. *Әхмәдуллин А.* Фәтхи Бурнаш поэмалары // Мирас. – 2002. – № 11. – Б. 37–47.
45. *Бакиров М.* Гомумтөрки шигъриятнең яралуы һәм иң борынгы формалары // Мирас. – 1999. – № 1. – Б. 97–121.
46. *Бәширов Ф.К.* XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Фикер, 2002. – 287 б.
47. *Вәлиди Җ.* Тукай хакында берничә сүз // Тукай турында замандашлары. – Казан, 1960. – Б. 259–263.
48. *Вәлиди Җ.* Татар шагыйрьләре // Вакыт. – 1913. – 24, 25, 26 июль.
49. *Газиз Г.* Сәгыйть Рәмиев шигырьләре тугрысында // Аң. – 1913. – № 11. – Б. 192.
50. *Гайнуллин М.* Татар әдипләре (Иҗат портретлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 280 б.

51. *Галиуллин Т.Н.* Балладаларыбыз турында // *Галиуллин Т.Н.* Яңа үрләр яулаганда. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. – Б. 83–109.
52. *Галиуллин Т.Н.* Шәехзадә Бабич – сатира остасы // Дәгъва. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 246–255.
53. *Галиуллин Т.* Тукай шигырьләрен яңадан укыганда // Тукай укулары. – Апрель – 99. – Казан: Отечество, 2000. – Б. 31–56.
54. *Галиуллин Т.Н.* Милли үзаң һәм шигърият // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2000. – Б. 64–69.
55. *Галиуллин Т.Н.* Без – Тукайлы шигърият! // Мәгариф. – 2006. – № 4. – Б. 7–11.
56. *Ганиева Р.К.* Шагыйрьнең рухи дөньясы: («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). – Казан: ТаРИХ, 2002. – 109 б.
57. *Ганиева Р.К.* Тукай иҗатын өйрәнү юлында // Фәнни Татарстан. – 2002. – № 3/4. – Б. 120–132.
58. *Ганиева Р.К.* «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында нәзыйрәчелек һәм тамаша күрсәтү традицияләре // Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәйләнешләр: Г. Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2011. – Б. 27–29.
59. *Гафиятуллина Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә Тукай. – Казан: Матбугат йорты, 2002. – 152 б.
60. *Гафиятуллина Н.М.* XX йөз башы татар шигъриятендә модернистик эзләнүләр // Фәнни язмалар – 2003. – Казань: РИЦ «Школа», 2004. – Б. 65–70.
61. *Госман Х.* Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1960. – 182 б.
62. *Госман Х.* Шигърият гомере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 208 б.
63. *Гыйлаҗев Т.Ш.* XX йөз башы татар әдәбияты тарихын укыту мәсьәләләре: Методик кулланма. – Казан: Печатный двор, 2002. – 96 б.
64. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты. XX гасыр башы: лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.
65. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
66. *Даутов А.И.* Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. – Казан: «Интелпресс» нәшр., 2002. – 152 б.
67. *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәби нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 271 б.

68. *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.
69. *Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйлаҗев Т.Ш.* Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.
70. *Заһидуллина Д.Ф.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.
71. *Заһидуллина Д.Ф.* Шәехзадә Бабичның иҗат юлы: мәгърифәтчелектән шартлы сурәткә таба // *Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М.* Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 149–166.
72. *Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р.* Әдәби әсәргә анализ ясау: урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.
73. *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – 191 б.
74. *Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р.* Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2007. – 112 б.
75. *Ибраһимов Г.* Татар шагыйрьләре // Әсәрләр: 8 томда. – Казан, 1978. – 5 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Б. 74–156.
76. *Исхакый Г.* Тукай мәктәптә // Мәктәп. – 1914. – № 6. – 10 апрель.
77. *Исхакый Г.* Милли җитешсезлегебез // Сүз. – 1916. – 14, 19, 23 август.
78. *Мәһдиев М.* Реализмга таба. XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 156 б.
79. *Миңнегулов Х.Ю.* Дөньяда сүземез бар... – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 336 б.
80. *Миңнегулов Х.Ю.* Гасырлар өнен тыңлап... – Казан: Мәгариф, 2003. – 335 б.
81. *Миңнегулов Х.Ю.* Еракта да якын Тукай // Казан утлары. – 2006. – № 4. – Б. 105–110.
82. *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслеккулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 288 б.
83. *Рәмиев З.З.* XX гасыр башы шигърияте // Мирас. – 1998. – № 3. – Б. 12–14.
84. *Рәмиев З.З* XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. – Казан: Школа, 2000. – 180 б.

85. *Рәхим Г.* Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 287 б.
86. *Сибгатуллина Ә.Т.* Суфичылык серләре (Төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 367 б.
87. *Сибгатуллина Ә.Т.* Илаhи гашыйклар юлыннан: (Суфичылык турында очерклар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 143 б.
88. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 1 т.: Борынгы чор hәм Урта гасырлар. – 415 б.
89. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 2 т.: XV–XVIII гасырлар. – 471 б.
90. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 3 т.: XIX йөз. – 551 б.
91. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 4 т.: XX йөз башы. – 533 б.
92. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1996. – 1 т. – 383 б.
93. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. –1999. – 2 т. – 430 б.
94. Татар шигърияте: XX гасыр башы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 447 б.
95. Тукай hәм XX гасыр мәдәнияте. Тукай и духовная культура XX века (Материалы научной конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Тукая) – Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. – Казань, 1997. – 323 с.
96. Ул дәрья да бу дәрья: Борынгы әдәбият. – Казан: Мәгариф, 1999. – 343 б.
97. *Урманче Ф.* Татар мифологиясе // Фәнни эзләнүләр юлында. – Казан: Фикер, 2000. – Б. 102–134.
98. *Халит Г.* Яңа гасыр поэзиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 168 б.
99. *Халит Г., Хисмәтуллин Х., Гыйззәт Б.* XX йөз башында татар әдәбияты. Очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 384 б.
100. *Ханзафаров Н.* Ил белән бергә // *Исәнбәт Н.* Әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 1 т.: Шигырьләр, поэмалар, драматик поэмалар. – Б. 5–12.
101. *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Раннур., 2002. – 352 б.
102. *Хисамов Н.Ш.* Бөек язмышлы әсәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 336 б.
103. *Хисамов Н.Ш.* Хәтер сагында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары hәм публицистика. – Казан: Мәгариф, 2004. – 641 б.

104. *Хисамов Н.Ш.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 208 б.
105. Эпик шигърият: XX йөз башы / төз. Ф.З. Яхин. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 239 б.
106. *Яхин Ф.З.* «Кисекбаш» китабының мистик-мифологик эчтәлеге һәм Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы // Тукай укулары. 22 апрель 1998 ел. – Казан, 1999. – Б. 68–169.

*ә) рус телендә:*

107. *Амирханов Р.У.* Татарский народ и Татарстан в начале XX века: исторические зарисовки. – Казан: Татар. кн. изд-во, 2005. – 152 с.
108. *Афасижев М.Н.* Западные концепции хдожественного творчества. – М.: Высшая школа, 1990. – 174 с.
109. *Белый А.* Символизм как миропонимание. – М.: Республика, 1994. – 528 с.
110. *Бердяев Н.А.* Философия творчества, культуры и искусства: в 2-х т. – М.: Искусство, 1994. – Т. 1. – 541 с.
111. *Бертельс А.Е.* Художественный образ в искусстве Ирана IX–XV веков (Слово, изображение). – М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 1997. – 422 с.
112. *Бикбаев Р.Т.* Современная башкирская поэма (1956–1965): дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 1966.
113. *Богданова Л.А.* Жанровые своеобразие поэмы в литературе Удмуртии: дис. ... канд. филол. наук. – Саранск, 2006.
114. *Больнов Отто Ф.* Философия экзистенциализма. – М.: Лань, 1999. – 367 с.
115. *Бранский В.П.* Искусство и философия: Роль философии в формировании и восприятии художественного произведения на примере истории живописи. – Калининград: Янтарный сказ, 1999. – 704 с.
116. *Брагинский В.И.* Символизм суфийского пути в «Поэме о Море Женщин» и мотив свадебного корабля // Суфизм в контексте мусульманской культуры. – М., 1989. – С. 168–179.
117. *Бройтман С.Н.* Историческая поэтика. – М.: Академия, 2004. – 341 с.
118. *Быстров В.Н.* Идея преображения мира у русских символистов (Д. Мережковский, А. Белый, А. Блок): дис. ... д-ра филол. наук. – СПб, 2004. – 361 с.
119. Введение в литературоведение: Учеб. пособие / под. ред. Л.В. Чернец. – М: Высшая школа, 2004. – 680 с.
120. *Вовк О.В.* Энциклопедия знаков и символов. – М.: Вече, 2006. – 528 с.

121. *Воскресенская М.А.* Символизм как миропонимание Серебряного века: Социокультурные факторы формирования общественного сознания российской культурной элиты рубежа XIX–XX веков. – М.: Логос, 2005. – 236 с.
122. *Гаджиев А.А.* Романтизм и реализм. Теория литературно-художественных типов творчества. – Баку: Элм, 1972. – 347 с.
123. *Гайнутдинов М.В.* Татарская литература зыбких времен (1917–1929 гг). – Казань: Экоцентр, 2001. – 135 с.
124. *Галиуллин Т.Н.* Дыхание времени. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1979. – 304 с.
125. *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и его традиции в тюркских литературах: дис. ... докт. филол. наук. – Казань, 1992. – 325 с.
126. *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 272 с.
127. *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 172 с.
128. *Гильманов Г.Х.* Татарская баллада. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 192 с.
129. *Гречаник И.В.* Художественная концепция бытия в русской лирике первой трети XX в.: дис. ... д-ра филол. наук. – М., 2004. – 365 с.
130. *Гуляев Н.А.* О формах романтической типологии // Романтизм: Грани и судьбы. Ч. 1. – Тверь, 1992. – С. 10–15.
131. *Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI в. – Казань: РИЦ «Школа», 2006. – 140 с.
132. *Давыдова Т.Т., Пронин В.А.* Теория литературы: учебное пособие. – М.: Логос, 2003. – 232 с.
133. *Долгополов Л.М.* Горький и проблема «детей солнца» (1900-е годы) // *Долгополов Л.М.* На рубеже веков. О русской литературе конца XIX – начала XX века. – Л., 1985. – С. 63–78.
134. *Долгополов Л.К.* Поэмы Блока и русская поэма конца XIX – начала XX веков. – М. – Л.: Наука, 1964. – 190 с.
135. *Дорошевич А.* Миф в литературе XX века // Вопросы литературы. – 1970. – № 2. – С. 122–140.
136. *Ермилова Е.В.* Теория и образный мир русского символизма. – М.: Наука, 1989. – 176 с.
137. *Есин А.Б.* Принципы и приемы анализа литературного произведения. Учебное пособие. – М.: «Флинта – Наука», 2002. – 248 с.
138. *Жульен Н.* Словарь символов. – Челябинск: Издательство «Урал LTD», 1999. – 500 с.
139. *Загидуллина Д.Ф.* Изменение моделей мира в татарской литературе 1906–1908 годов // Ученые записки КГУ. Т. 147, кн. 2. – Казань, 2005. – С. 66–72.

140. *Ибрагимов М.И.* Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. – Казань: Gumanitaria, 2003. – 62 с.
141. *Иванова И.С.* Феномен времени в лирике Серебряного века: дис. ... канд. филос. наук. – М., 2002. – 167 с.
142. История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). – Казан: Фикер, 2003. – 472 с.
143. *Киреева Л.Р.* Структрурные особенности современной башкирской поэмы: автореф. ... канд. филол. наук. – Уфа, 2004.
144. *Коваленко С.* Художественный мир советской поэмы: Возможности жанра. – М.: Наука, 1989. – 272 с.
145. *Колобаева Л.А.* Русский символизм. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 2000. – 296 с.
146. *Коссак Е.* Экзистенциализм в философии и литературе. – М.: Политиздат, 1980. – 360 с.
147. *Куликова И.С.* Философия и искусство модернизма. – М.: Политиздат, 1980. – 350 с.
148. *Кузьмичева Н.В.* Мотив сна в поэзии русских символистов (на материале поэзии Ф. Сологуба): дис. ... канд. филол. наук. – Ярославль, 2005. – 176 с.
149. *Кунафин Г.С.* Развитие жанровой системы в башкирской поэзии II половины XIX – нач. XX вв.: дис. ... д-ра филол. наук. – Уфа, 1998. – 505 с.
150. Литература: миф и реальность. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. – 298 с.
151. Литературная энциклопедия терминов и понятий (под ред. А.Н. Николюкина). Институт научной информации по общественным наукам РАН. – М.: МПК «Интелвак», 2003. – 1600 стб.
152. Литературный энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – 752 с.
153. Литературно-эстетические концепции в России конца XIX – начала XX вв. – М.: Наука, 1975. – 416 с.
154. *Лосев А.Ф.* Проблема символа и реалистическое искусство. – М.: Искусство, 1976. – 367 с.
155. *Лосев А.Ф.* Философия. Мифология. Культура. – М.: Политиздат, 1991. – 525 с.
156. *Лосев А.Ф.* Бытие. Имя. Космос. – М.: Мысль, 1993. – 958 с.
157. *Лотман Ю.* Литература в контексте русской литературы XVIII века // О русской литературе. – С.Пб., 1997. – С. 118–137.
158. *Максимов Д.Е.* О мифопоэтическом начале в лирике Блока // Уч. зап. Тартус. ун-та. Вып. 459. Творчество А.А. Блока и русская литература XX века. Блоковский сборник III. – Тарту, 1979. – С. 4–26.

159. *Махмудов А.* Торжество прекрасного. – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – 180 с.
160. *Мелетинский Е.М.* От мифа к литературе. Курс лекций «Теория мифа и историческая поэтика». – М.: РГДУ, 2001. – 169 с.
161. *Мелетинский Е.М.* О литературных архетипах. – М., 1994. – 134 с.
162. *Мещерякова М.И.* Литература в таблицах и схемах. – М.: Рольф, 2000. – 223 с.
163. *Милюгина Е.Г.* Идея универсального человека в романтизме // Романтизм: грани и судьбы. – Тверь, 1998. – С. 24–31.
164. *Мирсияпова Т.И.* Экзистенциальные мотивы в творчестве М. Ханафи: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2009. – 26 с.
165. Мифология. Энциклопедия / гл. ред. Е.М. Мелетинский. – М.: Большая Российская Энциклопедия, 2003. – 736 с.
166. Модернизм. Анализ и критика направлений. – М.: Искусство, 1987. – 400 с.
167. Модернизм в зарубежной литературе. – М.: Изд-во «Флинта – Наука», 1998. – 240 с.
168. *Мокина Н.В.* Русская поэзия Серебряного века: концепция личности и смысла жизни в динамике художественных мотивов и образов: дис. ... д-ра филол. наук. – Саратов, 2003. – 497 с.
169. *Мухаметшин Р.* Ислам в татарской общественной мысли начала XX века // Очерки истории татарской общественной мысли. – Казань, 2000. – С. 160–188.
170. *Неженец Н.И.* Русские символисты. – М.: Знание, 1992. – 64 с.
171. *Нигматуллин Э.Г.* Татарская литература начала XX века (до 1917 г.) в ее отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли. – Казань, 1972. – 232 с.
172. *Нигматуллин Э.Г.* Раздвигая века и границы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. – 136 с.
173. *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – 212 с.
174. *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань: Фэн, 1997. – 189 с.
175. *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – 176 с.
176. *Нямцу А.Е.* Традиционные сюжеты и образы в литературе XX века: учеб. пособие. – М.: УМК ВО, 1988. – 84 с.
177. *Нямцу А.Е.* Миф и легенды в мировой литературе: Теоретические и историко-литературные аспекты традиционализации. Ч. 1. – Черновцы: Черновицкий госуниверситет, 1992. – 160 с.
178. *Обломиевский Д.Д.* Французский символизм. – М.: Наука, 1973. – 303 с.

179. *Олина Н.В.* Художественно-философские искания в поэзии русского модернизма (А. Блок, С. Есенин): дис. ... канд. филол. наук. – Магнитогорск, 2000. – 162 с.
180. Основы литературоведения: Учеб. пособие для филол. фак-тов пед. ун-тов / Мещеряков В.П., Козлов А.С., Кубарева Н.П., Сербул М.Н.; под общ. ред. В.П. Мещерякова. – М.: Московский Лицей, 2000. – 369 с.
181. *Прохорова Т.Г.* Проза Л. Петрушевской как художественная система. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. – 264 с.
182. *Руднев В.П.* Словарь культуры ХХ века. – М.: Аграф, 1999. – 384 с.
183. Русская литература XIX–XX веков: в 2-х тт. – М.: Аспект Пресс, 2000. – Т. 2.: Рус. лит-ра ХХ века. Литературоведческий словарь. – 462 с.
184. *Сарабьянов Д.В.* Стиль модерн: Истоки. История. Проблемы. – М.: Искусство, 1989. – 261 с.
185. *Сартр Ж.-П.* Ситуации: Сборник. – М.: Ладомир, 1998. – 431 с.
186. *Саяпова А.М.* Поэзия Дардменда и символизм. – Казань, 1997. – 210 с.
187. *Свасьян К.А.* Проблема символа в современной философии. – Ереван: Изд-во АН Арм. ССР, 1980. – 226 с.
188. *Севостьянова В.С.* Архетипика романтического двоемирия в поэтике русского символизма: дис. ... канд. филол. наук. – Магнитогорск, 2004. – 180 с.
189. *Синеокая Ю.В.* Рубеж веков: русская судьба сверхчеловека Ницше // Ф. Ницше и философия в России. – СПб., 1999. – С. 58–72.
190. Современный справочник по литературе (сост. и науч. ред. С.И. Кормилев). – М.: Олимп: ООО «Изд-во АСТ», 2000. – 704 с.
191. Современный экзистенциализм. Критические очерки. – М., 1966. – 320 с.
192. *Соколова Ю.П.* Архетип «Ницше» в русской литературе 1890–1910 гг.: дис. ... канд. филол. наук. – Магнитогорск, 2007. – 170 с.
193. *Соловьев Э.Ю.* Экзистенциализм и научное познание. – М., 1966. – 402 с.
194. *Тамарченко Н.Д.* Методологические проблемы рода и жанра в поэтике ХХ века // Теория литературы. Т. 3: Роды и жанры (особенности проблемы в историческом освещении). – М.: ИМЛИ РАН, 2003. – С. 96–99.
195. *Топоров В.Н.* Миф. Ритуал. Символ. Образ: исследования в области мифопоэтического. – М.: Изд-во «Прогресс» – «Культура», 1995.
196. *Уваров Л.В.* Образ, символ, знак (Анализ современного гносеологического символизма). – Минск: Наука и техника, 1967. – 120 с.

197. *Уваров Л.В.* Символизация в познании. – Минск: Наука и техника, 1971. – 128 с.
198. *Федоров А.А.* Введение в теорию и историю культуры: Словарь. – Уфа, 2003. – 463 с.
199. *Хализев Е.В.* Теория литературы. – М.: Наука, 2000. – 398 с.
200. *Халит Г.* Тукай и его современники. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1966. – 228 с.
201. *Халит Г.* Многоликая лирика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 336 с.
202. *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али. – М.: Наука, 1979. – 254 с.
203. *Шеллинг Ф.В.* Философия искусства. – М.: Издательство «Мысль», 1999. – 608 с.
204. *Шиммель А.* Мир исламского мистицизма. – М.: Алетейа, Энигма, 2000. –416 с.
205. *Шлегель Ф.* Эстетика. Философия. Критика: в 2-х т. – М., 1983. – Т. 1. – 448 с.
206. *Эллис.* Русские символисты. – Томск: Издательство «Водолей», 1998. – 288 с.
207. *Эсалнек А.Я.* Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: учебное пособие. – М.: Флинта-Наука, 2001. – 214 с.
208. *Юсупова Н.М.* Символизация в татарской поэзии начала XX века // Вестник Удмуртского университета. – 2014. Серия «История и филология». – 2014. – № 4. – С. 111–114.
209. *Юсупова Н.М.* Мифологические образы и сюжеты в лиро-эпических произведениях начала XX века: роль, функции и художественное значение // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2014. – № 4. – Ч. 2. – С. 211–214.

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Беренче бүлек. XX йөз башы традицион татар поэмасы
һәм аның үсеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
1.1. XX йөз башы татар поэмаларында реалистик
юнәлеш яңарышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
1.2. XX йөз башы татар әдәбиятында романтик
поэмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Икенче бүлек. XX йөз башы татар поэмаларында
яңача эзләнүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
2.1. XX йөз башы татар поэмаларына символизм агымы
йогынтысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
2.2. XX йөз башы татар поэмаларында сызлану фәлсәфәсе . 123
Йомгак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Библиография . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

Научное издание

**Надыршина Лейсан Радифовна**

**ТАТАРСКАЯ ПОЭМА НАЧАЛА XX ВЕКА
КАК ХУДОЖЕСТВЕННАЯ СИСТЕМА**

(на татарском языке)

Редактор *Л.Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка *Д.Р. Галиуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 12,8. Уч.-изд. л. 12,1. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12